**РЕШЕНИЕ**
КАЗАНСКОЙ
ГОРОДСКОЙ ДУМЫ

КАЗАН ШӘҺӘРЕ
ДУМАСЫ
**КАРАРЫ**

26.02.2026 г.Казань № 4-6

**2025 ел өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының эшчәнлеге турында хисап**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы законы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2025 ел өчен үз эшчәнлеге һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлеге турындагы хисабын тыңлаганнан соң, Казан шәһәре Думасы Казан шәһәре Башкарма комитетының Казан шәһәренең алга таба социаль-икътисади үсешенә, халыкның тормыш дәрәҗәсен һәм сыйфатын күтәрүгә, шулай ук динамик үсештәге шәһәр статусын саклауга юнәлдерелгән бурычларны хәл итә алуын билгеләде.

Югарыда хәбәр ителгәннәрдән чыгып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. 2025 ел өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең эшчәнлеге һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының эшчәнлеге турында хисапны (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Казан шәһәре Башкарма комитетына (Р.Г.Гафаров) Казан шәһәре Башкарма комитетының Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставында билгеләнгән вәкаләтләрен тиешенчә үтәве буенча кирәкле барлык чараларны күрүне йөкләргә.

3. Казан шәһәре Думасының даими комиссияләренә үз юнәлешләре буенча өстенлекле бурычларның үтәлешен системалы рәвештә контрольдә тотуны һәм аларны үз утырышларында карап тикшерүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2026 елның 26 февралендәге
4-6 номерлы карарына
кушымта

**I. КАЗАН ШӘҺӘРЕ ТУРЫНДА ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ** 3

**II. СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ ҮСЕШ** 4
- Социаль-икътисади үсешнең төп күрсәткечләре. Хезмәт базары 4
- Бюджет үтәлеше 9
- Сатып алу эшчәнлеге 14
- Эшмәкәрлеккә ярдәм итү 17
- Кулланучылар базары 18

**III. ТЕРРИТОРИЯЛӘР ҮСЕШЕ** 21
- Шәһәр төзелеше сәясәте 21
- Капиталь төзелеш 24
- Торак сәясәте 27
- Тарихи үзәкне реконструкцияләү һәм үстерү 30

**IV. ШӘҺӘР ХУҖАЛЫГЫ** 32
- Торак-коммуналь хуҗалык 32
- Шәһәр территориясен төзекләндерү. Төзекләндерү өлкәсен контрольдә тоту чаралары 36
- Шәһәр пассажир транспорты 47
- Тышкы реклама 50
- Җирләү эше өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру 53

**V. МУНИЦИПАЛЬ МИЛЕК БЕЛӘН ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ ҖИР МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕН ҮСТЕРҮ** 54

**VI. СОЦИАЛЬ ӨЛКӘНЕ ҮСТЕРҮ** 58
- Демографик вәзгыять. Гражданлык хәле актларын теркәү 58
- Сәламәтлек саклау. Санитария-эпидемиология иминлеге 59
- Сәламәт туклану сәясәтен гамәлгә ашыру 63
- Мәгариф 66
- Мәдәният 76
- Физик культура һәм спорт 82
- Яшьләр сәясәте 88

- Халыкны социаль яклау һәм аңа ярдәм күрсәтү. «Игелекле Казан» проекты 93
- Хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү 97
- Иҗтимагый-сәяси һәм дини оешмалар белән хезмәттәшлек 99
- Милли-мәдәни оешмалар белән хезмәттәшлек 101

**VII. ҖӘМӘГАТЬ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ. КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ СӘЯСӘТНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ** 104

- Хокук саклау эшчәнлеге 104
- Яшүсмерләр арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны, наркоманияне профилактикалау 111
- Коррупциягә каршы сәясәт 114
- Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү 116
- «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы. Мәгълүмат саклау 119

**VIII. МӘГЪЛҮМАТ ТЕХНОЛОГИЯЛӘРЕН ҺӘМ ЭЛЕМТӘ ЧАРАЛАРЫН ҮСТЕРҮ** 122

**IX. ТЫШКЫ ЭЛЕМТӘЛӘРНЕ ҺӘМ ТУРИЗМНЫ ҮСТЕРҮ** 125

**X. КАЗАН ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЭШЧӘНЛЕГЕН ТӘЭМИН ИТҮ** 129

- Юридик эшчәнлек 129
- Кадрлар сәясәте 130
- Оешмалардан һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү. Башкару дисциплинасын контрольдә тоту 135
- Җәмәгатьчелек фикерен һәм массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау 140
- Муниципаль архив 141
- Бүләкләү сәясәте 143
- 2023 ел чаралары. Эшлекле дүшәмбеләр 145
- Казан шәһәре Думасы белән хезмәттәшлек 147

**ЙОМГАКЛАУ** 150

**Казан шәһәре** – Татарстан Республикасы башкаласы, биредә республика халкының өчтән бер өлеше яши. Ул Россиядәге иң эре сәнәгать, транспорт, фән-мәгариф, мәдәният һәм туристлык үзәкләренең берсе.

Башкаланың гомуми мәйданы 641,2 кв. км тәшкил итә. 2025 елның 1 гыйнварына шәһәрдә даими яшәүче халык саны 1 329,825 кеше булды.

Территориаль яктан Казан шәһәре 7 районга бүленә.




2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлеге шәһәр хуҗалыгының тотрыклы эшләвен тәэмин итүгә, торак-коммуналь хезмәтләрне сыйфатлы итеп күрсәтүгә, халыкның белем алуга, медицинага һәм башка хезмәтләргә булган ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен шартлар тудыруга, аның сәламәтлеген саклауга, гражданнарның аерым категорияләренә адреслы социаль ярдәм күрсәтүне оештыруга, шулай ук халыкның иҗади потенциалын гамәлгә ашыруга һәм мәдәниятне үстерүгә юнәлтелде.

Шәһәр халкының тормыш дәрәҗәсен саклап калу, икътисадның реаль секторы эше өчен уңайлы җирлек формалаштыру Казанны үстерүдә өстенлекле юнәлеш булып тора.

## Социаль-икътисади үсешнең төп күрсәткечләре

2025 елда Казанның социаль-икътисади үсеше республика һәм тулаем ил икътисадында күзәтелгән гомуми вазгыять белән билгеләнде.

Шәһәр икътисады түбәндәге күрсәткечләр белән характерлана:

| Күрсәткечләр | 2024 ел | 2025 ел | 2024 елга карата 2025 ел, % |
|---|---|---|---|
| **Шәһәрнең гомумикътисади күрсәткечләре** | | | |
| Тулаем территориаль продукт, млрд сумнарда | 1714,8* | 1891,3* | 102,5** |
| Үзебездә җитештерелеп озатылган товар күләме, млрд сумнарда | 839,4 | 926,2* | 106,3* |
| Сәнәгать җитештерүе индексы, % | 109,6 | 103,6* | |
| Кулланучылар бәяләре индексы, % (уртача бер елга) | 108,4 | 109,4* | |
| Уртача айлык хезмәт хакы, мең сумнарда | 77,459 | 88,592* | 114,4* |
| Эшсезлек дәрәҗәсе, % | 0,18 | 0,19 | |
| Шәһәр икътисадына кертелгән инвестицияләр, млрд сумнарда | 512,2 | 579,7* | 105,0** |
| Ваклап сату әйләнеше, млрд сумнарда | 938,1 | 1 037,4* | 101,8** |

Искәрмә: * бәя;
** чагыштырма бәяләрдә.

2025 ел нәтиҗәләре буенча тулаем территориаль продукт күләме 1 891,3 млрд сум дәрәҗәсендә булыр дип көтелә.

**Тулаем территориаль продукт, млрд сумнарда**




Шәһәр икътисадында әйдәп баручы урынны сәнәгать җитештерүе алып тора. Ул матди байлыклар җитештерү, товар һәм акча әйләнешен, яңа эш урыннарын һәм инвестиция чыганакларын булдыру юнәлешендә эшли торган төп сектор.

Шәһәр буенча җитештереп озатылган продукциянең тулаем күләме 2025 ел нәтиҗәләре буенча 904 млрд сум тәшкил итте.

2025 елда сәнәгать җитештерүе үсеше 101,5% дәрәҗәсендә бәяләнә (2024 елда – 109,6%).

**Сәнәгать җитештерүе күрсәткечләре**




Инвестицияләр климаты торышы – шәһәрдәге гомумикътисади вазгыятьнең һәм аның үсеш перспективаларының иң мөһим күрсәткечләреннән берсе. Башкала уңайлы инвестиция климатына ия.

Ел башыннан шәһәр икътисадына төп капиталга 300,9 млрд сум инвестиция җәлеп ителде, бу узган ел дәрәҗәсеннән 6,8 процентка түбәнрәк. Шул ук вакытта эре һәм урта предприятиеләр тарафыннан җәлеп ителгән инвестицияләрнең гомуми күләме – 259,7 млрд сум, ягъни 2024 ел дәрәҗәсенә карата 94,2% тәшкил итте.

Казан шәһәре территориясендә инновация инфраструктурасының 28 субъекты: технопарклар, технополислар, бизнес-инкубаторлар, сәнәгать парклары, инжиниринг үзәкләре эшләп килә.

Сәнәгать парклары эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм икътисади үсешне стимуллаштыру өчен нәтиҗәле ресурс булып тора. Бүгенге көндә Казанда 7 индустриаль (сәнәгать) парк үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра. 2025 елда Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында мәйданы 6,3 га булган яңа сәнәгать паркы аккредитацияләнде.

2025 елда Казанда шәһәр һәм республика өчен мөһим булган берничә инвестиция проекты тормышка ашырылды. Кремль яр буенда гастрономия комплексы төзү буенча инвестиция проекты шундыйларның берсе. Инвестицияләр күләме 1,1 млрд сум тәшкил итте, 150 дән артык эш урыны булдырылды.

Шулай ук 2025 елда гамәлгә ашырылган шәхси инвестиция проектлары арасында җитештерү инфраструктурасын киңәйтү буенча «Химград» технополисы проектын билгеләп үтәргә була. Ул яңа резидентларны заманча сәнәгать мәйданнары һәм инженерлык ресурслары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Инвестицияләр күләме 188,4 млн сум тәшкил итте, 217 эш урыны булдырылды.

Моннан тыш, кулланучылар базарын тәэмин итү максатыннан 387 сәүдә урынына исәпләнгән Мәскәү базарын реконструкцияләү буенча инвестиция проекты тәгәлләнде. Инвестицияләр күләме – 1,5 млрд сум.

Гамәлгә ашырыла торган проектлар арасында «Татарстан Республикасы пилотсыз авиация системаларының фәнни-җитештерү үзәге» сәнәгать технопаркы (инвестицияләр күләме – 1,65 млрд сум, булдырыла торган эш урыннары саны – 505), Киров дамбасы янында күпфункцияле комплекс (инвестицияләр күләме – 7,2 млрд сум, булдырыла торган эш урыннары саны – 438) һәм «Курган» мемориаль комплексы территориясендә крематорий (инвестицияләр күләме – 360 млн сум, булдырыла торган эш урыннары саны – 15) төзелешен атап үтәргә мөмкин.

Юдино торак массивында исә терлекчелектә сәнәгый-гамәли генетика буенча технопарк төзү проекты гамәлгә ашырыла башлады (инвестицияләр күләме – 1,25 млрд сум, булдырыла торган эш урыннары саны – 300). Ул шулай ук перспективалы проектлардан санала.

Хезмәт хакы – тормыш дәрәҗәсенең төп күрсәткечләреннән берсе. 2025 елның 11 ае нәтиҗәләре буенча шәһәрнең эре һәм урта предприятиеләрендә уртача хезмәт хакы 107 006,3 Асум тәшкил итте һәм, 2024 елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 17,7 процентка артты.

Бәяләүләр буенча, 2025 елда Казан шәһәре икътисады өлкәсендә эшләүчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 88 591,6 сум булыр дип фаразлана.

2025 елда муниципаль хезмәтләрне электрон формага күчерү һәм аларны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм һәм республика порталына чыгару эше дәвам итте.

Бүгенге көндә мөрәҗәгать итүче 72 муниципаль хезмәт буенча гаризаны һәм документларны, өйдән чыкмыйча гына, электрон рәвештә бирә ала. 2025 елда социаль әһәмияткә ия муниципаль хезмәтләрдән электрон рәвештә файдалану өчен тапшырылган гаризалар өлеше 66% (162,6 мең гариза) тәшкил итте.

Казан шәһәре территориясендә бер тәрәзә принцибы буенча хезмәт күрсәтү «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесенең «Минем документларым» бренды белән билгеле булган 11 бүлеге базасында гамәлгә ашырыла.

2025 елның 9 аенда Казан шәһәренең муниципаль һәм максатчан 22 программасын гамәлгә ашыруга барлык чыганаклардан 43,6 млрд сум бүлеп бирелде, шул исәптән Казан шәһәре бюджетыннан максатчан финанслау күләме 23,9 млрд сум тәшкил итте *(бер елга 53,1 млрд сум көтелә, шул исәптән Казан шәһәре бюджетыннан – 29,4 млрд сум).* Тагын 6 программа бюджет акчаларын җәлеп итмичә үтәлде.

**2026 елда социаль-икътисади үсешнең төп бурычлары:**

- илкүләм проектларны гамәлгә ашыру буенча эшне координацияләү;
- 2030 елга кадәр Казан шәһәренең социаль-икътисади үсеш стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын үтәүне дәвам итү;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру, шул исәптән хезмәтләрне электрон рәвештә һәм күпфункцияле үзәкләр аша; проактив режимда күрсәтүгә күчү;

- хезмәт хакын арттыруга һәм соры хезмәт базарында эшләүчеләр санын киметүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

- Казан шәһәрендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм аңа ярдәм итү өчен уңайлы шартлар булдыру.

## Хезмәт базары

Шәһәрнең хезмәт базарындагы вазгыять теркәлгән эшсезләр санының түбән дәрәҗәдә булуы һәм күп кенә тармакларның белгечләргә кытлык кичерүе белән билгеләп үтелә. Казан буенча эшсезләр саны арту тенденциясе күзәтелми. 2026 ел башына теркәлә торган эшсезлек дәрәҗәсе эшче көчләр санының 0,19 процентын (2025 елның 1 гыйнварына – 0,18%) тәшкил итте.

2026 елның 1 гыйнварына Казан шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләрендә эшсезләр сыйфатында 1 289 кеше теркәлде (2025 елның 1 гыйнварына – 1 193 кеше). Шул ук вакытта Казан шәһәрендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең мәгълүмат базасында 2026 елның 1 гыйнварына 12 меңгә якын вакансия урнаштырылган, ягъни бер эш эзләүчегә 10 буш эш урыны туры килә.

2024 ел белән чагыштырганда, мәшгульлек үзәкләренә мөрәҗәгатьләр саны артты, 2025 елда, үзенә туры килә торган эш эзләүдә ярдәм сорап, 9 364 кеше мөрәҗәгать итте.

2025 елда 3 693 кеше, яки үзенә туры килә торган эш эзләүдә ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләрнең 39,4 проценты эшсез дип танылды, шулардан:

- хатын-кызлар – 2 504 кеше;
- штатларны кыскарту нәтиҗәсендә эштән азат ителүчеләр – 174 кеше;
- инвалидлар – 282 кеше;
- эшендә озак вакыт өзеклекләр булган затлар – 573 кеше;
- элек эшләмәгән затлар – 69 кеше.

Эшсезлек буенча пособие алучы эшсез гражданнар саны 1 134 кешегә җитте. Казан шәһәре буенча пособиенең уртача күләме 2025 елның декабренә 14 069,07 сум тәшкил итте.

Эшсез гражданнарның структура составы:

1) хезмәт эшчәнлеген туктату сәбәпләре буенча: оешманы ябу яки штатны кыскарту сәбәпле эштән азат ителүчеләр – 7,1%, үз теләге белән эштән китүчеләр – 68,8%, теркәлгән эшсезләрнең гомуми санына карата белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар өлеше – 0,5% һ.б.;

2) белем дәрәҗәсе буенча: югары һөнәри белеме булганнар – 64,7%, урта һөнәри белеме булганнар – 24,5%, урта гомуми белеме булганнар – 7,8%, төп гомуми белеме булганнар – 3%;

3) җенес һәм яшь буенча: хатын-кызлар – 68%, ир-атлар – 32%, 16 дан 29 яшькә кадәрге яшьләр – 6,6%, 30 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлар – 93,4%;

4) аерым категорияләр буенча: пенсия алды яшендәге гражданнар – 22,0%; инвалидлар – 9,1%; эшендә озак вакыт (бер елдан артык) өзеклекләр булганнан соң яңадан эшкә урнашырга теләүчеләр – 10,5%; беренче тапкыр эш эзләүче (элек эшләмәгән) гражданнар – 0,6%.

Вакансияләр структурасы түбәндәгечә: эшче белгечлекләр буенча – 84%, хезмәткәр белгечлекләре буенча – 16%.

Потенциаль хезмәткәрләрне күпләп җәлеп итү максатыннан 2025 елда Казан шәһәрендә 813 предприятие катнашында 72 вакансияләр ярминкәләре һәм эш белән тәэмин итүчеләр көннәре уздырылды, аларга 44,9 мең кеше килде.

Шәһәрдә булган буш эш урыннарына эш эзләүче 6 019 гражданин эшкә урнаштырылды.

94 эшсез гражданинга эшмәкәрлек эшчәнлеге формасында үзмәшгульлекне оештыруда дәүләт ярдәме күрсәтелде, шуларның 92 сенә үз эшен ачуга субсидия бирелде.

Эшсез гражданнарның аерым категорияләренә эш табуда ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру кысаларында вакытлыча эшкә урнаштыру программаларында түбәндәгеләр катнашты:

- эш эзләүдә кыенлык кичерүчеләр – 2 кеше;
- укудан соң буш вакытта эшләргә теләк белдерүчеләр – 522 мәктәп укучысы;
- җәмәгать эшләрендә – 105 кеше.

Хисап елында квоталы һәм резервланган эш урыннарына инвалидлар категориясеннән – 1295 кеше, шулай ук социаль яклауга аеруча мохтаҗлар категориясеннән 20 кеше эшкә урнаштырылды.

2025 елда:

- 435 эшсез гражданин, шул исәптән 24 инвалид;
- «Кадрлар» илкүләм проектының «Мәшгульлеккә ярдәм итүнең актив чаралары» федераль проекты кысаларында 3 834 кеше укытылды.

Эшчәнлек өлкәсен (һөнәр) сайлау, эшкә урнашу, һөнәргә өйрәтү максатыннан 9 678 гражданинга (шуларның 294 е – укучылар) һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт ярдәме күрсәтелде.

1 032 эшсез гражданинга – психологик ярдәм, 1 380 гражданинга социаль адаптация буенча хезмәт күрсәтелде.

Казан шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт ярдәме чаралары Мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасы

базасында 100% электрон рәвештә күрсәтелә башлады. Хәзер гражданнар шәхси кабинет аша барлык төр дәүләт ярдәменнән читтән торып файдалана ала, әйтик, һөнәри тест уза, эш эзләү турында һәм психологик ярдәм алуга гариза бирә, ә эш белән тәэмин итүчеләргә биредә вакансияләрне оператив рәвештә урнаштыру, шулай ук кадрлар белән бәйле мәсьәләләр буенча электрон документлар әйләнешенә күчү мөмкинлеге тудырылды.

**2026 елга планнар:**

- «Кадрлар» илкүләм проекты чараларын гамәлгә ашыру;
- легаль булмаган мәшгульлек өлешен киметү;
- инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннары булдыру максатыннан эш белән тәэмин итүчеләргә дәүләт ярдәме күрсәтү программасында катнашу, шулай ук гражданнарның аерым категорияләрен эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру;
- оборона-сәнәгать комплексы предприятиеләре хезмәткәрләрен укыту;
- мәктәп укучыларына, студентларга һәм уку йортларын тәмамлаучыларга һөнәри үзбилгеләнүдә, белем алу траекториясен сайлауда һәм алынган һөнәр буенча эшләүдә ярдәм итүгә юнәлдерелгән яшьләргә һөнәри юнәлеш бирү һәм шәхси карьера маршрутларын булдыру проектын гамәлгә ашыру.

## Бюджет үтәлеше

**2025 елга Казан шәһәре бюджеты** Казан шәһәре Думасының 2024 елның 18 декабрендәге 3-35 номерлы «2025 елга, 2026 һәм 2027 елларның план чорына Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты турында»гы карары белән керемнәр һәм чыгымнар буенча 50 177,1 млн сум күләмендә расланды. Казан шәһәре бюджетын үтәү барышында аңа үзгәрешләр кертелде, шуларны исәпкә алып, 8 658,7 млн сум дефицит белән (2025 елның 1 гыйнварына калган акчалар әлеге дефицитны финанслау чыганагы булып торалар), керемнәр буенча план билгеләнешләре – 58 584,1 млн сум, чыгымнар буенча 67 242,8 млн сум тәшкил итте.

2025 елда шәһәр бюджеты үтәлеше керемнәр буенча – 62 265,6 млн сум, шул исәптән салым һәм салым булмаган керемнәр буенча – 37 936,9 млн сум, яки аныкланган планнан 107,9%, кире кайтарылмый торган керемнәр буенча 24 328,7 млн сум, яки 100% тәшкил итте.




Шәһәр бюджетында салым һәм салым булмаган керемнәрнең гомуми күләмендә өстенлекле урынны салым керемнәре алып тора, алар өлешенә 84,9% туры килә. Физик затлар керемена салым, махсус салым режимнары һәм җир салымы аеруча күләмле салым чыганаклары булып санала.

Физик затлар керемена салым 2025 елда шәһәр бюджетына норматив буенча 18,1734% керде. Керем 17 495,9 млн сум тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 2 757,9 млн сумга, ягъни 18,7 процентка артыграк. Бюджетка салым керемнәренең гомуми күләмендә салымның чагыштырмача күләме – 54,4%.

Шәһәр бюджетында күләме буенча икенче урында торган керем чыганагы – махсус салым режимнары, алар 6 797,4 млн сум күләмендә керде. 2024 ел белән чагыштырганда, керемнәр 10,7 процентка, ягъни 658,2 млн сумга артты. Махсус салым режимнары үз эченә түбәндәгеләрне ала: салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым (5 880,6 млн сум), салым салуның патентлы системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым (911,6 млн сум) һәм бердәм авыл хуҗалыгы салымы (4,3 млн сум).

Җир салымы шәһәр бюджетына норматив буенча 100% керә. Әлеге салымнан кергән керем 5 035,5 млн сум тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 588,2 млн сумга күбрәк.

Шулай ук шәһәр бюджетына физик затлар милкенә салым – 1 758,8 млн сум күләмендә, дәүләт пошлинасы – 806,9 млн сум күләмендә, нефть продуктларына акцизлар – 133,8 млн сум күләмендә, туристлык салымы – 123,1 млн сум күләмендә, файдалы казылмалар чыгаруга салым – 35,6 млн сум күләмендә, уен бизнесына салым 2,7 млн сум күләмендә керде.

Салым булмаган керемнәр 5 747,3 млн сум тәшкил итте, бу узган ел дәрәҗәсеннән 1,6 процентка, яки 95,0 млн сумга азрак.

Салым булмаган керемнәр муниципаль милектәге мөлкәтне файдаланудан кергән керемнәрне (2 322,1 млн сум); әйләнә-тирә мохиткә

тискәре йогынты ясаган өчен түләүне (58,2 млн сум); түләүле хезмәтләр күрсәтүдән кергән керемнәрне (545,8 млн сум); матди һәм матди булмаган активларны сатудан кергән керемнәрне (1 921,6 млн сум); штрафларны (875,7 млн сум) һәм башка салым булмаган керемнәрне (23,8 млн сум) үз эченә ала.




2025 елда Казан шәһәре бюджетының чыгым өлеше 64 299,1 млн сум тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 10 185,1 млн сумга, яки 18,8 процентка артыграк.

**2025 елда Казан шәһәре бюджеты үтәлеше**

| | 2024 елда үтәлгән, млн сумнарда | 2025 ел | |
|---|---|---|---|
| | | Расланган план, млн сумнарда | Үтәлгән, млн сумнарда |
| **Барлык керемнәр** | **58 069,1** | **50 177,1** | **62 265,6** |
| - салым керемнәре | 27 373,4 | 28 161,8 | 32 189,6 |
| - салым булмаган керемнәр | 5 842,2 | 2 893,4 | 5 747,3 |
| - кире кайтарылмый торган керемнәр | 24 853,5 | 19 121,9 | 24 328,7 |
| **Барлык чыгымнар** | **54 114,0** | **50 177,1** | **64 299,1** |
| - социаль-мәдәни өлкә | 40 241,1 | 41 221,4 | 48 085,0 |
| - гомумдәүләт мәсьәләләре | 8 025,6 | 3 845,5 | 7 993,7 |
| - илкүләм икътисад | 3 280,7 | 2 508,8 | 5 154,5 |
| - торак-коммуналь хуҗалык | 1 927,7 | 1 710,3 | 2 296,4 |
| - бурыч буенча хезмәт күрсәтү | 34,6 | 396,1 | 27,0 |
| - башка чыгымнар | 604,3 | 495,0 | 742,5 |

Бюджет чыгымнары структурасында 74,8% социаль-мәдәни өлкә тармакларына туры килә. 2025 елда социаль өлкә учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт хакы дәрәҗәсен арттыруның гомумреспублика тенденцияләрен саклап калу өлешендә Россия Федерациясе Президентының май указларын үтәү буенча эш дәвам итте, аларны финанслауга 3 635,8 млн сум акча бүленде.

**«Мәгариф»** бүлеге буенча бюджет чыгымнары күләме – 40 052,9 млн сум, шул исәптән тармак муниципаль программаларын үтәү кысаларында террорчылыкка каршы чаралар уздыруга, белем бирү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгытуга, шулай ук күзәтчелек органнарының күрсәтмәләрен үтәүгә 2025 елда 1 072,7 млн сум бүленде, каникуллар вакытында балаларны сәламәтләндерү муниципаль лагерьлары территориясендә җәмәгать тәртибен саклау чыгымнарын да кертеп, Казан шәһәрендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслауга 468,5 млн сум юлланды, ә яшьләр сәясәте өлкәсендә бюджет чыгымнары 647,8 млн сум тәшкил итте.

**«Мәдәният»** бүлеген финанслауга 2 254,4 млн сум акча тотылды. Бүлеп бирелгән акчалар мәдәният сарайлары һәм йортлары, китапханәләр челтәре, шәһәр музейлары һәм башка мәдәният учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтүгә, шулай ук мәдәният өлкәсендә шәһәркүләм чаралар үткәрүгә юнәлдерелде.

**«Социаль сәясәт»** бүлеге буенча чыгымнар 2025 елда 2 700,3 млн сум тәшкил итте һәм түбәндәге максатларга юнәлдерелде:

| **Чыгымнар юнәлеше** | **Сумма,** млн сумнарда |
|---|---|
| Җәмәгать транспорты хезмәтеннән бертигез файдалану мөмкинлеген тәэмин итү | 1 508,1 |
| Махсус хәрби операция уздыру кысаларындагы чаралар | 609,5 |
| Тәрбиягә бала алучы гаиләләргә һәм опекуннарның гаиләләренә тәрбиягә алынган балаларны карап тәрбияләү өчен түләүләр, шулай ук тәрбиягә бала алучы ата-аналарга акчалата бүләкләр һәм өстәмә түләүләр | 225,7 |
| Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының ташламалы категориясен, шулай ук 5-11 сыйныф укучыларын кайнар ризык белән тәэмин итү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтү | 283,4 |
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре | 33,0 |
| Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү | 27,3 |
| Мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары | 7,0 |
| Башкалар | 6,3 |

2025 елда **«Физик культура һәм спорт»** бүлеге буенча бюджет чыгымнары 3 077,4 млн сум тәшкил итте, алар шәһәрдәге спорт мәктәпләрен,

спорт корылмаларын карап тотуга, шулай ук массакүләм спорт чаралары уздыруга тотылды.

**«Сәламәтлек саклау»** бүлеге буенча чыгымнар 64,0 млн сум күләмендә исәпләнә. Акчалар эпидемиягә каршы чаралар уздыруга юнәлдерелде.

**«Гомумдәүләт мәсьәләләре»** бүлеге буенча бюджет чыгымнары 7 993,7 млн сум тәшкил итте.

**«Илкүләм иминлек һәм хокук саклау эшчәнлеге»** бүлеге буенча чыгымнар күләме – 495,5 млн сум. Алар берләштерелгән кизү-диспетчерлык хезмәте, хокук тәртибен саклау буенча терәк пунктлар эшчәнлеген тәэмин итүгә, шулай ук гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерүгә, пляжларны әзерләүгә һәм карап тотуга тотылды.

**«Илкүләм икътисад»** бүлеге буенча бюджет акчалары 5 154,5 млн сум күләмендә үзләштерелде, шуларның 4 284,5 млн сумы – урам-юл челтәрен карап тотуга, 735,4 млн сумы – транспорт өлкәсендәге чыгымнарга, 67,9 млн сумы илкүләм икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләрне финанслауга юнәлдерелде.

**«Торак-коммуналь хуҗалык»** бүлеге буенча чыгымнарны финанслауга 2 296,4 млн сум акча бүлеп бирелде, аңа торак фондын капиталь ремонтлау; гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү; төзекләндерү объектларын агымдагы карап тоту һәм ремонтлау, шәһәрне чәчәкләр белән бизәү өчен тотылган чыгымнар керә.

**«Әйләнә-тирә мохитне саклау»** бүлеге буенча 116,3 млн сум күләмендә чыгымнар чистарту корылмаларын карап тотуга, табигатьне саклау буенча чаралар үткәрүгә юнәлдерелде.

2025 елда **муниципаль бурыч буенча хезмәт күрсәтү өчен** тотылган бюджет чыгымнары 27,0 млн сум тәшкил итте. Казан шәһәренең муниципаль бурычы белән идарә итүдә нәтиҗәле сәясәт алып бару расланган планнан 369,1 млн сум күләмендә экономия ясарга мөмкинлек бирде.

**2025 елда ирешелгән төп уңышлар:**

- шәһәр бюджетында төп параметрларның тигезлеге тәэмин ителде һәм финанс тотрыклылыгы сакланды;
- кабул ителгән бюджет йөкләмәләре тулы күләмдә үтәлде;
- салым һәм салым булмаган керемнәр буенча план күрсәткечләре 7,9 процентка арттырып үтәлде, бу 2025 елда биналарны карап тотуга, агымдагы һәм капиталь ремонтлауга, муниципаль учреждениеләрне матди-техник яктан җиһазлауга, шәһәр территорияләрен төзекләндерүгә, шәһәр күләмендә чаралар оештыруга һәм үткәрүгә, проектларны гамәлгә ашыруга өстәмә акчалар тотарга мөмкинлек бирде;
- акчаларның калган өлешен Казан шәһәре бюджетының бердәм счетына җәлеп итү тәртибе эшләнде һәм гамәлгә кертелде, бу үз чиратында муниципаль бурычка хезмәт күрсәтүгә чыгымнарны киметергә мөмкинлек бирде.

**2026 елга төп бурычлар:**

- 2026 елга кабул ителгән бюджет параметрларын үтәү;
- 2026 елга бюджетта исәпкә алынмаган чыгымнарны финанслау өчен өстәмә чыганаклар эзләү һәм табу;
- социаль-мәдәни өлкә учреждениеләренә үзәкләштерелгән бухгалтерлык хезмәте күрсәтүне автоматлаштыру эшен дәвам итү.

## Сатып алу эшчәнлеге

**Сатып алулар системасы бюджет акчаларыннан нәтиҗәле файдалану һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү ысулларының берсе булып тора.**

2025 елда, сыйфатны яхшырту, ачыклыкны һәм конкурентлылыкны үстерү аша тотрыклылыкка ирешеп һәм сатып алу процессын оештыру-методик яктан тәэмин итеп, заказ бирүчеләрнең сатып алу эшчәнлеген камилләштерү һәм оптимальләштерү эше дәвам итте.

Әлеге өлкәдә Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды:

**Финанслауга лимитларны анализлауның һәм килештерүнең икътисади нәтиҗәләре**

Планлаштырыла торган, әмма 2025 ел бюджетында алдан исәпкә алынмаган сатып алуларның нигезле булу-булмавын анализлау максатыннан хисап елы дәвамында заказ бирүчеләргә сатып алуларны финанслау лимитлары бүлеп бирү проектлары анализланды. Шулай итеп, бюджет акчаларын бүлеп бирү буенча 313,7 млн сумлык 76 проектка (2024 елда – 200,6 млн сумлык 80 проект) анализ ясалды һәм 206,7 млн сум күләмендә, яки 65,9 процентка (2024 елда – 118,7 млн сум, яки 59,2%) лимитлар бүлеп бирүгә гаризаларның кимүе тәэмин ителде.

**2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында»гы федераль законны (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) үтәү кысаларында Казан шәһәре Башкарма комитеты структур бүлекчәләре һәм алар карамагындагы учреждениеләр тарафыннан гамәлгә ашырылган сатып алу эшчәнлегенең икътисади нәтиҗәләре.**

44-ФЗ номерлы федераль законны үтәү кысаларында 2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре һәм алар карамагындагы учреждениеләр тарафыннан сатып алуларны гамәлгә ашыруга 15 789,63 млн сумлык 2038 гариза (2024 елда – 12 949,32 млн сумлык 1 815 гариза) анализланды.

44-ФЗ номерлы федераль законны үтәү кысаларында карап тикшерелгән гаризалар буенча, заказ бирүчеләр өчен контрактның башлангыч максималь бәясен оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү хисабына, гаризаларны карап тикшерү этабында ук 15,56 млн сум күләмендә экономия ясалды, бу карап тикшерелгән гаризаларның гомуми суммасының 0,1 проценты (2024 елда – 34,43 млн сум, яки 0,2%).

2025 елда 44-ФЗ номерлы федераль закон буенча урнаштырылган муниципаль заказ күләме – 14 119,80 млн сумлык 1106 сатып алу процедурасы (2024 елда – 11 929,28 млн сум).

Үткәрелгән конкурентлык процедуралары нәтиҗәләре буенча 2025 елда гомуми экономия 277,73 млн сум, яки урнаштырылган муниципаль заказның гомуми суммасының 1,47 процентын тәшкил итте (2024 елда – 174,9 млн сум, яки урнаштырылган муниципаль заказның гомуми суммасының 1,47 проценты).

Шулай итеп, 2025 елда 44-ФЗ номерлы федераль закон буенча гомуми экономия заказ бирүчеләр тарафыннан сатып алу документларына төзәтмәләр кертү һәм уздырылган сатып алу процедуралары нәтиҗәләре буенча 293,29 млн сум (2024 елда – 210 млн сум) тәшкил итте.

Электрон аукционнар, конкурслар һәм котировкалар запросы буенча бер лотка гариза биргән сатып алу процедураларында катнашучыларның уртача саны – 2,47 (2024 елда – 2,7).

44-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясындагы 3 өлеше нигезендә кече эшмәкәрлек субъектлары өчен һәм 44-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләре нигезендә кече эшмәкәрлек субъектлары арасыннан субподрядчылар, ярдәмче башкаручылар өчен билгеләнгән таләп белән урнаштырылган конкурентлы сатып алулар күләме 4 339,83 млн сум, яки 30,74% (2024 елда – 3 306,59 млн сум, яки 27,72%) тәшкил итте, шуларның:

- 44-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясындагы 3 өлеше нигезендә – 1 845,07 млн сум, яки уздырылган конкурентлык процедураларының гомуми күләменең 13,07 проценты (2024 елда – 1 680,10 млн сум, яки уздырылган конкурентлык процедураларының гомуми күләменең 14,08 проценты);
- 44-ФЗ номерлы федераль законның 30 статьясындагы 5 һәм 6 өлешләре нигезендә – 2 494,76 млн сум, яки уздырылган конкурентлык процедураларының гомуми күләменең 17,67 проценты (2024 елда – 1 626,49 млн сум, ягъни уздырылган конкурентлык процедураларының гомуми күләменең 13,63 проценты).

**Сатып алуларны 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында»гы федераль закон нигезендә гамәлгә ашыра торган шәһәр муниципаль унитар предприятиеләренә, хуҗалык**

**һәм акционерлык җәмгыятьләренә консультацияләр бирү кысаларында сатып алу эшчәнлегенең икътисади нәтиҗәләре.**

2025 елда 25 589,49 млн сумлык 16 279 гариза (2024 елда – 33 291,63 млн сумлык 16 163 гариза) карап тикшерелде.

Сатып алулар буенча документларга заказ бирүчеләр тарафыннан төзәтмәләр кертү һәм уздырылган сатып алу процедуралары нәтиҗәләре буенча гомуми экономия 780,86 млн сум (2024 елда – 773,5 млн сум) тәшкил итте, шул исәптән:

- сатып алулар буенча документларны карап тикшерү һәм контрактның башлангыч максималь бәясен оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү этабында экономия күләме 60,88 млн сум, яки карап тикшерелгән гаризаларның гомуми суммасының 0,24 процентын (2024 елда – 63,19 млн сум, яки 0,19%) тәшкил итте;

- уздырылган сату-алу процедуралары нәтиҗәләре буенча заказ бирүчеләр тарафыннан ясалган экономия – 719,98 млн сум, яки карап тикшерелгән гаризаларның гомуми суммасының 2,81 проценты (2024 елда – 710,31 млн сум, яки 2,13%).

Узган елда Биржа мәйданчыгында 16 меңнән артык (2024 елда – 12 613 сатып алу) сатып алу урнаштырылды, аларның күләме 2,3 млрд сум (2024 елда – 1,8 млрд сум) тәшкил итте. Уздырылган процедуралар нәтиҗәләре буенча экономия – 149 млн сум (2024 елда – 93 млн сум).

Шулай итеп, 2025 елда сатып алу процедураларында 1,4 млрд сум күләмендә экономия тәэмин ителде, ә бюджет акчаларын бүлеп бирүгә гаризаларның гомуми күләме 206,7 млн сумга кимеде.

Муниципаль сатып алулар өлкәсендәге контроль һәм эчке муниципаль финанс контроле кысаларында 2025 елда мәдәният, физкультура һәм спорт учреждениеләрендә, гомуми белем бирү учреждениеләрендә һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләрендә 24 контроль чарасы уздырылды.

Муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыру барышында тикшерелгән акчалар күләме – 6 779 202,63 мең сум. Моннан тыш, 2024 елда террорчылыкны һәм экстремизмны профилактикалау өлкәсендә социаль әһәмияткә ия проектларны гамәлгә ашыруга чыгымнарны каплау өчен коммерциягә нигезләнмәгән оешмаларга Казан шәһәре бюджетыннан субсидияләр бирү һәм алардан максатчан файдалану шартларының, максатларының, тәртибенең үтәлеше тикшерелде (гомуми сумма – 549,33 мең сум). Шулай ук бердәнбер тәэмин итүче белән контракт төзү мөмкинлеге турында 6 муниципаль контракт буенча заказ бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре карап тикшерелде (гомуми сумма – 2 963 340,72 мең сум). 2025 елда тикшерелгән акчаларның гомуми күләме 9 743 092,68 мең сум тәшкил итте.

**2026 елга планнар:**

- импортны алыштыру максатыннан илкүләм режимны куллану схемасын камилләштерү;
- бердәнбер тәэмин итүчедән сатып алуларны электрон формага күчерү;
- сатып алулар өлкәсендә Казан шәһәренең норматив хокукый актларын яңа тенденцияләрне исәпкә алып актуальләштерү;
- уку-укыту семинарлары үткәрү һәм яшьләр арасында сатып алулар буенча белгеч һөнәрен популярлаштыру.

## Эшмәкәрлеккә ярдәм итү

Казанның кече бизнесы ул тулаем территориаль продуктның 42,5 проценты, шәһәрдәге барлык эшләүче халыкның өчтән бере һәм шәһәр бюджетына салым керемнәренең 41,5 проценты (2024 – 47,6%) дигән сүз.

2025 елда Казан шәһәрендә 86 290 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты үз эшчәнлеген гамәлгә ашырды, шуларның 37 758 е – кече һәм микропредприятиеләр, 298 е – урта предприятиеләр, 48 234 е – шәхси эшмәкәрләр.

Кече һәм урта эшмәкәрлек секторында эшләүчеләр саны 2025 елның 9 аенда 429,5 мең кешегә житте. Кече предприятиеләрдә акча әйләнеше шул ук чор нәтиҗәләре буенча 841,5 млрд сум тәшкил итте, бу, 2024 ел белән чагыштырганда, 1,7 процентка түбәнрәк (2024 елның 9 аенда – 856 млрд сум).

Кече предприятиеләрдә эшләүчеләренең уртача айлык хезмәт хакы 2025 елның 9 ае нәтиҗәләре буенча 48,7 мең сум булды, бу, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 25,4 процентка югарырак (2024 елның 9 аенда – 38,9 мең сум).

2025 ел нәтиҗәләре буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан шәһәр казнасына кергән салымнар суммасы 13,4 млрд сум тәшкил итте, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 14,1 процентка күбрәк (2024 елда – 11,7 млрд сум).

Муниципаль заказ кысаларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен урнаштырылган конкурентлы сатып алуларның гомуми күләме 2025 елда 4 339,83 млн сум, яки гомуми муниципаль заказ күләменнән 30,74% тәшкил итте (2024 елда – 3 305,93 млн сум, яки муниципаль заказның гомуми күләменнән 27,71%).

Федераль һәм республика ярдәм чаралары кысаларында эшмәкәрләр хисап елында 14,9 млрд сум күләмендә акча алды, шул исәптән федераль программалардан – 1 224 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (13,1 млрд сум), республика программаларыннан 316 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты (1,8 млрд сум) файдаланды.

Муниципаль ярдәм чаралары җыелмасы эшләвен дәвам итә, аңа түбәндәгеләр керде:

- штрафларга мораторий (2025 елда штрафлар урынына 1554 кисәтү һәм 693 искәртмә чыгарылды);

- кафелар каршында бушлай җәйге верандалар урнаштыру (2025 елда җәйге верандалар урнаштыруга 128 килешү төзелде).

Муниципалитет муниципаль биналарны ташламалы арендалау буенча «Аренда каникуллары» программасы кысаларында Казан эшмәкәрләренә һәм үзмәшгульләргә милек белән ярдәм итүне гамәлгә ашыра. Ташламалы аренда шартларында 5,8 мең кв.м мәйданга 38 килешү төзелде. 37 арендачы – кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары – арендалана торган урынны сатып алу буенча өстенлекле хокуклардан файдаланды.

Казанда үзмәшгульләр саны актив рәвештә үсә бара – 2025 ел башыннан аларның саны 33 252 кешегә артты һәм 168 мең кешедән артып китте (168 381).

## Кулланучылар базары

Казан шәһәренең **кулланучылар базары** социаль-икътисади хәлнең үзенчәлекле индикаторы булып тора.

Казанда кулланучылар базары үсешенең нәтиҗәле динамикасы өчен уңайлы шартлар барлыкка килде.

Ел йомгаклары буенча ваклап сату әйләнешенең 1,8 процентка артуы фаразлана, бу бәяләүләр буенча 1 087,4 млрд сум тәшкил итәчәк (2024 елда – 938,1 млрд сум).

**Ваклап сату әйләнеше**




2025 ел нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре халкына 159,6 млрд сумлык түләүле хезмәтләр күрсәтелер дип көтелә, ул, хезмәтләргә кулланучылар бәяләре индексын исәпкә алып, 2024 ел дәрәҗәсенә карата 101,1% тәшкил итәчәк.

Казан шәһәре буенча барлык товарларга һәм түләүле хезмәтләргә кулланучылар бәяләренең җыелма индексы 2025 ел нәтиҗәләре буенча 109,3% дәрәҗәсендә көтелә.

**Стационар булмаган сәүдә объектлары.** 2025 елда Казан шәһәре территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертелде. Ул 692 объектны үз эченә ала. 2025 ел нәтиҗәләре буенча 559 килешү төзелде (54 килешү гамәлдән чыгарылды). 2026 елга план – 2021 елда төзелгән, гамәлдә булу вакыты чыга торган килешүләрне тагын 5 елга озайту.

Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга хокукларны сату буенча электрон аукционнар әзерләү һәм уздыру эше дәвам итте. 28 лот буенча барлыгы 9 электрон аукцион үткәрелде, 10,4 млн сумлык 28 килешү, шулай ук җәйге верандалар буенча 128 килешү төзелде.

Стационар булмаган сәүдә объектлары өчен урыннар шулай ук җир асты җәяүлеләр кичүләрендә дә сатыла. Хәзерге вакытта хокуклар алты җир асты җәяүлеләр кичүенең дүртесендә (Восстание урамы/Декабристлар урамы, Н.Ершов урамы, Ямашев проспекты/Ф.Әмирхан урамы, Тукай мәйданы) сатылды, ике кичүгә (Сәетгалиев урамы, О.Кошевой урамы) ихтыяҗ юк. Дүрт җир асты җәяүлеләр кичүендә стационар булмаган сәүдә объектлары өчен урыннар сатудан кергән керем 2,4 млн сум тәшкил итте.

Шәһәр бюджетына гомуми керем 79,4 млн сум тәшкил итте.

2025 елда рөхсәтсез һәм законсыз урнаштырылган 181 күчемле милек объекты сүтелде, шулардан 102 стационар булмаган сәүдә объекты төзелгән муниципаль контракт кысаларында – мәҗбүри рәвештә, 79 стационар булмаган сәүдә объекты ирекле тәртиптә сүтелде.

2025 елда авыл хуҗалыгы ярминкәләре эшләвен дәвам итте. Көн саен чатыр ярминкәләре үткәрелде, ә язгы һәм көзге чорда сезонлы ярминкәләр шәһәрнең 14 мәйданчыгында гөрләде. Аларда Татарстан Республикасының 22 муниципаль районыннан килгән авыл хезмәтчәннәре, шулай ук республиканың агросәнәгать комплексына караган 24 оешма шәһәр халкына үз продукциясен тәкъдим итте. Язгы һәм көзге авыл хуҗалыгы ярминкәләрендә 2025 елда барлыгы 1274,1 млн сумлык продукция сатылды.

Республика бюджеты акчалары хисабына алты ярминкә мәйданчыгы модернизацияләнде, шулай ук ике яңа мәйданчык төзелде, аларның берсе – «Салават Күпере» торак комплексында. Барлыгы 205 млн сумлык эшләр башкарылды.

«Салават Күпере» торак комплексында Ә.Авзалова урамындагы 15 номерлы йорт янында ел әйләнәсе эшли торган күпфункцияле сәүдә модуле булган ярминкә мәйданчыгы оештырылды. Ленинград урамындагы 27 номерлы йорт янында эшләгән мәйданчык урынына яңа мәйданчык Беломорск урамы, 6 йорт адресы буенча ачылды.

Академик Лаврентьев урамы, 10 йорт, Батыршин урамы, 20 йорт, Липатов урамы, 7 йорт, Беломорск урамы, 6 йорт, Х.Ямашев проспекты, 71а йорт адреслары буенча урнашкан ярминкә мәйданчыкларында административ-санитар модульләр төзелде, төзекләндерү эшләре башкарылды, коймалар,

яктырту һәм видеокүзәтү системалары урнаштырылды, шулай ук каты көнкүреш калдыклары җыю мәйданчыклары җиһазландырылды.

Р.Зорге урамы, 75 йорт һәм Дементьев урамы, 7 йорт адреслары буенча унашкан мәйданчыкларда территорияне төзекләндерү эшләре башкарылды.

Шулай ук 2025 елда Мәскәү базары реконструкцияләнде. Реконструкция барышында инженерлык челтәрләре тулысынча яңартылды, антресольләр ныгытылды, витраж пыялалар һәм гөмбәз алыштырылды, яңа вентиляция һәм кондиционер системалары урнаштырылды, склад биналары модернизацияләнде, сәүдә витриналары җиһазландырылды һәм ветеринария лабораториясе булдырылды.

**2026 елга планнар:**

- кулланучылар базары өлкәсен координацияләү;
- стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру һәм сүтү эшен җайга салу.

## Шәһәр төзелеше сәясәте

Казан шәһәре Башкарма комитеты шәһәрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү буенча системалы эш алып бара.

2025 ел дәвамында «Татарстан Республикасының пространстволы планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә Казан агломерациясен социаль-икътисади һәм пространство ягыннан үстерүнең комплекслы схемасын гамәлгә ашыру буенча чаралар планын карап тикшерү һәм аңа төзәтмәләр кертү эше башкарылды.

Социаль объект (мәктәп) урнаштыру максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Һ.Такташ урамындагы торак булмаган төзелеш территориясен комплекслы үстерү турында карар кабул ителде.

2025 елда шәһәр төзелеше өлкәсендә түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барылды.

**Шәһәр төзелеше советы**

Шәһәр төзелеше советының 22 утырышы оештырылды һәм үткәрелде, аларда шулай ук Казан шәһәренең тарихи үзәгендә төзелеш алып бару мәсьәләләре күтәрелде. Барлыгы 99 объект карап тикшерелде. Шулардан 31 объект, алга таба проектлаштыруны килештерү өчен, Тарихи җирлекләрдә шәһәр төзелеше эшчәнлеге мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиягә җибәрелде. Шулай ук Казан шәһәре Мэры И.Р.Метшин һәм Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов катнашында ведомствоара комиссиянең 2 утырышы үткәрелде.

**Проект документлары**

Объектның архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренешен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кысаларында 1502 эскиз тәкъдиме һәм концепция карап тикшерелде, 427 объектның архитектура-шәһәр төзелеше ягыннан тышкы күренеше килештерелде.

**Архитектура, шәһәр мохите дизайны**

2025 елда түбәндәгеләр карап тикшерелде:

- элмә такта урнаштыру буенча 3 839 дизайн-проект, шуларның 2 555 е килештерелде;
- төзелеш белән бәйле булмаган эшләр өлешендә шәһәрнең архитектура-шәһәр төзелеше белән бәйле тышкы күренешен билгеләүче 1127 объект, шуларның 459 ы килештерелде;
- тышкы мәгълүмат чараларын гамәлдән чыгаруга 1 602 гариза;
- объектларны аларның архитектурасына яраштырып яктырту буенча 99 паспорт килештерелде.

Моннан тыш, Казан шәһәре территориясендә архитектура-сәнгать ягыннан проектлаштыру өлкәсендә проектларны һәм карарларны карап тикшерү буенча сәнгать советының 5 утырышы үткәрелде.

Хисап елында Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренә комплекслы үзгәрешләр эшләнде һәм кабул ителде.

Ватанны саклаучылар елы кысаларында «Россия Герое Д.Р.Гыйлемханов исемендәге 42 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә Россия Герое Д.Р.Гыйлемханов истәлегенә бюст урнаштырылды.

**Адрес бирү**

2025 елда күчемсез милек объектларына адреслар бирү турында 4702 гариза, архивта саклanучы документларның күчермәләрен бирү, Казан шәһәренең адреслы планы нигезендә күчемсез милек объектларының урнашу урыннарын ачыклау турында 645 мөрәҗәгать карап тикшерелде. 81 404 адрес гамәлгә кертелде. Казан шәһәре территориясендә 15 урамга, 1 урам-юл челтәре элементына, 1 планлаштыру структурасы элементына исемнәр бирелде, 1 урам исеменә үзгәреш кертелде.

Күчемсез милек объектларына инвентаризация үткәрү буенча эш дәвам иттерелде.

74 224 объект буенча кадастр белешмәләрен кертү өчен документлар әзерләнде.

**Территорияләрдә төзелеш алып бару**

Хисап чорында җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләүгә 9369 гариза кабул ителде, җир кишәрлекләре буенча 5338 шәһәр төзелеше планы расланды һәм бирелде.

2025 елда Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен (алга таба – Кагыйдәләр) 2024 елда яңа редакциядә расланган Казан шәһәр округы Генераль планына туры китерү, шулай ук, гамәлдәге законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, аңа үзгәрешләр кертү буенча зур эш башкарылды. Яңа редакциядәге Кагыйдәләр Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 7-4 номерлы карары белән расланды.

Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясенең 52 утырышы уздырылды; комиссия утырышларында 101 мәсьәлә карап тикшерелде; 117 тапкыр җәмәгатьчелек белән фикер алышулар уздырылды; рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга – 7 рөхсәт, җир кишәрлекләреннән файдалануның шартлы рәвештә рөхсәт ителгән төренә 20 рөхсәт бирелде.

2025 елда шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында булган белешмәләрне бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә 931 гариза кабул ителде. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында 5042 документ теркәлде. Ел йомгаклары буенча муниципаль хезмәт күрсәтүдән җирле бюджетка 1 104 000 сум күләмендә түләүләр керде.

**Җир кишәрлекләре ясау**

2025 елда җир кишәрлекләре ясау мәсьәләләре буенча 3000 нән артык гаризага шәһәр төзелеше бәяләмәсе әзерләнде, муниципаль берәмлек территориясенең кадастр планында җир кишәрлекләрен урнаштыруның

2350 схемасы эшләнде. Җир кишәрлекләреннән файдалануга рөхсәтләр бирү турындагы гаризалар буенча 1334 бәяләмә әзерләнде. Моннан тыш ачык сервитутлар билгеләү белән бәйле 195 гариза буенча бәяләмәләр әзерләнде.

Хисап елында ызанлау проектлары расланган территориянең гомуми мәйданы 218 га тәшкил итте.

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетына 16 380 мөрәҗәгать, гариза, хәбәрнамә, ведомствоара мөрәҗәгать керде, шул исәптән:

– төзелешкә рөхсәт бирү турында, төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында, шәхси торак төзелеше объектларын яки бакча йортларын төзүне планлаштыру турында рөхсәтләрнең һәм хәбәрнамәләрнең, ясалма җир кишәрлекләре булдыру буенча эшләр башкаруга рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытларын озайту турында 3 904 гариза;

– капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыруга һәм ясалма җир кишәрлекләрен файдалануга тапшыруга рөхсәтләр бирү турында, мәдәни мирас объектларын саклау буенча башкарылган эшләрне кабул итү актларын бирү турында, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында, шәхси торак төзелеше объектларын, бакча йортларын төзүне тәмамлау турында хәбәрнамәләр бирү хакында 1 524 гариза.

Төзелешкә рөхсәт бирү турында – 1 860 гариза, шул исәптән рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытын озайту турында – 312 гариза, планлаштырыла торган төзелеш турында 2 044 хәбәрнамә карап тикшерелде. 1 667 гариза буенча нәтиҗә – уңай, шул исәптән:

- 66 күпфатирлы торак йорт төзелешенә – 60 рөхсәт;

- блоклап төзелгән торак йортларда 12 блок төзелешенә – 8 рөхсәт;

- гражданлык билгеләнешендәге объектлар төзелешенә – 152 рөхсәт, шул исәптән мәдәни мирас объектларына – 7 рөхсәт;

- төзелеш өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында (рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытын озайтудан тыш) – 270 гариза;

- төзелешкә рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакытын озайтуга – 191 гариза;

- шәхси торак төзелеше объектларының, бакча йортларының төзелешне планлаштыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килүе турында – 986 хәбәрнамә.

Файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында – 546 гариза, капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру өчен рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында – 3 гариза, мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү актларын бирү турында – 5 гариза, төзелешне тәмамлау турында – 969 хәбәрнамә, ясалма юл белән булдырылган җир кишәрлеген файдалануга тапшыру өчен рөхсәт бирү турында 1 гариза карап тикшерелде. 824 гариза буенча нәтиҗә – уңай, шул исәптән:

- 43 күпфатирлы торак йортны файдалануга тапшыруга – 39 рөхсәт;

- блоклап төзелгән торак йортларда 91 блокны файдалануга тапшыруга – 27 рөхсәт;

- гражданлык билгеләнешендәге 191 объектны файдалануга тапшыруга – 109 рөхсәт;

- ясалма юл белән булдырылган җир кишәрлеген файдалануга тапшыруга – 1 рөхсәт;

- төзелгән шәхси торак төзелеше объектларының һәм бакча йортларының хәбәрнамәдә күрсәтелгән параметрларга туры килүе турында – 644 хәбәрнамә;

- мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү турында – 4 акт.

Дәүләт кадастр исәбенә алу һәм хокукларны теркәү турында 1637 гариза юлланды.

Ана капиталы акчаларын җәлеп итеп, шәхси торак төзелеше объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкару турында 13 акт төзелде.

Моннан тыш, хисап чорында җир һәм шәһәр төзелеше законнарын боза торган объектларга карата 11 дәгъва гаризасы бирелде.

**2026 елга планнар:**

- территорияләрне комплекслы үстерү турында карарлар кабул итү эшен дәвам итү, Казан шәһәр округы Генераль планына, Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертүдә катнашу;

- территориянең кадастр планында җир кишәрлекләре чикләре проектларын раслау эшен оештыруны тәэмин итү;

- муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә, процессларны автоматлаштырып, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гамәли платформасын Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасы һәм «Электрон Хөкүмәт» системасы белән интеграцияләү;

- Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасының мәгълүмат катламнарын тулыландыру;

- муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә, белешмәләрне миграцияләп, Дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасын, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең гамәли платформасын һәм Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасын интеграцияләү юлы белән процессларны автоматлаштыру.

## Капиталь төзелеш

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан торак төзү, шулай ук социаль өлкә объектларын төзү, реконструкцияләү, ремонтлау-реставрацияләү һәм капиталь ремонтлау кебек мөһим юнәлешләр буенча эш алып барылды.

**Торак төзелеше**

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фонды инвестор булган Социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру дәвам итте. Ел нәтиҗәләренә караганда, объектлар буенча башкарылган эшләрнең гомуми күләме 8,1 млрд сум тәшкил итте.

Хисап елында 1 310 565 кв.м торак (2024 елда – 1 417 175 кв.м) файдалануга тапшырылды: 708 568 кв.м (2024 елда – 873 688 кв.м) – шәхси торак төзелеше, 601 997 кв.м (2024 елда – 543 487 кв.м) – күпфатирлы торак йортларда, шуларның 97 441 кв. метры (2024 елда – 97 441 мең кв.м) – социаль ипотека буенча.

2025 елда эшләр 11 торак объектында алып барылды, шул исәптән «Салават Күпере» торак микрорайонының 1 номерлы кварталында – 3 йорт, 5 номерлы кварталында – 4 йорт, М-14 «Гаилә» микрорайонында – 4 йорт.

«Салават Күпере» торак микрорайонының 1 номерлы кварталында гомуми мәйданы 29 320,00 кв.м булган 559 фатирлы 3 торак йорт файдалануга тапшырылды.

Аграр урамында алданган өлешкә кереп төзүчеләр өчен гомуми мәйданы 21 982,46 кв.м булган 342 фатирлы йорт төзү эше дәвам итә. Аның заказ бирүчесе һәм төзүчесе – Намуссыз төзүчеләр гамәлләреннән зыян күргән затларга ярдәм итү республика фонды.

2025 елда түбәндәге **социаль инфраструктура объектларында** эшләр тәмамланды:

- Кремль урамындагы 1 һәм 7/1 йортларда урнашкан «Шәһәр Думасы биналары комплексы» төбәк әһәмиятендәге һәм федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты. Гомуми мәйданы 2 754,3 кв.м булган, фәнни-проект документациясе нигезендә яңадан торгызылган һәм заман таләпләреннән чыгып куллану өчен яраклаштырылган объект файдалануга тапшырылды;

- Миславский урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан «Харитонов типографиясе, 1896 ел» төбәк әһәмиятендәге мәдәни мирас объекты. Бинаның фасад өлешен, объектның тарихи тышкы күренешенә туры китереп, яңадан торгызу эшләре башкарылды. Шулай ук кондиционер системасы урнаштырылды;

- Воровский урамында коммуналь хезмәтләр өлкәсендә хезмәт күрсәтү базасы (1 нче этап), (2 нче этап). Хәзерге вакытта гомуми мәйданы 7 578,20 кв.м булган объект файдалануга тапшырылды;

- Даурия урамында механикалаштыру базасы һәм теплица хуҗалыгы. Хәзерге вакытта гомуми мәйданы 12 024,3 кв.м булган объект файдалануга тапшырылды;

- Профсоюз урамы, 25/15 йорт адресы буенча урнашкан бина. Объектның фасады капиталь ремонтланды;

- Дементьев урамы, 2б йорт адресы буенча урнашкан административ бина. Биредә бүлмәләр капиталь ремонтланды;

- «“Лидер” яшүсмерләр клубы» объекты. Биредә тышкы инженерлык челтәрләре: газ белән тәэмин итү, элемтә, су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләре төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

«Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте» үзәкләштерелгән дини оешмасының Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары мөхтәсибәте карамагындагы җирле мөселман дини оешмасы – «Сөләйман» мәчете мәхәлләсе белән килешү кысаларында Серов урамы, 4а йорт адресы буенча «“Ярдәм” инклюзия үзәге» бинасы төзелә.

Югарыда санап үтелгән нәтиҗәләргә ирешү өчен проект-смета документларын әзерләү белән бәйле зур эш башкарылды.

2025 елда түбәндәге проект-тикшеренү эшләре гамәлгә ашырылды:

- Миславский урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан мәдәни мирас объектын капиталь ремонтлау буенча;

- Мирный торак массивында су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәрләрен төзү буенча;

- Казан шәһәрендә Казан – Оренбург автомобиль юлының ПК 0+00 – ПК 10+00 участогында Оренбург Тракты урамы аша җир өсте җәяүлеләр кичүе төзелешен тәмамлау буенча;

- Казан шәһәренең «Кадыш торак массивындагы мәдәният йорты» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе бинасын капиталь ремонтлау буенча.

**2026 елга планнар**

2026 елда 2025 елдан күчкән объектларда эшләр башкару планлаштырыла, шул исәптән:

- Мирный торак массивында җиләк-җимеш агачлары питомнигы базасын төзү;

- Мирный торак массивында тышкы инженерлык челтәрләре булган спорт комплексы төзү;

- Казан шәһәрендә Казан – Оренбург автомобиль юлының ПК 0+00 – ПК 10+00 участогында Оренбург Тракты урамы аша җир өсте җәяүлеләр кичүе төзелешен тәмамлау;

- «ФИЗРА спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү комплексында хуҗалык-көнкүреш, яңгыр канализациясе һәм юл өслекләре төзү;

- А.Камалиев проспектында урнашкан, 2024 елның 21 декабрендә пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме нәтиҗәсендә зыян күргән 1 номерлы күпфатирлы йортта ремонт-торгызу эшләрен башкару;

- Казан шәһәре Авиатөзелеш районының Максимов урамындагы 1 номерлы йортта торак булмаган бүлмәләрне капиталь ремонтлау;

- Тула урамында урнашкан туклану комбинаты бинасын капиталь ремонтлау;

- алданган өлешкә кереп төзүчеләр өчен Аграр урамында йорт төзү;

- Серов урамы, 4а йорт адресы буенча «“Ярдәм” инклюзия үзәге» бинасын төзү.

Социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру дәвам итәчәк. 2026 елда түбәндәге объектлар файдалануга тапшырылачак:

- «Салават Күпере» торак микрорайонының 5 номерлы кварталында гомуми мәйданы 35 709,43 кв.м булган 666 фатирлы 4 йорт;

- Идел буе районындагы М-14 «Гаилә» микрорайонында гомуми мәйданы 64 264,37 кв.м булган 1282 фатирлы 4 йорт;

«Салават Күпере» торак микрорайонында 718 фатирлы 3 йорт төзү буенча эшләр башланачак.

## Торак сәясәте

Гражданнарны торак белән тәэмин итү Казан шәһәре Башкарма комитетының өстенлекле бурычы булып тора. Дәүләт һәм муниципаль торак программаларын гамәлгә ашыру гражданнарның төрле категорияләрен тораклы итү буенча гаять мөһим мәсьәләне хәл итәргә мөмкинлек бирә.

2025 елда Казан шәһәрендә 639 гаилә торак шартларын яхшыртты:

| **Программаның атамасы** | **Гаиләләр саны** |
|---|---|
| Бөек Ватан сугышы ветераннарын һәм башка федераль программаларда катнашучыларны (хәрби хәрәкәт ветераннары, гомуми авырулар буенча инвалидлар, күчеп килергә мәҗбүр булган затлар, Ерак Төньяк районнарыннан күчеп килүчеләр) торак белән тәэмин итү | 16 |
| Социаль ипотека программасы | 515 |
| Яшь һәм күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү | 11 |
| Социаль һәм махсуслаштырылган наем килешүләре буенча торак урыннарга мохтаҗ гражданнарны торак белән тәэмин итү | 55 |
| Авария хәлендәге йортларда яшәгән гражданнарны торак белән тәэмин итү | 42 |
| **БАРЛЫГЫ** | **639** |

2025 елда федераль бюджеттан торак субсидиясе һәм сертификатлар алу хокукына ирешүчеләр: Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары (2 кеше) – 10,201 млн сум, гомуми авырулар буенча инвалидлар (13 кеше) – 33,857 млн сум, Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнар гаиләләре (1 гаилә) – 3,763 млн сум.

**Яшь һәм күп балалы гаиләләрне торак белән тәэмин итү**

2025 елда 10 яшь гаиләгә һәм 1 күп балалы гаиләгә фатир сатып алу өчен 35,586 млн сумлык социаль түләүләр һәм сертификатлар бирелде.

**Социаль ипотека программасы**

Казан шәһәрендә торак шартларын яхшыртуның тагын бер мөмкинлеге – Социаль ипотека программасы кысаларында ташламалы бәядән фатир сатып алу.

2025 елда Социаль ипотека программасы буенча 596 гаилә исәпкә алынды, гомуми чират 1599 гаиләгә кадәр артты; 515 гаилә фатирлы булды; 682 исәп эше яңадан теркәлде, 1051 гаиләнең исәп эшләренә үзгәрешләр кертелде; 987 гаилә, шул исәптән социаль ипотека килешүләре буенча йөкләмәләрне үтәүгә бәйле рәвештә 704 гаилә, исәптән төшерелде.

**Социаль наем килешүләре нигезендә торак белән тәэмин итү**

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә 9 540 гаилә социаль наем килешүе буенча торак урын алуга мохтаҗ буларак исәптә тора. 2025 елда чиратта торучыларны яңадан теркәү буенча зур эш башкарылды, нәтиҗәдә 3 276 гаилә исәптән төшерелде, шуларның 3 244 е – 2005 елның 1 мартына кадәр исәпкә баскан гаиләләр. Соңгы биш елда чират якынча ике тапкырга кимеде.

2025 елда социаль наем килешүләре буенча 46 гаилә торак урыннар белән тәэмин ителде, шуларның 24 е – торакны беренче чиратта алу хокукына ия гаиләләр (1990 елга кадәр исәпкә басучылар); 16 сы – торакны чираттан тыш алу хокукына ия гаиләләр; 6 сына коммуналь фатирлардагы бүлмәләргә карата тиешле хокуклар билгеләнде.

Сату-алу килешүләре нигезендә коммуналь фатирлардагы бүлмәләр (Россия Федерациясе Торак кодексының 59 статьясындагы 3 өлеш) һәм торак урыннардагы өлешләр сатып алуның өстенлекле хокукы буенча 8 гражданинга милеккә тапшырылды (23 595 526 сум).

**Махсуслаштырылган торак фонды**

Махсуслаштырылган торак урыннар бирү эше дәвам итә. 2025 елда Дубравная урамы, 35 йорт адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган йортта гражданнарның ташламалы категорияләренә (инвалидларга, хезмәт ветераннарына һәм хезмәт стажы 30 елдан да ким булмаган пенсионерларга) – 8 торак урын, Дубравная урамы, 43 йорт адресы буенча урнашкан махсуслаштырылган торак комплексында сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле гражданинга 1 фатир бирелде.

**Гражданнарны авария хәлендәге тораклан күчерү**

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 11 сентябрендәге 3856 номерлы карары белән 2024-2026 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программа кабул ителде. Аңа 2025 ел этабы буенча өч йорт (барлыгы 39 торак урын) кертелде.

Этапны гомуми финанслау күләме – 203 млн сумнан артык.

Моннан тыш, 2025 елда суд актларын үтәү максатыннан 3 гаиләгә шәһәрнең муниципаль торак фондыннан бушатылган торак урыннар бирелде.

**Өлешкә кереп төзү**

Казан шәһәре Башкарма комитеты өлешкә кереп төзү өлкәсендә төзүче оешмалар эшчәнлеген контрольдә тоту буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә. Нәтиҗәдә башкалада алданган өлешкә кереп төзүчеләр белән бәйле проблемалы йортлар калмады.

Бүгенге көндә өлешкә кереп төзелә торган 189 объект буенча, шул исәптән төзелү стадиясендә булган 137 объект буенча, 102 төзүче оешма эшчәнлеге контрольдә тотыла. Бу – өлешкә кереп төзүдә катнашучыларның 258 млрд сумнан артык акчаларын җәлеп итү һәм 3,6 млн кв. метрдан артык төзелеш мәйданнары.

Хәзерге вакытта өлешкә кереп төзелә торган барлык объектлар да гражданнарның акчаларын банкның эскроу-счетларында саклауга нигезләнгән яңа кагыйдәләр буенча сатыла. Йорт файдалануга тапшырылганнан соң гына төзүче оешманың гражданнарның акчаларын алу мөмкинлеге барлыкка килә. Шул рәвешле өлешкә кереп төзүчеләрне финанс ягыннан максималь яклауга ирешелде.

Өлешкә кереп төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне үтәүне контрольдә тоту (куркынычсызлык мониторингы) гамәлгә ашырыла. 2025 елда 279 контроль-күзәтчелек чарасы үткәрелде, ачыкланган хокук бозулар буенча 50 акт төзелде, аларны бетерүгә 43 күрсәтмә бирелде һәм хокук бозуларны булдырмау турында 18 кисәтү ясалды.

**Торак урыннарны хосусыйлаштыру**

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан Казан шәһәре муниципаль милкендә булган торак урыннарны гражданнар милкенә тапшыру турында килешүләр төзелә.

2025 елда хосусыйлаштыру килешүләре буенча 557 проект рәсмиләштерелде, 571 торак урынга карата милек хокукы теркәлде.

Шулай ук түбәндәге хезмәтләр күрсәтелде:

- Казан шәһәрендә хосусыйлаштыру хокукыннан файдалану (файдаланмау) турында белешмәләр бирү – 511;
- архив документлары бирү – 298.

**Муниципаль торак фондын формалаштыру**

Суд карарлары нигезендә һәм билгеләнгән тәртиптә (нотариус аша) 43 торак урын иясез калган милек дип танылды һәм аларга карата милек хокукы Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә теркәлде.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге милкендә булган 65 торак урын законсыз яшәүче гражданнардан суд тәртибендә бушатылды, алар торак урынга мохтаҗ гражданнарга закон белән билгеләнгән тәртиптә биреләчәк.

Шулай итеп, 2025 елда Казанның торак фонды – 108 торак урынга, ә соңгы өч елда барлыгы 200 торак урынга тулыланды.

**2026 елга планнар:**

- Социаль ипотека программасы кысаларында торак белән тәэмин итү;

- гражданнарның аерым категорияләрен федераль, республика һәм муниципаль программалар кысаларында торак белән тәэмин итү;

- 2005 елның 1 мартына кадәр исәпкә баскан гаиләләр исемлеген актуальләштерү эшен дәвам итү һәм аларны торак белән тәэмин итү;

- муниципаль торак урыннарны хосусыйлаштыру мәсьәләләре буенча гражданнарны кабул итү һәм торак урыннарны гражданнар милкенә тапшыру буенча килешүләр проектларын рәсмиләштерү;

- 2024-2026 елларга Казан шәһәренең авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча адреслы муниципаль программаны гамәлгә ашыру;

- өлешкә кереп төзү өлкәсендә контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның нәтиҗәле системасын оештырып, Казан шәһәре территориясендә алданган өлешкә кереп төзүчеләрнең барлыкка килүенә юл куймау.

## Тарихи үзәкне реконструкцияләү һәм үстерү

2025 елда «Яңа Порт» территориясен үзгәртеп кору буенча актив эш алып барылды: төзелеш дәвам итте, параллель рәвештә гаражларны сатып алу гамәлгә ашырылды. Саклагыч дамба төзелешенең беренче этабын төгәлләү елның мөһим инфраструктур казанышы булды. Инде хәзердән үк биредә шәһәрнең яңа йөзе тоемлана.

**Торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү**

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» префектурасы тарафыннан өстенлекле программаларны гамәлгә ашыру дәвам итте. 5 йорт (Сул як Болак урамы, 56 йорт, Татарстан урамы, 13 йорт, Әхтәмов урамы, 32 йорт, Гаспринский урамы, 31 йорт, Порт урамы, 17 йорт) капиталь ремонтланды, башкарылган эшләрнең гомуми суммасы 157,3 млн сум тәшкил итте. 8 йортның 19 подъездында авария очракларын кисәтү максатыннан 7,2 млн сумлык планлы ремонт эшләре башкарылды.

«Безнең ишегалды» программасы буенча 2025 елда 115 млн сумга 13 ишегалды төзекләндерелде.

**2026 елга планнар:**

- 5 йортта капиталь ремонт үткәрү;
- «Безнең ишегалды» программасы буенча 3 ишегалдын төзекләндерү.

**Мәдәният**

2025 елда «Иске шәһәр» территориясендә тарихи мирасны саклауга, традицион мәдәниятне үстерүгә, казанлыларның һәм башкала кунакларының ялын бай эчтәлекле итеп оештыруга юнәлдерелгән төрле мәдәни-массакүләм чаралар комплексы гамәлгә ашырылды.

Башкарылган эшләр арасында инде традициягә әйләнгән проектлар да (мәсәлән, «Ураза бәйрәме», Кабан күлендә спортның су төрләре фестивале, Шәһәр көне уңаеннан шәһәр күләмендәге чаралар: «Милли кием», «Печән базары», «Казан сөлгесе»), яңа, актуаль проектлар да бар иде.

2025 елда яңа формат – «Бистәдә җәй» программасы уңышлы гамәлгә кертелде. Әлеге проект җәйге чорда бистәгә килүчеләр санының артуына этәргеч булды һәм аудиториягә даими чаралар циклын тәкъдим итте. Әйтик, традицион һөнәрләр буенча мастер-класслар, үз һөнәренең чын осталарыннан белем бирү программалары һәм лекцияләр, балалар өчен интерактив уен программалары, шахмат буенча даими турнирлар, кич ачык һавада кино күрсәтүләр, музыкаль коллективлар чыгышлары, бию программалары.

**Объектларны реставрацияләү**

2025 елда «Иске шәһәр» территориясендә профильле ведомстволар тарафыннан тарихи-мәдәни мирас һәйкәлләрен ачыклау һәм саклау буенча эш дәвам иттерелде. Шундый ачыкланган объект – сәнәгатьче Якуб Козлов йорты (XIX гасыр, Мехчылар урамы, 78 йорт). Сәүдәгәр Юнысовлар һәм Үтәмешевларның сәүдә кибетләре комплексын (XIX гасыр, Мәскәү урамы, 57/13 йорт) исә реестрга кертү процессы башланды.

Элеккеге Казан укытучылар семинариясе бинасында (1873 ел, Ш.Мәрҗани урамы, 26 йорт) реставрация эшләре, «“Мазут” җәмгыяте йорты» объектында (XIX гасыр, Мехчылар урамы, 2 йорт) авариягә каршы эшләр башланды, Шакир солдат йортының (XIX гасыр, Г.Тукай урамы, 16 йорт) фасады реставрацияләнде, Каюм Насыйриның музей-йортын торгызу дәвам итә.

Сәнәгать архитектурасының уникаль һәйкәлен – Александровларның сыра кайнату заводы комплексын (Петцольдның «Көнчыгыш Бавария»се, XIX гасыр ахыры, Г.Тукай урамы, 97 йорт) реставрацияләү гамәлгә ашырыла. «Бертуган Крестовниковлар» фабрика-сәүдә ширкәте бинасының тарихи корпусын торгызуның икенче этабы башланды.

## Торак-коммуналь хуҗалык

**Торак-коммуналь хуҗалык** – зур икътисади һәм социаль әһәмияткә ия булган тармак, чөнки ул барлык гражданнарның мөһим тормыш мәнфәгатьләренә, халыкның тормыш эшчәнлеген турыдан-туры тәэмин итү, аларның яшәү уңайлылыгы, шулай ук сыйфатлы торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү мәсьәләләренә кагыла.

**Торак фонды**

Торак фондының гомуми мәйданы – 52,3 млн. кв.м: 5 915 күпфатирлы йорт (алга таба – күпфатирлы йортлар) (43,8 млн кв.м), 115 тулай торак (0,5 млн кв.м), 61 417 шәхси торак йорт (8,03 млн кв.м).

Күпфатирлы йортлар белән Казанда 137 идарәче компания идарә итә, алар идарәсендә 5 086 күпфатирлы йорт (84,2%); 740 торак милекчеләре ширкәте һәм торак-төзелеш кооперативы, 858 күпфатирлы йорт (14,3%) тора. 86 күпфатирлы йорт (йортларның 1,5 проценты) белән турыдан-туры милекчеләр идарә итә.

2025 елда социаль һәм махсуслаштырылган яллау буенча 806 килешү һәм аларга өстәмә килешүләр төзелде. Күпфатирлы йортта идарәче оешмаларны сайлау буенча 76 ачык конкурс үткәрелде.

Торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә халыкка сыйфатлы хезмәт күрсәтү төп бурыч булып кала бирә.

**Инженерлык челтәрләрен ремонтлау**

2025 елда Казан шәһәрендә дистә еллар элек кертелгән инженерлык челтәрләренең тузу проблемасы булуы ачык күренде. 2025 елда Казанда су белән тәэмин итү һәм су чыгару челтәре һәм корылмалары 70 проценттан артыкка тузды, җылылык челтәрләренең уртача тузганлыгы – 2024 ел белән бер дәрәҗәдә калган һәм уртача 55 процент тәшкил итте.

2025 елда инженерлык челтәрләрендә һәм корылмаларында 5,53 млрд сумлык, шул исәптән коммуналь инфраструктураны модернизацияләүнең республика программасы буенча – 1,57 млрд сумлык, предприятиеләрнең инвестиция программалары буенча – 4,53 млрд сумлык эшләр башкарылды.

2026 елга муниципаль милектәге, 100 процент тузган Щапов, Касаткин урамнары буенча су белән тәэмин итү челтәренең 2 участогын, Бертуган Касыймовлар, Җиңү проспекты, Техника, Варганов, 2 нче Азино урамнары буенча канализация челтәренең 5 участогын, Иделдән суалгыч җайланмасы корылмаларын ремонтлау, җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү челтәрләренең 13 участогын алыштыру өчен гаризалар бирелде.

**Су белән тәэмин итү һәм җылылык белән тәэмин итү**

2025 елда «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте 12,06 км озынлыктагы җылылык челтәрләрен (бер торба исәбеннән санаганда), 4 котел агрегатын алыштырды, 28 котельный бинасын һәм 13 төтен торбасын реконструкцияләде һәм капиталь ремонт үткәрде, 24 котельныйда физик һәм мораль яктан искергән җиһазларны алыштырды.

Казан җылылык челтәрләре оешмасы 26,9 км җылылык челтәрен реконструкцияләде һәм капиталь ремонт үткәрде. Васильченко урамында ПНС-5 суыртып агызу насос станциясен төзү тәгәлләнде, бу шәһәрнең Төньяк зонасын җылылык белән тәэмин итүнең ышанычлылыгын һәм сыйфатын арттырырга, шулай ук яңа территорияләрне җылылык белән тәэмин итүгә тоташтырырга мөмкинлек бирәчәк. «Портовая» территориясендәге торак һәм социаль объектларны җылылык белән тәэмин итү өчен 2,1 км озынлыктагы 1 номерлы магистраль җылылык үткәргеч төзелеше башкарылды.

Оборона министрлыгының торышы канәгатьләнерлек булмаган 33 нче хәрби шәһәрчегендәге котельныйдан файдаланучыларны җылылык белән гарантияле тәэмин итү максатыннан Татарстан Республикасы Рәисенең коммуналь инфраструктураны модернизацияләү программасы буенча блоклы-модульле котельный төзелде. Котельныйны 2026 елның 1 нче кварталында файдалануга тапшыру планлаштырыла.

2025 елда «Водоканал» муниципаль унитар предприятиесе объектларында 2,6 млрд сумлык түбәндәге эшләр башкарылды:

- Дербышки станциясе торак массивын су белән тәэмин итү өчен гомуми озынлыгы 1,2 км булган яңа сүүткәргеч төзелеше тәмамланды;
- Яңа Әмәт коллекторын, 1 нче Төньяк коллектор участогын реконструкцияләү тәгәлләнде;
- канализация чистарту корылмаларында идарә шкафларын модернизацияләү һәм күчерү эшләре тәмамланды;
- Киров һәм Яңа Савин районнарында гомуми озынлыгы 2,38 км булган канализация торбаүткәргече участокларын реконструкцияләү тәгәлләнде;
- шәһәрнең барлык районнарында 3,043 км озынлыктагы суүткәргеч участоклары реконструкцияләнде.

Объектларда 2026 елда дәвам итә торган эшләр башкарыла:

- «Танкодром» су алу җайланмасында 3 яңа скважина бораулау;
- Окраинная урамындагы Аракчино Шоссесы урамыннан алып 2 нче күтәрелеш суүткәргеч насос станциясенә кадәр суүткәргеч участогын реконструкцияләү.

«Экология» илкүләм проектының федераль программасы кысаларында Казан шәһәре канализациясенең биологик чистарту корылмалары ике этапта реконструкцияләнде. 2026 елда Казан шәһәренең биологик чистарту корылмаларының ләм кырларын рекультивацияләү тәмамланачак.

Гидротехник корылмаларны алга таба файдалануның һәм карап тотуның максатка ярашлылыгын билгеләү өчен Казан шәһәренең инженерлык сагы объектларына, Казан шәһәрендә төзелгән һәм перспективалы төзелешне исәпкә алып, гомуми суммасы 27,5 млн сум тәшкил итә торган күп факторлы тикшерү үткәрелде. Гидротехник корылмаларны тикшерү нәтиҗәләре реаль күренешне билгеләргә һәм алга таба чаралар планын формалаштырырга мөмкинлек бирә.

2021 елдан җир кишәрлегенә түләүсез газ кертүгә юнәлдерелгән **газлаштырып бетерү программасы** эшләп килә.

2025 елда 922 гариза бирелде, 597 кулланучы газга тоташтырылды.

Әлеге программа эшли башлаганнан бирле 2 158 кулланучы тоташтырылды.

**Күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау**

2025 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау программасы буенча 4,0 млрд сумлык 224 йорт ремонтланды, аерым алганда:

- 55 йорт түбәсе алыштырылды;
- 46 йортта җылылык системасы ремонтланды;
- 47 йорт фасады ремонтланды, шулардан 22 йортның фасады җылытылды;
- 45 йортта – салкын су белән тәэмин итү инженерлык системалары, 19 йортта – кайнар су белән тәэмин итү системалары, 46 йортта су чыгару системалары алыштырылды;
- 2 йортта янгыннан саклау системасы (АППЗ) ремонтланды;
- 10 йортта 12 һава торышы буенча көйләү узелы урнаштырылды,
- 141 йортта 457 лифт алыштырылды.

Башкарылган эшләр нәтиҗәсендә әлеге йортларда яшәүче 67 меңнән артык кешенең яшәү шартлары яхшыртылды.

**Күпфатирлы йортларга агымдагы ремонт башкару**

Проект-смета документациясен эшләү һәм эшләрнең үтәлешенә техник күзәтчелек үткәрү белән комплекслы якын килү нигезендә башкарылган агымдагы ремонт программасы буенча 2025 елда 834 күпфатирлы йортта 913,7 млн сумлык ремонт ясалды, шул исәптән:

- температура-дымлылык режимын нормальләштерү буенча барлык кирәкле чараларны үтәп, 39 түбә;
- 69 йортта төтен юллары һәм вентиляция каналлары;
- 78 йортның фасады;
- 39 йортта үзәк җылыту системасы;
- 43 йортта кайнар су белән тәэмин итү системасы;
- 58 йортта салкын су белән тәэмин итү системасы;
- 51 йортта канализация системасы;
- 15 йортта һава торышы буенча көйләү узеллары;
- 352 күпфатирлы йортның 741 подъезды ремонтланды.

99 йортта электромонтаж эшләре башкарылды.

**Калдыклар белән эш итү**

2025 елда 85 контейнер мәйданчыгы, шул исәптән «Безнең ишегалды» программасы кысаларында 62 контейнер мәйданчыгы тәртипкә китерелде.

Казан шәһәрендә 2 903 контейнер мәйданчыгыннан калдыклар чыгарыла. Төбәк операторы тарафыннан Казан шәһәре буенча каты коммуналь калдыкларны туплау өчен 2 000 нән артык мәйданчыкта калдыкларны аерым

җыю өчен сортларга, биш төрле фракциягә: пыяла, пластик, кәгазь, металл һәм тетрапакка аеру өчен органик булмаган калдыклар өчен билгеләнгән 2 463 сары челтәрле контейнер урнаштырылды. Контейнер мәйданчыкларының 80 проценты чүп-чарны аерым туплау өчен җиһазландырылды.

2024 елдан Казан шәһәре буенча текстиль эшләнмәләр җыю проекты гамәлгә ашырыла. Контейнерлар күбесенчә контейнер мәйданчыкларына куела, аларда барлык төр текстиль әйберләр, шул исәптән теләсә нинди хәлдәге кием-салым, аяк киеме, сумкалар, йомшак уенчыклар һәм өй текстиле кабул ителә. Ике ел эчендә 200 тоннага якын текстиль эшләнмәләр җыелды, Казан территориясендә текстиль җыю өчен барлыгы 226 контейнер куелды.

2025 елның апрелендә төбәк операторы тарафыннан Ватан урамы, 45 йортта урнашкан икенче «Җыю ноктасы» пункты гамәлгә куелды. Проект махсус билгеләнгән мәйданчыкларда икенчел эшкәртү өчен калдыкларны җыюны, күмүгә җибәрелә торган калдыкларның гомуми өлешен киметүне күздә тота.

2025 елда калдыкларны аерым җыюга эшмәкәрләр дә кушылды. Мәсәлән, октябрьдә «Җыю ноктасы» пунктларына өстәмә рәвештә Үзәк Мариуполь урамы, 49Б һәм Д.Давыдов урамы, 75 адресы буенча икенчел чималны сортларга аера торган яңа пунктлар ачылды. 4 мәйданчыктан җыелган икенчел чималның гомуми күләме 348 тонна тәшкил итте. 2026 елда эшмәкәрләр тагын шундый 20 пунктны файдалануга тапшырырга планлаштыра.

Хәзерге вакытта каты коммуналь калдыклар Мамадыш тракты урамындагы бердәнбер «Восточный» каты коммуналь калдыклар полигонының II картасына чыгарыла. II картаның сыйдырышлыгы 1,6 млн тоннадан артык каты көнкүреш калдыклары тәшкил итә. Әмма бер тәүлеккә уртача 1 600 тонна калдык ташылган очракта, полигонны ел ярымнан соң файдаланып булмаячак. Шул сәбәпле хәзерге вакытта полигонның 3 нче картасын төзү өчен җир кишәрлеге бирү мәсьәләсен хәл итү буенча эш алып барыла.

**2026 елга планнар:**

1. Казан шәһәренең җылылык белән тәэмин итү схемасын актуальләштерү.

2. Ресурслар белән тәэмин итүче оешмаларның инвестиция программаларын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту.

3. Газлаштырып бетерү программасын дәвам итү – газлаштырылган торак пунктларда газны җир кишәрлекләре чикләренә түләүсез китереп җиткерү.

4. 3 нче Төньяк канализация коллекторын, Лукин урамындагы канализация насос станциясен, шулай ук Х.Мәүлүтев / Академик Парин урамыннан алып Оренбург тракты урамына кадәр Универсиада Авылы территориясендә, Дубравная урамындагы 23 йорттан Дубравная урамындагы 66 йортка кадәр Ю.Фучик урамында урнашкан коллектор участокларын реконструкцияләү.

5. Окраинная урамындагы Аракчино Шоссесы урамыннан алып 2 нче күтәрелеш суүткәргеч насос станциясенә кадәр суүткәргеч участогын реконструкцияләү.

6. Шәһәр хуҗалыгын 2026/2027 елның кышкы чорында файдалануга әзерләү кысаларында җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү һәм су чыгару объектларын һәм челтәрләрен капиталь ремонтлау һәм реконструкцияләү.

7. Күпфатирлы йортларның гомуми милкен капиталь ремонтлау программасын гамәлгә ашыру.

8. «Восточный» каты коммуналь калдыклар полигонының 3 нче картасын төзү өчен җир кишәрлеге бүлеп бирү.

9. Контейнер мәйданчыкларында каты коммуналь калдыкларны аерым туплауны гамәлгә кертүне дәвам итү.

10. «Муниципаль торакны исәпкә алу мәгълүмат системасы» муниципаль торак фондын исәпкә алу буенча программа продуктын интеграцияләү.

## Шәһәр территориясен төзекләндерү

**Төзекләндерү** – мегаполисның индивидуальлеген һәм эстетик җәлеп итүчәнлеген, анда яшәү уңайлыкларын һәм тормыш сыйфатын тудыручы заманча шәһәр мохитенең төп характеристикаларының берсе.

**Урам-юл челтәрен карап тоту**

2025 елда урам-юл челтәренең җыештырыла торган мәйданы 23,1 млн. кв. метрны тәшкил итте.

Ел нәтиҗәләре буенча, субподряд оешмаларын исәпкә алып, юл предприятиеләрендә 623 берәмлек махсуслаштырылган җыештыру техникасы, шул исәптән ел әйләнәсендә һәм кышкы режимда кулланыла торган 577 берәмлек универсаль техника, җәйге режимда кулланыла торган 46 берәмлек җыештыру техникасы, 32 берәмлек беркетелә торган җиһаз (роторлы кар көрәгеч, ком сипкеч) бар иде.

Чыгарылган кар I Порт, II Порт, Несмелов, Воровский, Гадел Кутуй, Васильченко, Техника урамнарындагы һәм Җиңү проспектындагы 8 кар эретү пунктында утильләштерелде.

Шәһәрдә ясалма корылмалардан файдалану өчен аларны тиешле хәлдә карап тотуны тәэмин итү максатыннан 71 автомобиль күпере, транспорт чишелеше һәм юлүткәргече, 6 тоннель, 17 җәяүлеләр күпере һәм 67 җир асты һәм җир өсте кичүләре карап тотылды.

51 мең куб метрдан артык күләмдәге калдыклар рөхсәтсез ташланган 258 урын Казан шәһәре бюджеты хисабына юк ителде.

**Һәйкәлләр**

2025 елда «“Кызыл капка” юбилей аркасы» мәдәни мирас объектын реставрацияләү эшләре башланды, «Карл Маркс бюсты» мәдәни мирас объектын саклау буенча фәнни-проект документациясе эшләнде.

**Юл челтәрен ремонтлау**

2025 елда Казанда юл челтәрен үстерүгә һәм ремонтлауга һәм ишегалды территорияләрен төзекләндерүгә барлыгы 21,43 млрд сум бүлеп бирелде (2024 елда – 45,3 млрд сум), шул исәптән «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында юлларны һәм күперләрне ремонтлауга1,76 млрд сум, тузган юл катламнарын ремонтлауга 6,0 млрд сум, 3,0 млрд сум Казан шәһәренең торак массивларында юлларны ремонтлауга, 6,4 млрд сум – урам-юл челтәрен, квартал эчендәге машина юлларын ремонтлауга, юл хәрәкәте иминлеген арттыру чараларына, яңгыр канализациясе челтәрләрен, тышкы яктырту челтәрләрен төзекләндерүгә, юл тамгалары салуга, бакча ширкәтләренә, Казан шәһәренең күп балалы гаиләләренә бүлеп бирелгән җир кишәрлекләренә керү юлларын ремонтлауга һәм чокырларны ремонтлауга, 4,27 млрд.сум – «Безнең ишегалды» программасын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелде.

2025 елда 250 дән артык юл участогы ремонтланды.

«Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында гомуми озынлыгы 7 км булган 12 юл участогына ремонт ясалды.

Товарищеская һәм Әмирхан Еники урамнарында юл өслеген ремонтлаудан тыш тротуарлар ремонтланды, велосипед юлы төзекләндерелде, юл хәрәкәте куркынычсызлыгы элементлары урнаштырылды, машина кую урыннары тәртипкә китерелде. Вишневский урамына тоташкан урында юл хәрәкәтен оештыру схемасы үзгәртелде, үткәрү мөмкинлеген арттыру өчен өстәмә хәрәкәт полосасы булдырылды. Моннан тыш, Центральная урамы белән киселештә җәяүлеләр кичүләре дә бар.

Сахалин урамын ремонтлау нәтиҗәсендә, асфальт-бетон өслекне алыштырудан тыш, бу урамның ике ягында да тротуарлар, җәмәгать транспорты тукталышы, юл хәрәкәтен оештыру элементлары булдырылды.

Галиәсгар Камал урамында, юл эшләреннән тыш, яктырту җайланмалары да куелды.

Курашов, Г.Кутуй, Журналистлар урамнары һәм Ямашев проспекты буенча эшләр барышында юл өслеге тулысынча яңартылды, юл хәрәкәте куркынычсызлыгының кирәкле элементлары урнаштырылды.

2025 елда «Яшәү өчен инфраструктура» илкүләм проекты буенча юл эшләре кысаларында Болак аша К.Нәҗми урамындагы күперләргә (Романов күпере) һәм Достоевский урамындагы юл үткәргечкә ремонт ясалды. Эшләр комплексында юл өслегеннән тыш таяныч конструкцияләрнең искергән элементлары алыштырылды, бу ясалма корылмаларны файдалануда куркынычсызлыкны тәэмин итәчәк.

Асфальт-бетон катламнары нык тузган юл участокларын норматив хәлгә китерү кысаларында 29 юл участогына ремонт ясалды. Болар – Кремль дамбасы, Г.Исхакый урамы, Сибгат Хәким урамы һәм башка юл участоклары. Ремонтның гомуми мәйданы 1 млн кв.метрдан артып китте.

Урам-юл челтәрен ремонтлау кысаларында 150 мең кв. метрдан артык мәйданда 22 юл участогына ремонт ясалды. Болар: Салмачы торак массивында – Крутовская, Центральная урамнары, Мирный торак массивында – 8 нче Дәүләки урамы, Северный торак массивында – Муса Бигиев урамы, Центральная урамнан ТЭЦ урамына кадәрге юл һәм башка юллар ремонтланды.

Хисап елында квартал эчендәге машина юлларының 68 участогына 1 млрд сумлык ремонт ясалды.

Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов карары буенча торак массивларда юлларны ремонтлау программасы буенча 2 млрд сумга ремонт эшләре башкарылды. 40 торак массивта 91 участок төзекләндерелде. Шул ук вакытта, халыкның ремонтка ихтыяҗы зур булу сәбәпле, торак массивлар юллары башка программаларга да кертелде. Гомумән алганда, 90 процентан артык тузган яки юл өслеге бөтенләй булмаган 102 урам юлы 3 млрд. сумга ремонтланды.

Юл объектларын төзү һәм реконструкцияләү кысаларында 2025 елда Киров районында җәяүлеләрнең имин хәрәкәте өчен Краснокшайск һәм Деловая урамнары киселешендә җәяүлеләр өчен җир өсте кичүе төзелде.

Идел буе районында яшәүчеләрне 18 нче поликлиникага, футбол манежына, «Горки» метро станциясенә кадәр йөри алуны тәэмин итү максатыннан Х.Мәүлүтев урамында җәяүлеләр өчен җир асты кичүен төзү эшләре тәгәлләнде.

Юл вәзгыятен яхшырту өчен Җиңү проспектыннан Оренбург тракты урамы буйлап шәһәрдән чыгу юнәлешендәге юл киңәйтелде.

Бакча ширкәтләренә керү урыннарын юллар белән тәэмин итү кысаларында узган ел 1 километрга якын озынлыктагы юл ремонтланды. Идел буе районының «Островок», «Мечта», «Ивушка», «Табигать», «Автомобилист», «50 лет Победы», «Волга ЗАО "Кварт"» бакча ширкәтләрендә һәм Авиатөзелеш районының «КМПО» ачык акционерлык җәмгыятенең коммерциягә нигезләнмәгән бакчачылык ширкәтенә караган 6 нчы күмәк бакчасында яңа юл өслекләре ясалды.

Барлыгы 6 ел эчендә 27 бакча ширкәтенә 25 км озынлыкта 19 керү юлы сузылды.

68 авария участогын (26 юл-транспорт һәлакәте концентрацияләнгән урын, юл-транспорт һәлакәте булырга мөмкин 16 участок, һәлак булучылар булган 9 юл-транспорт һәлакәте участогы, 17 авария зонасы) бетерү кысаларында 400 дән артык юл билгесе, куркынычсызлык киртәләре, 89 яктырткыч, 11 ясалма юл тигезсезлеге урнаштырылды, юл тамгалары һәм тавыш полосалары куелды.

2025 елда 400 мең кв. м мәйданда юл тамгалары ясалды.

**Ишегалды территорияләрен төзекләндерү**

2025 елда ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча «Безнең ишегалды» программасы эшен дәвам итә.

Программаны гамәлгә ашыру барышында хисап елында Казанда 466 ишегалды территориясендә комплекслы төзекләндерү эшләре башкарылды яисә гомуми мәйданы 590 мең кв. м булган асфальт-бетон өслекле 266 объект (2024 елда – 570 мең кв.м мәйданлы 459 ишегалды территориясе) төзекләндерелде.

Ишегалларында 5 мең өстәмә парковка урыны җиһазландырылды, 3 меңнән артык урам яктырту баганалары урнаштырылды, энергияне сак тотучы 4,5 мең яктырткыч куелды (2024 елда – 4,5 мең данә), 5 меңнән артык кече архитектура формасы урнаштырылды.

Гомумән алганда, 2025 елда юл эшләрен башкару нәтиҗәләре буенча Казан урамнарының һәм ишегалларының 2,5 млн кв.м асфальт өслеге ремонтланды (2024 елда – 2,4 млн кв. м).

**Урамнарны яктырту**

Урамнарны яктырту системасын норматив хәлдә тоту буенча агымдагы карап тоту кысаларында уздырыла торган чаралар нәтиҗәсендә 2025 елда магистральләр, урамнар һәм ишегалды территорияләренең яктыртылуы 95 процент норматив белән 94,8 процент тәшкил итте.

Хисап елы нәтиҗәләре буенча 35 470 яктылык ноктасы (шул исәптән 24 555 данә – архитектур яктан яктырту нокталары) муниципаль милеккә кабул ителде һәм ел ахырына муниципаль казна составында аларның саны 187 063 данәгә житте (2024 елда – 151 593 данә), урам яктырту челтәренең озынлыгы 3 758 км тәшкил итте (2024 елда – 3 603 км).

Яктырту нокталары саны шәһәрнең торак массивларында урнаштырылган, юл инфраструктурасы объектларын, торак микрорайоннарны төзү һәм реконструкцияләү белән комплекслы рәвештә төзелгән тышкы яктырту челтәрләрен файдалануга тапшыру, ишегалды территорияләрен төзекләндерү нәтиҗәсендә артты.

**Яңа ел бизәлеше**

Шәһәрне яңа елга бизәү алдагы ел объектларының яңа ел бизәлешен торгызу кысаларында башкарылды. «Казан» гаилә үзәге янындагы мәйданчыкта динамик утлар белән бизәлгән һәм музыкаль утлы шоу уздыру өчен анимацияле гөмбәзе булган 35 метр биеклектәге үзәк чыршы урнаштырылды һәм яңа ел ярминкәсе оештырылды.

Шәһәр урамнары яңа елга бизәлде: Меңьеллык мәйданында һәм Тинчурин скверы территориясендә «2024» саннары рәвешендәге конструкцияләр, Кремль һәм Лобачевский урамнары буйлап терәкләр, Меңьеллык мәйданында «Таҗ» инсталляциясе, Кәрим Тинчурин исемендәге театр каршындагы мәйданда «Лилия» композицияләре, М.Вахитов һәйкәле

янында «Каскад» иллюминациясе, Пушкин урамында «Чыршылар» һәм «Кар бөртекләре» конструкцияләре, Николай Ершов – Гвардия урамнарындагы мәйданда «Җәннәттәге алма агачы» конструкциясе, Универсиада проспектында терәкләр куелды. Шулай ук Оренбург Тракты урамындагы Танк училищесы буендагы койма, Болак елгасы аша күперләр, Танк боҗрасы районындагы җир өсте кичүе, Академик Парин урамындагы транспорт боҗрасы бәйрәмчә бизәлде. Шулай ук Карл Маркс һәм Вишневский, Николай Ершов урамнарында да утлы консольләр урнаштырылды. Казан шәһәре Үзәк мәдәният һәм ял паркының керү урыны янында «Арка», «Күркәләр», «Бүләкләр» яктылык композицияләре һәм гирляндалар урнаштырылды, ә Котельников скверы янында декоратив яктылык коймалары куелды.

Бауман урамында, «Черек күл» паркында, Кремль урамында Чернышевский урамыннан Беренче Май мәйданына кадәр, Ирек мәйданында яктылык конструкцияләре торгызылды.

Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләрендәге: Үзәк мәдәният һәм ял паркындагы, Урицкий, «Черек күл», «Крылья Советов», Сыртланова урамындагы «Калейдоскоп», Гаврилов урамындагы «Континент», Дербышки торак массивының Мир урамындагы «Комсомолец» паркларындагы, «Салават Күпере» (2 нче чират), «Светлая долина» торак комплекслары паркларындагы, Аксенов, Тинчурин скверларындагы, Әпсәләмов урамындагы «Ак чәчәкләр», Татарстан Республикасының төзелеш тармагы барлыкка килүенең 100 еллыгы исемендәге скверлардагы, Горки-Әмәт урман-паркындагы, Лядской һәм Балыкчы бакчаларындагы, Юлиус Фучик урамындагы бульвардагы һәм Кремль яр буендагы, Филармония янындагы сквердагы, «Чулпан» мәдәният үзәге янындагы һәм «Авангард» скверындагы территорияләр яңа елга бизәлде.

Элек куелган консольләр Ленин дамбасыннан Киров дамбасына, шулай ук «Аюлар» һәм «Чыршы» композицияләре «Әкият» курчак театры территориясеннән Меңьеллык паркына күчерелде.

Мөштәри урамында, Ленин дамбасында, Н.Назарбаев урамында, Г.Камал исемендәге яңа театр бинасы янында яңа ел элементлары урнаштырылды, «Елмай» паркында павильон һәм пергола бизәлде, «Зилант» скверы территориясендә 10 метр биеклектәге яңа ел чыршысы куелды.

**Яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен карап тоту**

2025 елда яңгыр канализациясе челтәрләренең озынлыгы 5,6 километрга, ә гомуми озынлыгы 517,3 километрга кадәр артты. Урам-юл челтәрен, шулай ук торак комплексларын реконструкцияләү һәм төзү кысаларында төзелгән челтәрләр муниципаль милеккә кабул ителде.

Яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен карап тотуга республика бюджетыннан бүлеп бирелгән 30 млн сум күләмендәге акчалар хисабына 3,1 км магистраль челтәрләр чистартылды һәм аларның үткәрүчәнлеге торгызылды (2024 елда – 90 млн сумга 13,5 км).

Яңгыр канализациясе челтәрләрендә җитмәгән яки яраксыз хәлгә килгән элементлар ачыкланган саен аларны торгызу эшләре башкарылды. Бер ел эчендә 600 дән артык яңгыр суларын кабул итү һәм карап тикшерү коелары норматив хәлгә китерелде.

Яңгыр сулары канализациясен су объектларына чыгару урыннарында 28 чистарту корылмасын агымдагы карап тоту һәм эшкә яраклылыгын тәэмин итү чаралары башкарылды. Урам-юл челтәрен һәм торак төзелешен үстерү кысаларында төзелгән тагын 2 чистарту корылмасы муниципаль милеккә кабул ителде.

2025 елда Идел буе районы Салмачы торак массивының Гостеприимный юлы һәм Камышлы урамнары буенча яңгыр сулары канализациясе челтәрләрен төзү эшләре башкарылды.

Юл фонды акчалары хисабына Х.Мәүлүтев урамындагы магистраль торба үткәргечне ремонтлау һәм яңгыр канализациясе челтәрләрен һәм 103 номерлы рус-татар мәктәбе янында (Адоратский урамы, 41А йорт) яңгыр канализациясе челтәрләрен төзү эшләре башкарылды.

Пушкин һәм Карл Маркс урамнарында су чыгаруның өстәмә элементларын урнаштыру эшләре башкарылды.

**Җәмәгать урыннарын төзекләндерү**

2025 елда гомуми бәясе 1 785,6 млн сумлык 8 җәмәгать киңлеге (2024 елда Г.Камал исемендәге театрның яңа бинасы янындагы паркны төзекләндерүгә бүлеп бирелгән акчаларны исәпкә алып), шулардан «Уңайлы шәһәр мохитен булдыру» федераль проекты кысаларында гомуми бәясе 375,0 млн. сумлык 3 объект, Татарстан Республикасы бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчалары исәбеннән гомуми бәясе 1 410,6 млн. сумлык 5 объект төзекләндерелде.

«Уңайлы шәһәр мохитен формалаштыру» федераль проекты кысаларында түбәндәге объектлар төзекләндерелде:

- Серов урамындагы бульварны төзекләндерүнең 3 нче чираты (тукталыш пунктыннан сулыкка кадәр): ял итү урыннары белән «урман фатиры», ишарәләр теле дәресләре өчен киңлек, халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркемнәре өчен махсус кисмәкләр урнаштырылган җәмәгать бакчасы һәм су белән уйнау мәйданчыгы, шулай ук халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркемнәре өчен велосипед юлы төзелде, экопавильон куелды;
- Акчарлак күлләрендә эшләр дәвам итте: Зур Акчарлак күленә караган тагын бер күзәтү мәйданчыгы төзелде һәм тирә-ягы комплекслы яшелләндерелде, Кече Акчарлак күле янындагы паркка кече архитектура формалары куелды;
- «Зилант» скверында фонтан торгызылды, гранит эшләре башкарылды, баскыч мәйданчыкларында һәм төшү урыннарында брусчатка җәелде, эскәмияләр һәм чүп савытлары куелды, территория яшелләндерелде. Фонтан үзәгендә бронзадан «Зилант-Саклаучы» скульптурасы урнаштырылды, ә ике

яктырту баганасында берәр кече Зилант куелды. Скверның керү төркемендә килүчеләрне Татарстанның милли символларының берсе булган ике скульптуралы лалә чәчәге каршы ала.

Республика акчасы һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына түбәндәге объектлар төзекләндерелде:

- Г.Камал исемендәге театрның яңа бинасы янында балалар мәйданчыгын төзү дәвам итте. Барлык уен элементлары тематик яктан Түбән Кабан күле фаунасы белән бәйле, мәйданчыкта беренче булып җирле кош – соры челән рәвешендәге динамик уен җиһазлары барлыкка килде.

Территория төрле яшьтәге балалар һәм өлкәннәр өчен 8 тематик зонаны үз эченә ала, алар арасында: агачлар яшеллегендә урман фонтаны, су каналлары системасы булган интерактив су өстәле. Мәгърифәтчелек һәм музыка сукмаклары, яктылык эффектларын кулланып иҗади куелышлар өчен театр сәхнәсе барлыкка килде.

– федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты – һәлак булган сугышчыларга Казансу елгасында куелган һәйкәл-гыйбадәтханәне реконструкцияләү белән бер үк вакытта аңа илтүче территория төзекләндерелде (яктырткычлы җәяүлеләр күпере, туристик автобуслар өчен һәм халыкның хәрәкәтләнүе чикле төркемнәре өчен парковка төзелде, парковкадан храмга илтүче баскыч ремонтланды, храм хезмәткәрләре ихтыяҗлары өчен павильон куелды һәм өстәмә җәяүле юллар ясап һәм яктырткычлар куеп, янәшәдәге территория төзекләндерелде);

– Җиңү паркында махсус хәрби операциядә катнашучылар истәлеген мәңгеләштерү өчен мемориаль таш салынды. Киләчәктә паркта мемориаль зонаны төзекләндерү планлаштырыла;

– 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү кысаларында фронтовик шагыйрь Фатыйх Кәримгә һәйкәл куелды һәм Декабристлар урамындагы Яшьләр скверының бер өлеше төзекләндерелде. «Салават Күпере» микрорайонындагы 188 номерлы күппрофильле «Бионика» лицее янындагы территория төзекләндерелде, скверда Бөек Ватан сугышы ветераны һәм танылган хәрби теоретик генерал Мәхмүт Гәрәевка бюст куелды.

**Яшелләндерү**

2011 елда Казанда шәһәрне яшелләндерү һәм төзекләндерү буенча системалы эш башланган вакыттан алып паркларның һәм скверларның гомуми мәйданы 4,7 тапкырга – 132 гектардан 625 гектарга кадәр артты. Шәһәрнең җәмәгать киңлекләре саны 1,5 тапкырга – 115 тән 170 кә кадәр артты.

2025 елда яшел үсентеләрнең гомуми мәйданын, Казан шәһәрен яшелләндерү процентын бәяләү буенча фәнни-тикшеренү эше башланды. Тикшерү нәтиҗәләре шәһәр территориясенең экологик торышын бәяләргә, микроклимат белән бәйле проблемалы аспектларны идентификацияләргә һәм проблемаларны хәл итү өчен рекомендацияләр эшләргә мөмкинлек бирәчәк. Бу эшләрне 2026 елның 1 кварталында тәмамлау планлаштырыла.

2025 елда 8,0 мең кв.метрдан артык мәйданда 43 урам чәчәкләр белән бизәлде. 0,5 млн данә чәчәк үсентесе утыртылды. Пушкин, Лобачевский, Николай Ершов, Оренбург Тракты урамнары, Павлюхин, Бауман урамы һәм башка урамнар чәчәк түтәлләре белән бизәлде. Шәһәрнең төп магистральләре буйлап – Кремль, Вишневский, Н.Ершов, Павлюхин, Оренбург Тракты урамнарында, Болак ермагы аша күперләрнең коймаларында меңнән артык чәчәк кашполары эленде. Моның өчен 14 мең ампель петуния кулланылды. Бу безнең урамнарга, туристлык маршрутларына һәм ял урыннарына матурлык өстәде.

Шулай ук шәһәрнең төрле өлешләрендә 63 чәчәк фигурасыннан торган 22 күләмле композиция («ФИФА дивары», «Бутса», «Ләкләк», «Чәчәк агачы», «Могҗизалар илендә Алиса», «Туп», «Барс», «Аккошлар, «Шарлар» һәм башка фигуралар) урнаштырылды.

3 683 га мәйданда «Аккош күле» шәһәр урманының җирле әһәмияттәге махсус саклanучы табигый территориясен карап тоту башкарылды. Эшләр һәм предприятие, оешма, учреждениеләрнең хезмәт коллективларын һәм халыкны җәлеп итеп төрле акцияләр үткәрү кысаларында территорияне чистарту, авария хәлендәге агачларны җыештыру, янгынга каршы полосалар ясау, давыл нәтиҗәләрен бетерү эшләре оештырылды.

Кунакчыллык маршрутларын, күпләп ял итү урыннарын, юл объектларын яшелләндерүне дә кертеп, 2025 елда яшелләндерү кысаларында компенсация рәвешендә 24,8 мең агач һәм 16,8 мең куак (2024 елда – 56 мең агач һәм 41 меңнән артык куак) утыртылды.

**2026 елга планнар:**

1. «Яшәү өчен инфраструктура» программасы буенча юлларны капиталь ремонтлау.
2. Юл-транспорт һәлакәтләре күп була торган урыннарны бетерү эшләрен дәвам итү.
3. Җәмәгать урыннарын һәм массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерү һәм үстерү чараларын гамәлгә ашыруны дәвам итү.
4. Шәһәрне чәчәкләр белән ландшафтлы итеп бизәүне дәвам итү.
5. «“Кызыл капка” юбилей аркасы» мәдәни мирас объектын реставрацияләү эшләрен дәвам итү.
6. «Карл Маркс бюсты» мәдәни мирас объектын реставрацияләү эшләрен башкару.
7. Җиңү проспектындагы «Гадел хөкем академиясе» тукталышында җир өсте җәяүлеләр кичүендә ремонт эшләре башкару.

## Төзекләндерү өлкәсен контрольдә тоту чаралары

2025 елда төзекләндерү өлкәсен контрольдә тоту эше дәвам итте.

2025 ел башыннан 25 971 материал төзелде, бу 2024 ел белән чагыштырганда 27 процентка күбрәк (2024 елда – 20 437 материал). Материалларның шактый өлеше (22 254) автомат режимда теркәлде.

Шәһәр территориясен көндәлек мониторинглау барышында 3 717 материал рәсмиләштерелде, шул исәптән 2 680 беркетмә төзелде, 693 кисәтү белдерелде, 344 күрсәтмә бирелде.




Ачыклана торган хокук бозуларның еш очрый торган төр составы (яшелләндерелгән территорияләрдә машина куюны исәпкә алмыйча) таблицада күрсәтелде.

| Хокук бозу төре | Материаллар саны |
|---|---|
| Мәгълүмати-басма продукция һәм тышкы мәгълүмат чаралары | 608 |
| Җир эшләре | 605 |
| Фасадларны һәм керү урыннарын карап тоту | 434 |
| Территорияне карап тоту | 371 |
| Шлагбаумнар һәм коймалар | 237 |
| Төзелеш объектларын карап тоту | 199 |
| Башкалар | 1 263 |
| **БАРЛЫГЫ** | **3 717** |

Хокук бозуларны профилактикалау буенча эш дәвам итә. Чаралар профилактик визит һәм консультация форматында уздырыла: төзекләндерү объектларын кышкы һәм җәйге чорда карап тотуга таләпләр аңлатыла, булырга мөмкин булган хокук бозулар ешрак әйтелә, сорауларга җаваплар бирелә. 2025 елда 35 профилактик визит, 10 консультация үткәрелде.

«Дозор-М3» автомат рәвештә теркәү программа-аппарат комплекслары ярдәмендә автомобильләрне газоннарга, балалар, спорт һәм хуҗалык мәйданчыкларына, шулай ук контейнер мәйданчыкларына урнаштыруның

22 254 очрагы теркәлде һәм Казан шәһәре административ комиссиясенә карап тикшерүгә тапшырылды.

Кикшеринг өлкәсендә тәртип урнаштыру эше алып барылды. 2025 елда 4 рейд үткәрелде, билгеләнгән парковка зоналарыннан читтә куелган 940 самокат алынды. Операторларга карата 84 беркетмә төзелде.

2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы федераль законга кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, 2025 елда җәмәгать судьяларына РФ Административ хокук бозулар кодексының 19.5 статьясында каралган административ хокук бозулар турында 127 беркетмә җибәрелде, шулардан 100 беркетмә Казан шәһәре Башкарма комитеты файдасына каралды; хокук бозуларны бетерү бурычын йөкләү турында 25 дәгъва гаризасы бирелде, шуларның 4 се канәгатьләндерелде, 4 се буенча хокук бозулар бетерелде, калганнары карала; 6 суд актына шикаять бирелде, шуларның 3 се үзгәрешсез калдырылды, аларга карата кассация шикаятьләре бирелде, аларның берсе канәгатьләндерелде, калганнары карауда.

Хисап елында Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча зур эш башкарылды, алар Казан шәһәре Думасының 2025 елның 17 декабрендәге 6-4 номерлы карары белән расланды.

2026 елда тышкы төзекләндерү өлкәсендә норматив хокукый актларның үтәлешен контрольдә тоту буенча планлы эш дәвам итәчәк, кешеләр күпләп җыела торган урыннарга, шәһәр халкының имгәнүен кисәтү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелде.

**2025 елда административ закон бурычларын үтәү, төзекләндерү өлкәсендә тәртипне тәэмин итү эше дәвам иттерелде, бу шәһәребездә уңайлы һәм куркынычсыз яшәүнең мөһим өлеше булып тора.**

Контроль органнары беркетмәләре буенча Казан шәһәренең административ комиссияләре тарафыннан түбәндәге санда карарлар чыгарылды:

| 2021 ел | 2022 ел. | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|
| 15 473 | 15 050 | 13 849 | 10 965 | 15 957 |

Шул ук вакытта Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган төп хокук бозулар: территорияләрне төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне бозу – 3 361, урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу – 3 231, яшелләндерелгән территорияләрдә автомобильләр кую – 5 127, тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу – 2 113, муниципаль хокукый актларны үтәмәү – 1 865.

2025 елда хокук бозуларны бетерү буенча дәгъвалау эше дәвам итте. Хисап чорында төзекләндерү өлкәсендәге таләпләрне бозуны вакытында төзәтмәгән затларга карата 156 эш кузгатылды. 50 проценты (78) хокук бозулар судка кадәр дәгъвалардан соң, 27 – дәгъвалар судка җибәрелгәннән соң төзәтелде.

Дәгъва белдерелә торган эш алып барыла торган хокук бозуларның төп төрләре: адрес күрсәткечләрен рәсмиләштерүне һәм билгеләүне регламентлый торган нигезләмәне бозу, мәгълүмати-басма продукциядән чистартмау, җир эшләрен башкарганда хокук бозулар, тиешле килештерүсез урнаштырыла һәм файдаланыла торган тышкы мәгълүмат чаралары.

## СТАТИСТИКА 2023-2025




Административ эшләрнең иң күп саны (94%) комиссияләр тарафыннан махсус техник чаралар кулланып ачыкланган хокук бозуларны автоматик теркәү материаллары буенча карала:

- түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалану тәртибен бозу – 249 442;

- транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү мәйданчыкларында, шулай ук йорт яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру – 11 703;

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан файдалану тәртибенә карата таләпләрне бозу (кузовтагы (контейнердагы) коелучан йөкләрне, чүп-чарны, җиңел савытларны, киселгән агач-ботакларны, яфракларны брезент яисә башка материал белән капламыйча йөк транспорт чарасын эксплуатацияләү) – 171;

- җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү буенча муниципаль кагыйдәләрне, калдыклар белән эш итү буенча муниципаль кагыйдәләрен бозу (контейнер мәйданчыгына бару юлларын транспорт чарасын куеп томалау) – 199;

- транспорт чаралары хуҗалары тарафыннан әлеге максатлар өчен билгеләнмәгән урында чүп-чар ташлау – 101.

2025 елда РФ Эчке эшләр министрлыгының Дәүләт автоинспекциясе белән хезмәттәшлегенең яңа схемасы гамәлгә ашырылды: транспорт чаралары милекчеләре турында мәгълүматны тулысынча автомат режимда алу буенча ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы кертелде. 2025 елда кеше катнашыннан башка 255 060 запрос эшкәртелде.

Моннан тыш, комиссияләр тарафыннан кулланыла торган мәгълүмат-аналитика системасы Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәте һәм Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасы белән интеграцияләнде. Бу бина түбәләрен кардан һәм боздан вакытында чистартмаган, граффити ясалган, шулай ук бина һәм корылмаларның фасадларын тиешенчә карап тотмаган өчен автомат рәвештә фиксацияләү материаллары буенча карарлар чыгарырга мөмкинлек бирәчәк.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, 2024 елда административ комиссияләр эшенә Telegram мессенджерында кертелгән чат-бот ярдәмендә гражданнар оператив рәвештә штрафлар булу-булмавы турында мәгълүмат, административ хокук бозу турындагы эш буенча җентекле мәгълүмат ала, хокук бозуларның фотоларын, урыны, түләү вакыты һәм сроклары турында мәгълүматларны күрә, шулай ук яңа штрафлар турындагы хәбәрнамәләргә языла ала. 2025 ел ахырына инде 89 792 уникаль кулланучы һәм 10 216 актив язылу бар.

Контроль системасын үстерү кысаларында 2026 елда Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләрен бозуның автомат рәвештә теркәләчәк категорияләре санын арттыру планлаштырыла.

## Шәһәр пассажир транспорты

2025 елда халыкка сыйфатлы һәм уңайлы транспорт хезмәте күрсәтү, куркынычсыз юл хәрәкәте оештыру Казан шәһәре халкына транспорт хезмәте күрсәтү өлкәсендә эшнең төп юнәлешләре булып калды.

Бүгенге көндә Казан шәһәренең шәһәр эчендәге пассажир транспортының комплекслы маршрут челтәре дүрт транспорт төреннән тора, анда түбәндәгеләр керә:

- 54 автобус маршруты, аларда 608 берәмлек хәрәкәттәге состав һәм 13 берәмлекле 6 сезонлы маршрут (гомуми озынлыгы 1,0 мең км) кулланыла;
- 240,45 км озынлыктагы юлда 90 трамвай йөри торган 9 трамвай маршруты;
- 275,14 км озынлыктагы юлда 139 троллейбус йөри торган 11 троллейбус маршруты;
- 11 станциядән торган 18,2 км озынлыктагы бер метрополитен линиясе. Анда 15 электр поезды (51 вагон) составы хезмәт күрсәтә.

2025 елда 223,4 млн пассажир йөртелде, бу 2024 ел күрсәткеченнән 1,3 процентка кимрәк булды. 2025 елда ташламалы категорияле гражданнар тарафыннан башкарылган транспортта йөрүләр саны 2024 ел дәрәҗәсенә карата 1,6 процентка артты һәм 72,9 млн йөрү тәшкил итте (2024 елда – 71,8 млн йөрү). Казан шәһәрендә ай саен уртача 114 меңнән артык ташламалы транспорт картасы тулыландырыла, алар буенча 6 млн сәфәр башкарыла.




Муниципаль унитар предприятиеләр өлешенә гомуми пассажир йөртү күләменең 89 проценты туры килә (2024 елда – 87,6%). «ПАТП №2» муниципаль унитар предприятиесе иң эре пассажирлар йөртүче булып тора, пассажирлар йөртүнең гомуми күләменнән аның өлеше 52,6 процентны тәшкил итә. «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе – 36,4 процент.

Иң күп пассажирлар йөртү автобуслар белән башкарыла – 63,6 процент (якынча 142,1 млн пассажир).

2025 елда шәһәр электр транспортында 81,3 миллионнан артык пассажирга хезмәт күрсәтелде, ягъни пассажирлар йөртүнең гомуми күләменең 36,4 проценты, шул исәптән:

- трамвайларда – 15,8 млн пассажир (гомуми йөртү күләменең 7,1 проценты);
- троллейбусларда – 26,1 млн пассажир (гомуми йөртү күләменең 11,7 проценты);
- метрополитенда 39,4 млн пассажир (гомуми йөртү күләменең 17,6%).




Шәһәрдә файдаланылучы автобус паркының уртача яше – 6 ел, трамвайларныкы – 9,9 ел, троллейбусларныкы – 7,4 ел.

2025 елда «НефАЗ» маркалы 30 автобус сатып алынды.

«Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе көче белән хисап елында контакт челтәре яңадан төзелде һәм реконструкцияләнде, шулай ук юл хуҗалыгы реконструкцияләнде, авария хәлендәге баганалар сүтелде һәм яңа терәк баганалар урнаштырылды.

2025 елның 1 маеннан ачылган 11 номерлы яңа троллейбус маршрутында «Г.Тукай исемендәге сквер – Танк училищесы» маршрутында «Казан зооботаника бакчасы», «Юстиция кварталы», «Танк училищесы» яңа тукталыш пунктлары оештырылды. 6 номерлы троллейбус маршруты хәрәкәте «Г.Тукай исемемендәге сквер – В.Кулагин урамы» элек расланган схема буенча югарыда күрсәтелгән тукталыш пунктларына кермичә генә яңартылды.

2025 елда шәһәрдә пассажирлар агымы зур булган эре тукталыш пунктларында барлыгы 354 электрон мәгълүмат таблосы эшләде.

Казан шәһәренең шәһәр пассажирлар транспортында йөрү өчен автоматлаштырылган түләү системасын үстерү эше дәвам итә. Транспорт картасын гамәлгә кертә башлаганнан бирле барлыгы 3,1 миллионнан артык электрон юл билеты чыгарылды. Бүгенге көндә Казан шәһәрендә транспорт карталарын тулыландыра торган 352 пункт эшләп килә.

Пассажирлар уңайлылыгы һәм транспорт предприятиеләренең чыгымнарын оптимальләштерү өчен, җир өсте электр транспортының барлык хәрәкәттәге составында һәм 99 автобуста юл өчен түләүнең кондукторсыз системасы кертелде. 2026 елда автобус паркының хәрәкәттәге составында әлеге системаны гамәлгә кертү эше дәвам итәчәк.

2025 елда 3 700 юл билгесе урнаштырылды һәм тиешле таләпләргә туры китерелде, 121 светофорлар белән идарә итү шкафы буялды, светофор объектларының төзексезлеге буенча 1 560 гариза эшкәртелде, «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша кергән 1 745 гариза канәгатьләндерелде.

2025 елда муниципаль юл фондында калган акчалар исәбенә авария куркынычы булган 3 участок светофор объектлары белән җиһазландырылды.

Бүгенгә 501 светофор объектының 258 е юл хәрәкәте белән идарә итүнең адаптив системасына тоташтырылды.

Казан шәһәрендә бердәм шәһәр парковка мәйданнары системасы эшләп килә. 2025 елның ахырына урам-юл челтәре буйлап урнашкан 249 участокта 13 446 парковка урыны оештырылды. Парковкага түләү өчен 101 паркомат урнаштырылды, видеофиксация комплекслары урнаштырылган 41 автомобиль, 34 стационар камера һәм 5 кул комплексы эшләде.

Хокук бозучы автомобиль хуҗаларын административ җаваплылыкка тарту максатыннан тәгәрмәчләргә блокаторлар кую эше дәвам итте. Кабул ителгән чаралар нәтиҗәсендә дәүләт номерлары салдырылган автомобильләр кую саны берәмлекләрдә генә исәпләнә.

2025 елда Казан шәһәрендә 7 300 берәмлек электросамокаттан һәм 190 берәмлек велосипедтан станциясез вакытлыча файдалану сервислары эшләде.

Муниципаль парковка урыннарында ташламалы машина кую хокукы бирелгән каршеринг автомобильләре сервисы эшен дәвам итте. Ел ахырына 1 191 каршеринг автомобиле реестрга кертелде.

Муниципаль парковкаларда электромобильләр өчен ташламалар бирелә, ел ахырына 1 163 электромобиль реестрга кертелде.

**2026 елга планнар:**

- Казан шәһәре халкына транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын арттыру һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;
- парковка урыннары зоналарын киңәйтү;
- хәрәкәт составын яңарту;
- автобус маршрутларында йөрү өчен түләүнең кондукторсыз системасына күчә бару;
- светофор объектларын юл хәрәкәте белән идарә итүнең адаптив системасына тоташтыру;
- яңа светофор объектларын урнаштыру.

## Тышкы реклама

2025 елда тышкы реклама һәм мәгълүмат өлкәсендә төп бурычлар булып түбәндәгеләр торды:

- Казан шәһәре бюджетына реклама эшчәнлегеннән кергән керемнәрнең планлы күрсәткечләрен тәэмин итү;
- реклама корылмаларын урнаштыруны контрольдә тоту һәм төзелгән килешү шартларының үтәлешен контрольдә тоту буенча эш;

- рөхсәтсез куелган тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын, шул исәптән муниципаль милек объектларында да, ачыклау һәм аларны сүтү (законлаштыру) чараларын үткәрү;

- сити-форматтагы реклама корылмалары челтәрен үстерү проекты буенча эш;

- реклама корылмаларының эчтәлеген онлайн мониторинглау мөмкинлеген бирүче сити-софт программасын кертү буенча эш, шулай ук ачыкланган хокук бозулар буенча аларның хуҗаларына автоматик режимда таләпләр җибәрү.

**Керемнәр**

2025 ел нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре бюджетына 314,03 млн сум керем керде, шул исәптән 308,32 млн сум – реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә төзелгән килешүләр буенча, 3,35 млн сум – рөхсәтләр биргән өчен түләнгән дәүләт пошлиналары буенча һәм 2,367 млн сум – килешүләр буенча йөкләмәләрне вакытында үтәмәгән өчен пенялар.

**Социаль реклама**

Хисап чорында социаль реклама урнаштыру турында 162 мөрәҗәгать карап тикшерелде. 129 социаль программаны урнаштыруда ярдәм күрсәтелде, бу 2024 ел күрсәткечләреннән 1,16 тапкырга артыграк. Актуаль иҗтимагый тематикаларны яктырту өчен 1 635 тән артык реклама өслеге – түбәле тукталыш корылмаларындагы реклама панеленнән алып эре форматлы медиафасадларга кадәр файдаланылды.

**Гамәлгә ашырылган проектлар**

2025 елда төп казанышларның берсе – реклама корылмасы белән берләштерелгән яңа заманча түбәле тукталыш корылмаларын урнаштыру һәм аларны файдалану хокукына сатулар үткәрү булды. 2 коммуникация күрсәткече, түбәле 13 реклама корылмасы, муниципаль түбәле тукталыш корылмалары составында 36 реклама панеле һәм 1 яңа төр конструкция – җылы реклама павильоны урнаштыру хокукы уйнатылды.

Хәзерге вакытта 473 тукталыш корылмасына реклама фирмалары хезмәт күрсәтә, бу Казан шәһәре территориясендә урнаштырылган барлык тукталыш корылмаларының якынча 1/3 өлешен тәшкил итә.

**Рөхсәтләр бирү**

2025 елда реклама корылмаларын урнаштыруга һәм файдалануга 60 рөхсәт бирелде (түбәле муниципаль тукталыш корылмаларында 35 реклама панеле, 13 тукталыштагы түбәле реклама корылмалары, 1 тукталыштагы реклама павильоны, 6 медиафасад, 1 видеоэкран, 2 коммуникация күрсәткече, 2 түбәле җайланма).

Шулай ук пилон, афиша корылмасы, медиафасад, видеоэкран, түбәле корылма һәм муниципаль түбәле тукталыш корылмасында реклама панеле урнаштыруга 6 рөхсәт гамәлдән чыгарылды.

Элгрәк бирелгән рөхсәт кәгазенә 797 үзгәреш кертү килештерелде, шул исәптән килешүләрнең гамәлдә булу вакыты озайтылуга бәйле рәвештә 794 реклама корылмасы буенча рөхсәтләрнең гамәлдә булу вакыты үзгәртелде.

**Реклама корылмаларын урнаштыруны контрольдә тоту**

Ел дәвамында реклама корылмалары урнаштыру һәм файдалану килешүләре шартларының үтәлешен контрольдә тоту эше алып барылды, шулай ук Казан шәһәрен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә реклама корылмалары белән берләштерелгән түбәле тукталыш корылмаларын карап тоту мәсьәләләренә зур игътибар бирелде.

Реклама корылмаларын урнаштыруны контрольдә тоту эше кысаларында, реклама корылмаларының агымдагы эчтәлеге буенча таләпләрне дә кертеп, хокук бозуларны бетерү турында барлыгы 465 таләп җибәрелде. Куелган таләпләрнең үтәлеше планлы йөреп тикшерүләр кысаларында контрольдә тотыла.

Шулай ук ел дәвамында муниципаль җир кишәрлекләрендә тиешле рөхсәте булмаган законсыз тышкы мәгълүмат чараларын – стелалар һәм флаглы композицияләрне ачыклау һәм сүтү буенча планлы эш алып барылды. Автосалоннар, азык-төлек кибетләре һәм тиз туклану рестораннары челтәрләре, автомобильләргә ягулык салу станцияләре контрольгә алынды.

Хисап елында транспорт чараларын бары тик яки күбесенчә реклама корылмалары сыйфатында гына куллануга бәйле хокук бозуларны ачыклау буенча эш дәвам итте. 44 автомобиль ачыкланды, шуларның 14 е алынды, 14 е буенча материаллар Монополиягә каршы федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырылды, 16 сы буенча материалларны вәкаләтле органга тапшыру өчен мәгълүмат җыю бара.

**2026 елга планнар:**

- 2026 елда Казан шәһәре бюджетына реклама эшчәнлегеннән алынган керемнәрнең планлы күрсәткечләрен тәэмин итү;
- реклама корылмаларын урнаштыруны контрольдә тоту, төзелгән килешү шартларының үтәлешен контрольдә тоту эше;
- түбәле тукталыш корылмаларын һәм шәһәр мәгълүмат панельләрен кертеп, сити-форматтагы реклама корылмалары челтәрен үстерү проекты буенча эшләү;
- реклама корылмалары эчтәлегенә онлайн мониторинг алып барырга мөмкинлек бирә торган сити-софт программасы буенча эшләү.

## Җирләү эше өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру

Җирләү эше өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне гамәлгә ашыру Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегенең бер юнәлеше булып тора.

2025 елда «Мирный» һәм «Самосырово» зиратларының мәгълүматларын цифрлаштыру үткәрелде. Бүгенге көндә Казан шәһәрендәге барлык зиратларның гомуми мәйданының 63,5 проценты яки 10 зират цифрлы форматка күчерелде.

Республика бюджеты хисабына «Курган» җеназа комплексының квартал эчендәге машина юлларына асфальт җәелде, бу участокларга, шул исәптән хәрбиләр каберлекләренә дә уңайлы килү мөмкинлеген тәэмин итте. Барлыгы 22,075 мең кв. м территориягә асфальт салынды, эшләрнең бәясе 146 226,056 мең сум тәшкил итте.

Зиратларны карап тоту буенча планлы чаралар үткәрелде. Казанның «Арча» зиратында иганәчеләр ярдәме белән яңа санитария узелы урнаштырылды.

**2026 елга планнар:**

- 12 зират цифрлаштырылды: «Архиерейск», «Борисоглебский», «Вознесенское», «Кадыш», «Киндери», «Красная горка», «Савин», «Яңа Сосновка», «Окольная», «Отар», «Салмачы. Мөселман», «Салмачы. Православие»;
- Архангельск зиратының хәрби өлешендә тумбаларны өлешчә алыштыру;
- Арча зиратында 106 тумбаны алыштыру;
- Кадыш һәм Борисоглебкий зиратларында асфальтланган керү юлларын төзү.

Җирле үзидарә милкенең нигезен муниципаль милек тәшкил итә. Хәзерге вакытта Казан шәһәре муниципаль милкендә гомуми баланс бәясе 417,25 млрд сумлык күчемле һәм күчемсез милек бар, ул муниципаль учреждениеләргә, унитар предприятиеләргә беркетелгән һәм дә Казан шәһәре милке казнасын тәшкил итә.

Монополиягә каршы реформа кысаларында үткәрелгән чаралар нәтиҗәсендә 2025 елда Казанда җиде муниципаль унитар предприятие гамәлдә булды, шуларның икесе үз оештыру-хокукый формасында сакланды («Водоканал» һәм «Метроэлектротранс») һәм бишесен хуҗалык җәмгыятьләренә үзгәртеп кору вакыты озайтылды («ПАТП №2», «Шәһәрне төзекләндерү», «Шәһәр күперләре», «Казан шәһәре Киров районының Юл ремонтлау-эксплуатацияләү идарәсе», «Горводзеленхоз» тресты).

Казан шәһәрендә банкротлык стадиясендә булган муниципаль предприятиеләр юк.

**Казан шәһәре муниципаль казнасын тулыландыру**

2025 елда муниципаль унитар предприятиеләре табышының бер өлешен күчерүдән алынган бюджет керемнәре 41,15 млн сум тәшкил итте, бюджет билгеләнешләре тулы күләмдә үтәлде.

Казнаны формалаштыру (тулыландыру) эшчәнлеге муниципаль милек белән идарә итү процессының аерылгысыз өлеше булып тора. 2025 елда аңа гомуми мәйданы 247 847,16 кв.м булган 404 күчемсез милек объекты (биналар, бүлмәләр, корылмалар), 325 инженерлык инфраструктурасы объекты, 282 945 күчемле мөлкәт берәмлеге кабул ителде.

Шулай ук 2025 елда казнадан гомуми мәйданы 250 813 кв.м булган 470 күчемсез мөлкәт объекты (биналар, бүлмәләр, корылмалар), 382 инженерлык инфраструктурасы объекты, 313 026 күчемле мөлкәт берәмлеге чыгарылды.

2025 елда торак булмаган фондның 36 объекты түләүсез файдалану хокукында тапшырылды:

- 3 дини оешмага;
- 16 дәүләт учреждениесенә;
- 13 иҗтимагый оешмага;
- 1 – хәйрия фондына;
- 3 – хәйриячелекне һәм иреклелекне (волонтерлыкны) оештыру һәм аңа булышлык итү эшчәнлеген, шул исәптән яшеренү челтәрләре үреп, аларны махсус хәрби операция зонасына җибәрү эшчәнлеген алып бару өчен коммерцияле булмаган җәмәгать оешмаларына тапшырылды.

Муниципаль бюджетны тулыландыру (милекне арендага бирү, хосусыйлаштыру очракларында) һәм милекне карап тоту чыгымнарын киметү муниципаль милек белән нәтиҗәле идарә итүнең төп күрсәткечләре булып тора.

2025 елда 27 сәүдә процедурасы (аукционнар / ачык сатулар) игълан ителде:

- 4 милек комплексын (биналары булган җир кишәрлекләрен) милеккә сату буенча 3 электрон аукцион;

- 3 торак булмаган бүлмәне милеккә сату буенча 2 электрон аукцион;

- 2 җир кишәрлеген милеккә сату буенча 2 электрон аукцион;

- җир кишәрлекләрен арендалауга 15 килешү төзү хокукларын гамәлгә ашыру буенча 4 электрон аукцион;

- төзелеп бетмәгән 1 объектны үз көченә кергән суд карарлары нигезендә милеккә сату буенча 1 ачык сату;

- Казан шәһәренең муниципаль милек объектларыннан файдаланган өчен еллык аренда түләве күләмен сату буенча 14 электрон аукцион (шуларның 10 сы – «Ташламалы аренда» программасы буенча).

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенә караган җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталының 509,914 млн сумлык 39,99 процент өлеше сатылды.

2025 елда түбәндәге килешүләр төзелде:

- җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьтә катнашу өлешен сату-алу буенча 509,914 млн сумлык 1 килешү;

- түләүне 5 елга кадәр кичектереп, гомуми бәясе 203,25 млн сумлык 4,22 мең кв.м мәйданлы арендага алына торган милекне кече яки урта эшмәкәрлек субъектларына сату-алу буенча 24 килешү (2008 елның 22 июлендәге 159-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, арендага алына торган милекне сатып алуның «турыдан-туры сату» дип атала торган өстенлекле хокукы);

- гомуми бәясе 579,82 млн сумлык мөлкәт комплексларын (җир кишәрлекләре булган биналарны) милеккә сату-алу буенча 3 килешү;

- гомуми бәясе 220,96 млн сумлык гомуми мәйданы 2,06 мең кв. м булган торак булмаган биналарны милеккә сату-алу буенча 3 килешү;

- 0,1228 га мәйданлы 42,45 млн сумлык җир кишәрлеген аукцион сатулары аша сату-алу буенча 1 килешү

- җирне арендалау буенча 162 килешү;

- җирне сату-алу буенча 139 килешү;

- җирдән түләсез вакытлыча файдалану буенча 250 килешү;

- 37 сервитут килешүе төзелде;

- җирне арендалау, сату-алу, җирдән түләүсез вакытлыча файдалану килешүләрен өзү турында 206 килешү;

- җир өчен аренда түләве күләме турында 3 500 дән артык хәбәрнамә, шул исәптән җир өчен аренда түләве буенча бурычларны түләү турында таләпләр.

2025 елда Казан шәһәре бюджетына күчемсез милекне арендалаудан 160,8 млн сум күләмендә керем керде, бу бюджет билгеләнешләренең 100,5 процентын тәшкил итте.

**Күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү**

Күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләрен бушлай бирү турында федераль законны гамәлгә ашыру кысаларында 2012 елдан башлап Казанда күп балалы гаиләләрне түләүсез җир кишәрлекләре белән тәэмин итү эше уңышлы дәвам итә.

Хәзерге вакытта түләүсез җир кишәрлеге алу хокукына ия гражданнар исемлегенә кертелгән күп балалы гаиләләрнең гомуми саны – 18 163 гаилә.

2012 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр 10 257 гаилә бушлай җир кишәрлеге алу хокукын тормышка ашырды. 7 906 гаиләне җир кишәрлеге белән тәэмин итәргә кирәк.

2025 елда җир кишәрлекләрен сайлау комиссиясенә 2 620 гаилә чакырылды, җир кишәрлекләрен бүлү комиссиясенең 134 утырышы уздырылды, күп балалы гаиләләр Татарстан Республикасының Лаеш, Биектау, Югары Ослан муниципаль районнары территорияләрендә 1 703 җир кишәрлеге сайлап алды.

**Җир кишәрлекләрен мәҗбүри алу**

«Казан шәһәре метрополитенының икенче линиясенең «Юлиус Фучик урамы» метро станциясеннән «Академик Сахаров урамы» метро станциясенә кадәр беренче участогы» линия объектын төзү максатыннан 2025 елда муниципаль ихтыяҗлар өчен 221 млн сум күләмендә 11 җир кишәрлеген мәҗбүри алу буенча чаралар төгәлләнде.

2022 елда башланган «Казан шәһәренең Киров районында Горький шоссесын реконструкцияләү, Чкалов һәм Степан Халтурин урамнарыннан алып М-7 “Волга” автомобиль юлына кадәрге участок» линия объекты автомобиль юлын төзү максатыннан җир кишәрлекләрен мәҗбүри алу эшләре дәвам итте. Күрсәтелгән юлны төзү кысаларында барлыгы 158 млн сумлык 35 кишәрлекне мәҗбүри алу буенча чаралар үткәрелде, шул исәптән 2 җир кишәрлеге буенча мәҗбүри алу буенча чаралар хисап елында тәмамланды. 5 кишәрлекне суд тәртибендә тартып алу эшләре дәвам итә.

Җирле әһәмияттәге «“Яңа порт” гидротехник корылмасы (1 нче этап)» линия объектын төзү максатыннан 2025 елда муниципаль ихтыяҗлар өчен «Якорь» гараж-төзелеш кооперативы территориясендә урнашкан объектлары белән бергә гомуми суммасы 21 млн сумга 12 җир кишәрлеге мәҗбүри алынды. 11 җир кишәрлегенә карата суд тәртибендә мәҗбүри алу буенча эшләр алып барыла.

2025 елда барлыгы 52 млн сумлык 17 җир кишәрлеге мәҗбүри алынды.

Казан шәһәренең Декабристлар урамында урнашкан торак булмаган төзелеш территорияләрен комплекслы үстерү максатыннан хәзерге вакытта 15 җир кишәрлеген һәм аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларын мәҗбүри алу буенча чаралар үткәрелә.

**2026 елга планнар:**

- Татарстан Республикасы Биектау, Питрәч, Югары Ослан, Яшел Үзән муниципаль районнары территорияләрендә җирләрне әйләнешкә кертү буенча чаралар үткәрү.
- күп балалы гаиләләргә җир кишәрлекләре бирү.

## Демографик вәзгыять.
## Гражданлык хәле актларын теркәү

2025 елда барлык төрдәге 52 151 гражданлык хәле акты теркәлде.

2024 ел белән чагыштырганда теркәлгән бала туу саны артты.

Гадәттәгечә малайлар кызларга караганда күбрәк туды. Шулай ук 213 пар игезәкләр тууы теркәлде, ә өч игезәк туу очраклары 2025 елда теркәлмәде.

2025 елда Казан шәһәренең барлык бала тудыру йортларында бала тууны теркәү эше дәвам итте. Хисап чоры нәтиҗәләре буенча туган балаларның 84 проценты бала тудыру йортларында теркәлде.

Теркәлгән үлемнәр саны 2024 ел белән чагыштырганда кимеде. Күпчелек очракта үлемне дәүләт теркәвенә алу медицина оешмасы тарафыннан бирелгән үлем турында медицина таныклыгы нигезендә башкарылды.

2025 елда өйләнүшеләр саны алдагы елның шул ук чоры белән чагыштырганда 2,3 процентка артты. 11 431 пар өйләнешү турында таныклык алды.

2025 ел нәтиҗәләре буенча Казанда аерылышу турында 3 587 акт теркәлде, аларның төп өлеше (69,2) суд карары нигезендә теркәлде.

| Акт язмалары саны | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Өйләнешү турында | 11 461 | 12 668 | 11743 | 11169 | 11431 |
| Аерылышу турында | 5 344 | 5 285 | 5005 | 4189 | 3587 |

Хисап чорында архив эше дәвам итте. 2025 елда кабаттан документлар алу, акт язмаларына үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү өчен мөрәҗәгать иткән, шулай ук вәкаләтле органнар аша Казан шәһәре Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе архивыннан кирәкле документларны шәхсән алучылар саны 197 меңнән артык кешене тәшкил итте.

| Күрсәткечләр | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| **Таныклыклар кабат бирелде** | 19 240 | 23 312 | 20829 | 18394 | 16738 |
| **Белешмәләр бирелде** | 60 070 | 45 780 | 45875 | 45885 | 46696 |
| **Үзгәрешләр, төзәтмәләр кертелде** | 2 042 | 2 189 | 2 218 | 2156 | 2199 |
| **Мөрәҗәгатьләр буенча белешмәләр бирелде** | 49693 | 43 899 | 41 844 | 97955 | 131490 |
| **БАРЛЫГЫ** | **131 045** | **115 180** | **110766** | **164390** | **197123** |

Ныклы гаиләләрне хөрмәтләү гаилә кыйммәтләрен пропагандалау булып тора. 2025 елда гаилә тормышы юбилее белән барлыгы 981 гаилә котланды, шулардан:

- гаилә тормышының 70 еллык юбилее (бәрәкәт туе) белән – 4 гаилә;
- 60 еллык юбилей («бриллиант» туй) белән – 134 гаилә;
- 50 еллык юбилей (алтын туй) белән – 843 гаилә.

2025 елда гаилә институтын популярлаштыруга һәм ныгытуга юнәлдерелгән 300 дән артык чара (юбиляр гаиләләрне, күп балалы гаиләләрне хөрмәтләү, паспортлар тапшыру, исем кушу, мөһим сораулар турында сөйләшүләр, «Безнең геройларга» акциясе, йөкле ханымнар көннәре һәм башкалар) үткәрелде.

Моннан тыш, җәмәгатьчелек игътибарын гаилә кыйммәтләре мәсьәләләренә җәлеп итү өчен социаль челтәрләрдә тормыш рәвешләре, үзара ярдәмләшүнең һәм традицияләргә тугрылыкның ачык үрнәге булган һәм шәһәр халкында уңай кайтаваз уята торган гаиләләр турында мәгълүмат урнаштырыла.

2026 елда эш дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең һәркем өчен ачыклыгын һәм сыйфатын күтәрүгә, шулай ук гаиләнең абруен ныгытуга, гаилә бәйрәмнәрен һәм йолаларын үстерүгә һәм яңартуга, гаилә кыйммәтләрен популярлаштыруга һәм гаилә уңышсызлыгын профилактикалауга юнәлдерелгән программаларны киңәйтүгә юнәлтеләчәк.

## Сәламәтлек саклау

2025 елда Казан шәһәре территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүгә дәүләт гарантияләре программасы кысаларында 108 медицина оешмасы эшләде, шуларның 42 се – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы дәүләт автоном учреждениеләр, 4 – федераль, 58 – шәхси милек формасындагы һәм 4 – башка учреждениеләр.

Казан шәһәре территориясендә 7 амбулатор-стационар комплекс эшләвен дәвам итә, аларның һәркайсының башында күппрофильле медицина учреждениеләре тора: М.Н.Садыйков исемендәге 7 нче шәһәр клиник хастаханәсе, 16 нчы шәһәр клиник хастаханәсе, 12 нче шәһәр клиник хастаханәсе, Медицина университеты клиникасы, К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 нче шәһәр клиник хастаханәсе, Сугыш ветераннары госпитале, 1 нче шәһәр балалар хастаханәсе.

Казан шәһәрендә 4 124 табиб һәм 7 460 урта медицина хезмәткәре эшли.

Халыкны медицина кадрлары белән тәэмин итү:

- табиблар белән – 10 мең кешегә 30,6;
- урта медицина хезмәткәре белән – 10 мең кешегә 60,0.

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләренең берсе – тармакта кадрлар җитмәүчелеген бетерү.

Штаттагы вазифаларның табиблар белән тәэмин ителеше 98,5%, физик затлар белән тәэмин ителеш – 83,2% тәшкил итә.

Штат вазифаларының урта медицина хезмәткәрләре белән тәэмин ителеше – 92,1%, урта медицина хезмәткәрләренең физик затлары белән– 81,2%.

Сәламәтлек саклау системасы эшенең нәтиҗәлелеген бәяли торган төп күрсәткеч – үлүчеләр саны кимү. Республикада үлүчеләр саны 2024 ел белән чагыштырганда кимеде.

Күп очракта уңай нәтиҗәләргә 2030 елга кадәр исәпләнгән «Дәвамлы һәм актив тормыш» һәм «Гаилә» кебек илкүләм проектларны гамәлгә ашыру хисабына ирешелә.

Шулай ук 2025 елда «Балаларга медицина ярдәме күрсәтүнең заманча инфраструктурасын булдыру белән бергә балалар сәламәтлеген саклау өлкәсен үстерү» федераль проектын гамәлгә ашыру дәвам итте.

Профилактик медицина тикшерүләре балаларның сәламәтлеген саклауда мөһим роль уйный. Алар авыруларны башлангыч стадияләрдә ачыкларга һәм вакытында дәваларга мөмкинлек бирә. 2025 елда 306 526 бала (планнан 104,9%) профилактик тикшерүләр үтте.

Өлкәннәрнең билгеле бер төркемнәрен диспансеризацияләү 398 319 кешегә уздырылды, профилактик медицина тикшерүләрен 111 333 кеше (2024 елга караганда 4 процентка күбрәк – 107 050 кеше) үтте, 166 600 кеше репродуктив сәламәтлекне бәяләүгә юнәлдерелгән диспансеризация кысаларында тикшерелде.

2025 елда Вишневка торак массивында 100 кешегә хезмәт күрсәтүгә исәпләнгән гомуми практика табибы һәм педиатрия үзәге, «Весна» торак комплексында 400 кешегә хезмәт күрсәтүгә исәпләнгән өлкәннәр поликлиникасы һәм «Волжские просторы» торак комплексында 200 кешегә хезмәт күрсәтүгә исәпләнгән балалар поликлиникасы төзелеше тәмамланды. Сәламәтлекне саклау, авыруларны диагностикалау һәм профилактикалау өчен барлык кирәкле шартлар тудырылды.

2 нче клиник хастаханәдә, 16 нчы шәһәр клиник хастаханәсендә, Сугыш ветераннары госпиталендә, К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 нче шәһәр клиник хастаханәсендә «Стационарларны капиталь ремонтлау» программасы буенча эшләр дәвам итә.

К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсендә кабул итү-диагностика бүлеген төзү эшләре дәвам итә.

**2026 елга планнар:**

- хезмәткә сәләтле яшьтәге затларның үлемен киметү буенча профилактик чаралар үткәрүне дәвам итү (өлкән яшьтәге халыкның билгеле бер төркемнәренә диспансеризация, профилактик медицина тикшерүләре, онкоскрининг үткәрү, халыкның репродуктив сәламәтлеген бәяләү);
- 2 нче клиник хастаханәдә, 16 нчы шәһәр клиник хастаханәсендә, Сугыш ветераннары госпиталендә, К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсендә капиталь ремонтны төгәлләү;

- К.Ш.Зыятдинов исемендәге 18 нче үзәк шәһәр клиник хастаханәсенең кабул итү-диагностика бүлеген файдалануга кертү.

## Санитария-эпидемиология иминлеге

Казан шәһәре халкының санитария-эпидемиология ягыннан иминлеге санитария-гигиена, эпидемиягә каршы (кисәтү) чаралары комплексын уздыру белән һәм бу өлкәдә федераль дәүләт күзәтчелеге системасы белән тәэмин ителә.

2025 елда Казан шәһәре территориясендә йогышлы һәм паразитар авыруларның 338 393 очрагы теркәлде, 100 мең кешегә авыручылар саны – 25 554,2, бу 2024 ел дәрәҗәсендә.

Дифтерия, кызылча, паратиф, лептоспироз һәм аеруча куркыныч инфекцияләр очраклары теркәлмәде.

Бактериаль дизентерия, кискен гепатит A, B, C, хроник вируслы гепатитлар, бума ютәл, кызамык, Көнбатыш Нил бизгәге, бөер синдромлы геморрагик бизгәк, Денге бизгәге, талпан энцефалиты, талпан боррелиозы белән авыручылар саны кимеде. Педикулез, туберкулез, гонококк инфекциясе һәм хастаханәдән тыш үпкә ялкынсынуы белән авыручылар саны кимеде. Шул ук вакытта, ачыкланмаган этиологияле кискен эчәк инфекцияләре, энтеровирус инфекциясе, гемофиль инфекция, грипп һәм корчаңгы белән авыручылар саны артуы билгеләп үтелде.

Казан шәһәрендә йогышлы авыруларны булдырмау, таралуын чикләү һәм бетерү максатыннан эпидемиягә каршы чаралар уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан 26 099,6 мең сум акча бүлеп бирелде:

- ачык территорияләрне дератизацияләүгә – 5 626,2 мең сум;
- ачык территорияләрне талпанга каршы эшкәртүгә – 3 737,5 мең сум;
- сулыкларны черки личинкаларына каршы дезинсекцияле эшкәртүгә – 2 250,6 мең сум;
- йогышлы авырулар чыганакларын дезинфекцияләүгә, чыганаклардагы әйберләрне камерада дезинфекцияләүгә, авыручыларны санитария ягыннан зарарсызландыруга – 11 929,1 мең сум;
- эпидемиягә каршы санитария чараларына – 2 556,2 мең сум.

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан дератизация эшкәртүенә өстәмә рәвештә 15 586,2 мең сум акча бүлеп бирелде, бу Казан шәһәренең 3 432 гектар мәйданлы территориясен кимерүчеләргә каршы эшкәртергә мөмкинлек бирде.

2025 елда гомуми мәйданы 5 368,4 га җирләрдә профилактик эшкәртүләр, шул исәптән 4 671,5 га мәйданда дератизация эшкәртүе башкарылды, акарицид

белән эшкәртү мәйданы 400,3 га, ларвицид белән эшкәртү мәйданы 296,6 га мәйданда башкарылды.

Токсикологик мониторинг мәгълүматлары буенча, 2025 елда Казан шәһәрендә химик этиологиядәге кискен агулануның 1351 очрагы теркәлде, бу 2024 ел дәрәҗәсеннән 7 процентка югарырак, аларның 175 очрагы үлем белән тәмамланды, бу узган ел белән чагыштырганда 6,4 процентка кимрәк.

Казан шәһәре территориясендә рекреация максатында кулланыла торган сулыкларның су сыйфаты күрсәткечләре күпьеллык уртача күрсәткечләр дәрәҗәсендә тора. 2025 елда санитария-химия күрсәткечләре буенча гигиена нормативларына туры килми торган сулыкларның су пробалары өлеше 11,2%, микробиологик пробалар – 11,8% тәшкил итте.

Эчәргә яраклы суның сыйфаты Казан шәһәре халкының сәламәтлегенә нинди йогынты ясаганын бәяләү өчен дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында 34 күзәтү ноктасында лаборатор тикшеренүләр үткәрелде.

Лаборатория тикшерүләре нәтиҗәләре буенча, су бүлү челтәреннән килә торган эчәргә яраклы суның сыйфаты Казан шәһәре буенча күпьеллык уртача күрсәткечләр дәрәҗәсендә тора. Санитария-химия күрсәткечләре буенча гигиена нормативларына туры килмәгән су пробалары өлеше 2025 елда 4,8 процентны, микробиологик күрсәткечләр буенча 1,2 процентны тәшкил итте.

2025 елда Казан шәһәре автомагистральләре һәм сәнәгать предприятиеләре йогынтысындагы зонаның атмосфера һавасын күзәтү дәвам итте. Атмосфера һавасыннан барлыгы 11 605 проба алынды, аларның 1,1 проценты гигиена таләпләренә туры килмәде. Лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча пычрата торган матдәләре гигиена нормативларыннан арткан атмосфера һавасы пробаларының чагыштырмача күләме шулай ук күпьеллык уртача күрсәткечләр дәрәҗәсендә калды.

2025 елда каты коммуналь калдыкларны җыю урыннарын (мәйданнарын) һәм аларга якын территорияләрне тиешенчә карап тотмау мәсьәләсе буенча 652 мөрәҗәгать карап тикшерелде. Мөрәҗәгатьләрне карап тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган хокук бозу фактлары буенча 7 дәгъва гаризасы судка җибәрелде, мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында 240 кисәтү белдерелде.

Азык-төлек продукциясенең билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән чагыштырма авырлыгы микробиологик күрсәткечләр буенча 3,4% һәм санитар-химик күрсәткечләр буенча 2,8% тәшкил итә, бу күпьеллык уртача күрсәткечләр дәрәҗәсендә.

Азык-төлек продукциясенең тикшерелгән пробаларында микотоксиннар, радионуклидлар, генлы-модификацияләнгән организмнарның гигиена нормативлары буенча артуы ачыкланмады.

Продукциянең билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры килмәве ачыклану сәбәпле, гомуми күләме 4,099 тонна булган 496 партия азык-төлек продукциясе

әйләнештән алынды. Тиешле таләпләрне бозуның ачыкланган фактлары буенча административ хокук бозу турында 453 беркетмә төзелде, гомуми суммасы 5 681 300 сумлык административ штраф салынды, 161 материал карап тикшерү өчен судка җибәрелде. Шулай ук мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамаганлыгы турында 759 кисәтү белдерелде.

Казан шәһәре буенча эшләүче халык арасында 2025 елда төрле тармакларда эшчәнлек алып барган предприятиеләрдә һәм оешмаларда эшләүче 108 хезмәткәргә һөнәри авыру диагнозы куелды (2024 елда – 110). Берьюлы берничә һөнәри авыруы ачыкланган эшчеләрнең чагыштырма күләме 3,7% тәшкил итте, бу 9% тәшкил иткән 2024 ел күрсәткеченнән түбәнрәк. Этиологик билгеләре буенча физик факторлар йогынтысыннан барлыкка килә торган авырулар өстенлек итә.

Зарарлы һәм куркыныч хезмәт шартларында эшләүче хезмәткәрләрне периодик рәвештә медицина тикшерүләре белән тәэмин итү Казан шәһәре буенча 94,1% тәшкил итте (2024 елда – 88,2%).

2025 елда Казан шәһәре территориясендә радиация торышы үзгәрмәде, ачык урыннарда гамма-нурланыш дәрәҗәсе 0,10-0,18 мкЗв/сәг тәшкил итте һәм күпьеллык уртача күрсәткечләрдән артмады.

**2026 елга бурычлар:**

- халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәүне контрольдә тотуны (күзәтчелекне) тәэмин итү һәм гамәлгә ашыру;
- кешенең яшәү тирәлеге факторларына федераль дәүләт санитар-эпидемиологик контрольне (күзәтчелекне) камилләштерү, шул исәптән федераль проектларны гамәлгә ашыру кысаларында;
- адреслы профилактик чараларны эшләү һәм үткәрү өчен йогышлы һәм паразитар авырулар буенча эпидемиологик вәзгыятьне күзәтү, анализлау, бәяләү системасын үстерү (камилләштерү).

## Сәламәт туклану сәясәтен тормышка ашыру

2025 елда сәламәт тукклануны оештыру эше түбәндәге юнәлешләр буенча алып барылды:

- Казан шәһәренең мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануны оештыру;
- сәламәтлек саклау учреждениеләрендә туклануны оештыру;
- туклануның куркынычсызлыгын тикшереп тору;
- җитештерү процессларын цифрлаштыру;
- сәламәт туклануны пропагандалау.

**Мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү учреждениеләрендә туклануны оештыру.**

2025 елның 1 сентябреннән Казан шәһәрендә көн саен барлыгы 176 мең укучы кайнар ризык белән туклана.

Башлангыч сыйныф укучыларын түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү буенча федераль программа кысаларында 74 мең укучы өчен бердәм меню нигезендә туклану оештырылды.

1-4 сыйныф укучыларының туклануын оештыру өчен «Татарстан Республикасында гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең эксперт бәяләмәсен алган ике атналык меню эшләнде.

Хисап елында федераль программа кысаларында башлангыч мәктәп укучылары өчен тукlануның 2 варианты тәкъдим ителде. Комплекс вариантын ата-аналар сайлый һәм язмача гариза белән рәсмиләштерә.

Түләүсез кайнар тукланудан тыш, барлык мәктәп укучылары өчен түбәндәге туклану комплекслары бар: бәясе 43 сумлык иртәнге аш яки кичке әбәт, бәясе 20 сумлык аш, 63 сумлык комплекслы төшке аш һәм 89 сумлык ирекле сайлау менюсы.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән 5-11 нче сыйныф укучылары гыйнвардан майга кадәр көн саен 9,60 сумлык, ә 2025 елның 1 сентябреннән 10,30 сумлык туклану белән тәэмин ителә. Шулай ук тәкъдим ителгән теләсә кайсы комплексның, шул исәптән буфет продукциясенең бәясе бу суммага киметелә.

2006 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр шәһәр бюджетыннан аз керемле гаиләләрдәге һәм махсус хәрби операциядә катнашучылар гаиләләрендәге укучыларны, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балаларны туклану акча бүлеп бирелә – бу укучыларның 18 проценты. 12 мең югары сыйныф укучысы ирекле сайлау менюсы буенча түләүсез туклана, махсус хәрби операциядә катнашучыларның 4,6 мең баласы һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән 1,5 мең бала (1-11 сыйныфлар) ике тапкыр туклана.

Башлангыч сыйныф укучыларын бушлай кайнар ризык белән тәэмин итү программасын гамәлгә ашыру кысаларында җәйге каникул чорында 11 мәктәпнең азык-төлек блогы ремонтланды. Күрсәтелгән эшләргә республика бюджетыннан 271 млн сум бүленеп бирелде. Ремонт эшләре нәтиҗәсендә сыйдырышлык 291 урынга артты.

Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты акчаларыннан 251,4 млн сум Казан шәһәре мәктәп ашханәләренә түбәндәгеләр өчен бирелде:

- мәктәп пешекчеләренә өстәмә түләү һәм персонал сайлау чыгымнары (163,6 млн сум);
- кирәкле җиһазлар, мебель, декоратив элементлар, уку-укыту постерлары сатып алу (50,3 млн сум);
- җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау (20,4 млн сум);

- савыт-саба, юу чаралары, махсус кием, хуҗалык товарлары сатып алу (35,1 млн сум);

- төшке аш залларының дизайн-проектларын эшләү, декоратив ремонт ясау (0,4 млн сум).

Бүгенге көндә Казанда 188 мәктәп рестораны эшләп килә.

**Сәламәтлек саклау учреждениеләрендә туклануны оештыру**

2025 елда 7 дәвалау-профилактика учреждениесе өчен туклану оештыру дәвам итте: «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном медицина учреждениесе, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном медицина учреждениесе, «М.Н.Садыйков исемендәге 7 номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном медицина учреждениесе, «А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник инфекция хастаханәсе» дәүләт автоном медицина учреждениесе, «Республика клиник тире-венерология диспансеры» дәүләт автоном медицина учреждениесе, «РЖД-Медицина» клиник хастаханәсе, «Казан шәһәре сугыш ветераннары госпитале» дәүләт автоном медицина учреждениесе.

2025 елда көн саен тәүлек буе эшли торган стационарлардагы 5 мең пациент туклану белән тәэмин ителде.

**Туклану куркынычсызлыгы**

Махсус игътибар зонасында – куркынычсыз туклану, ул сыйфатлы чималдан башлана. 2025 елда аккредитацияләнгән лабораториядә 206 мең анализ үткәрелде, 1 мең тонна продукция яраксызга чыгарылды. Лаборатория хезмәткәрләре тарафыннан сыйфат һәм куркынычсызлыкны тикшерү өчен балалар бакчаларына һәм шәһәр мәктәпләренә 1 218 тапкыр урынга чыгып тикшерүләр үткәрелде.

**Җитештерү процессларын цифрлаштыру**

2025 елда Казан шәһәренең Азык-төлек һәм социаль туклану департаменты процессларны цифрлы трансформацияләү эшен дәвам итте, аның төп юнәлешләренең берсе – көндәлек операцияләрне автоматлаштыру.

1-С ERP базасында бердәм мәгълүмат системасын гамәлгә кертү эше дәвам итә. 2025-2026 елларга «Складлар һәм логистика» модулен гамәлгә кертү планлаштырылды.

Гамәлгә кертү этабында – товарны кабул итү һәм тәэмин итүчеләргә дәгъва белдерү процессын автоматлаштыру. Модельләштерү этабында – «Җитештерүне автоматлаштыру» проекты.

«Битрикс 24» программасы базасында «Акыллы туклану» сервисын киңәйтү эше дәвам итә. 2025 елда түбәндәге функционал кертелде:

- тикшерүләр системасына яңа бүлекчәләр кертелде;

- яңа чек-битләр һәм башкалар өстәлде.

Сәламәт туклану өлкәсендәге эшчәнлекнең өстенлекле юнәлешләреннән берсе булып җаваплы элемтә белән эшләү кала. «Ата-аналар контроле

журналы» проекты кысаларында ата-аналарның көн саен ашханәләргә килүе дәвам итә. 2025 елда журналдагы язмалар саны 24,1 меңгә җитте, бу алдагы ел белән чагыштырганда 3 меңгә күбрәк.

**Кадрлар әзерләү**

Мәктәп ашханәләрендә кадрлар җитмәү сәбәпле, 2025 елның язында Казан милли тикшеренү технология университеты, Казан кооператив институты, Казан инновация университеты һәм Казан сәүдә-икътисад көллияте белән берлектә Ресурс үзәге төзелде.

Алдан 3 мең тугызынчы сыйныф укучысы арасында һөнәри юнәлеш бирү эше үткәрелде. 183 кеше дуаль белем алырга теләк белдерде, шуларның 161 е һөнәри сынауларга һәм һөнәри тестлар узуга кертелде. Башкарылган эш нәтиҗәләре буенча алар белән максатчан укытуга килешүләр төзелде.

Бүгенге көндә 151 студенттан торган 16 студентлар бригадасы төзелгән, алар уку һәм эшне берләштерә (4 көн – көллияттә, 2 көн – эштә).

**Сәламәт туклануны пропагандалау**

Халык арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча актив эшкә аерым игътибар бирелә.

2025 елның җәендә 83 номерлы лицейның һәм 14 номерлы гимназиянең мәктәп яны лагерьларында, ә декабрьдә 79 номерлы мәктәптә гаилә пикниклары оештырылды. Июнь аенда – «Елмай» паркында «Сәламәтлек пикнигы» һәм Горки-Әмәт урманында «Зур гаилә пикнигы», ә август ахырында – «Күрше фест» фестивалендә өч очрашу булды. Шулай ук күрсәтелгән чараларда иҗади мастер-класслар үткәрелде.

**2026 елга планнар:**

- Казан шәһәренең 11 мәктәбендә азык-төлек блокларын ремонтлау, технологик җиһазларны алмаштыру һәм яңа җиһазлар сатып алу;
- цифрлаштыру проектларын дәвам итү;
- сәламәт туклануны пропагандалау проектларын гамәлгә ашыру;
- укучыларның үтү мөмкинлеген арттыру һәм чиратта көтү вакытын кыскарту максатыннан, тарату линиясендә ризык бирүне тизләтү өчен гомуми белем бирү учреждениеләрендә 60 банкоматны инфоматка күчерү.

## Мәгариф

Казанда белем бирү – ул 344 балалар бакчасы, шуларның 303 е – муниципаль һәм 15 е – мәктәпкәчә бүлекләр, 206 мәктәп, алар арасында 174 е – муниципаль, шулай ук 49 ы – өстәмә белем бирү учреждениесе. Шәһәрдә якынча 250 мең бала белем һәм тәрбия ала, шулардан 182 008 бала – мәктәпләрдә (муниципаль мәктәпләрдә – 171 135, дәүләт мәктәпләрендә – 6 695, федераль мәктәпләрдә – 1 177, шәхси мәктәпләрдә – 3 001) һәм 67 960

бала – балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр (66 163 – муниципаль бакчаларда). Өстәмә белем бирү учреждениеләренә 71 245 укучы йөри.

2025 елда «Яшьләр һәм балалар» милли проекты кысаларында Казан шәһәре Совет районының «Лето» торак комплексында 1 224 урынга исәпләнгән яңа 123 номерлы физика-математика лицее ачылды. «33 нче Хәрби шәһәрчек» торак комплексында 220 урынга исәпләнгән балалар бакчасы төзелеше тәмамланды.

Бүгенге көндә 3 366 укучыны 44 автобус маршруты буенча 29 белем бирү учреждениесенә илтү оештырылган. 2025 елның 1 апрелендә Казан шәһәренең Мәскәү районындагы «99 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә кадәр 109ш номерлы яңа маршрут ачылды.

Вознесение трактын реконструкцияләүгә бәйле рәвештә мәктәп автобус маршрутлары хәрәкәтендә үзгәрешләр булды һәм бер маршрут урынына ике – 96ш номерлы («Иман урамы – 183 номерлы гимназия») һәм 96ш-1 номерлы («Вознесенское торак массивы – 183 номерлы гимназия») маршрутлар буенча балаларны илтү оештырылды.

«“Абдулла Алиш исемендәге 20 номерлы гимназия” муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе – Казан шәһәре Совет районының Царицынский Бугор торак массивы» яңа мәктәп автобус маршрутын ачуны оештыру эше алып барыла.

**Аерым ихтыяҗлар**

Үсештә аерым ихтыяҗлары булган балаларны сыйфатлы белем белән тәэмин итү эше дәвам итә. 2025/2026 уку елы башыннан мәктәпкәчә учреждениеләрдә аутистик спектры бозылган, психик үсешендә тоткарлык булган, үсешендә авыр һәм күптөрле тайпылышлар булган 110 бала өчен 13 махсуслаштырылган төркем ачылды. Балалар бакчаларына 1131 сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән бала йөри.

Моннан тыш, Казан шәһәре Яңа Савин районының «13 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә махсуслаштырылган кабинетлар ремонтланды һәм җиһазлар сатып алынды. Шулай ук Казан шәһәре Совет районының «111 номерлы рус-татар урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе өчен дә җиһазлар сатып алынды.

Казанда төрле нозологияле (ишетү, күрү, сөйләм кимчелекләре булу, терәк-хәрәкәт аппараты кимчелекләре булу, психик үсештә тоткарлык булу, акылга зәгыйфьлек, аутистик спектрда тайпылышлар булу) балаларны укыту өчен шартлар тудырылган 54 база мәктәбе бар. Махсус һәм ресурс сыйныфлары эшли. Муниципаль мәктәпләрдә барлыгы 1 784 сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән һәм 1 257 инвалид бала белем ала.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар белән күпьеллык системалы һәм нәтиҗәле эш алып бару нәтиҗәсендә Казан шәһәренең белем бирү учреждениеләре бу өлкәдә Россиядә иң яхшылардан санала. Әгәр 2024

елда 33 номерлы балалар бакчасы Россиянең иң яхшы инклюзив балалар бакчасы булса, 2025 елда Казанның 78 номерлы лицее Россиянең иң яхшы инклюзив мәктәбе дип танылды.

**Милли белем бирү**

Бүгенге көндә милли белем бирү учреждениеләре челтәренә татар телендә белем бирүче 38 мәктәп керә, аларда 32 934 укучы белем ала (узган уку елында – 37 мәктәп, аларда 29 357 бала белем алды).

Мәктәп укучыларының милли составы: 51% – татар балалары, 41,6% – рус балалары, 7,4% – башка милләт балалары. 18,59% татар баласы туган татар телендә укый, ә 36,67% – туган татар телендә тәрбияләнә.

«Туган тел» предметын өйрәнү кысаларында 32,02% бала туган татар телен (шул исәптән 23,02% – Татарстан Республикасының дәүләт телен – татар телен), 44,52% – туган рус телен сайлады.

Татар телендә белем һәм тәрбия бирү 229 балалар бакчасында, шул исәптән татар телендә тәрбия һәм белем бирүче 85 балалар бакчасында алып барыла. Сабыйларның 46,4 процентына татар телендә белем һәм тәрбия бирелә. 5, 177, 252 һәм 348 номерлы балалар бакчалары «Татарстан Республикасының иң яхшы билингваль балалар бакчасы» конкурсында җиңүчеләр булдылар.

**Дәүләт йомгаклау аттестациясе**

Дәүләт йомгаклау аттестациясе белем бирү сыйфатының бер күрсәткече булып тора. 2025 елда дәүләт йомгаклау аттестациясендә 20,5 меңгә якын укучы катнашты.

2025 елда чыгарылыш сыйныф укучыларының гомуми саныннан (5815 кеше) 11 нче сыйныфны тәмамлаучы 5 800 чыгарылыш сыйныф укучысы бердәм дәүләт имтиханнарын тапшырды (99,74%). Калган (сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикләнгән) чыгарылыш сыйныф укучылары дәүләт чыгарылыш имтиханын сайладылар. Рус теле буенча уртача балл 65,18 булды. Профильле дәрәҗәдәге математика буенча уртача балл 69,44 тәшкил итте.

**Рус теле һәм математикадан 3 елга уртача балл динамикасы**

| Фән | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|
| Рус теле | 71,65 | 67,09 | 65,18 |
| Математика | 63,59 | 70,05 | 69,44 |

2024 ел белән чагыштырганда, Казан шәһәренең чыгарылыш укучылары 14 предметтан 5 предмет буенча уртача баллны яхшырта алды.

Бердәм дәүләт имтиханнары йомгаклары буенча 160 максималь нәтиҗә алынды (100 балл). Йөз баллы иң күп нәтиҗәләрне Казан чыгарылыш укучылары рус әдәбияты (48), химия (38), рус теле (19), математика (12) һәм информатика (15) буенча күрсәттеләр. Казан укучыларының 7 се имтиханнарда 200 балл җыйды.

«Укудагы аеруча уңышлары өчен» медальләре белән 639 чыгарылыш укучысы, икенче дәрәҗәдәге медальләр белән – 519 кеше бүләкләнде.

2025 елда бөтенроссия олимпиадасының муниципаль этабы рекордлы 17 мең катнашучыны җыйды.

Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының төбәк этабында һәм Республика мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында 4 054 катнашучыдан 2 535 укучы җиңүче һәм призер булды. Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында шәһәр мәктәпләре укучылары Татарстан Республикасы буенча 265 урыннан 162 призлы урын яулады.

| Атамасы | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| Казан | 115 | 142 | 159 | 148 | 162 |
| Татарстан | 211 | 237 | 251 | 244 | 265 |
| Татарстан командасында Казан шәһәре призерлары өлеше | 54,5% | 59,9% | 63,3% | 60,6% | 61,1% |

2025 елда олимпиадаларда катнашу нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе премияләре белән 1 596 укучы һәм 731 педагог бүләкләнде.

Моннан тыш, Мәскәү районының «2 номерлы лицей-интернат» муниципаль автоном белем бирү учреждениесенең 11 сыйныф укучысы Гыймран Абдуллин һәм аның остаз-укытучысы Илшат Сафиуллин халыкара олимпиада хәрәкәтендәге уңышлары өчен 250 мең сум күләмендә Казан шәһәре Мэры премиясенә лаек булдылар.

**Педагоглар**

Казан шәһәренең мәгариф учреждениеләрендә 31 меңнән артык кеше эшли, алар арасында 17 меңнән артык педагогик хезмәткәр бар. Моннан тыш, 2025 елда Казан мәктәпләренә, балалар бакчаларына һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренә рекордлы 460 яшь белгеч эшкә килде.

Идарә кадрларын ротацияләү барышында 2025 елда резервтан 7 җитәкче билгеләнде (2 – мәктәпләргә, 4 – балалар бакчаларына, 1 – өстәмә белем бирү учреждениесенә).

Ел саен Казанның белем бирү учреждениеләре, шулай ук укытучылары һәм тәрбиячеләре республика һәм федераль һөнәри конкурсларда алдынгы урыннарны били. 2025 елда:

- Казан шәһәре Яңа Савин районының 146 номерлы «Ресурс» лицееның татар теле һәм әдәбияты укытучысы А.М.Мөхәммәтова «Иң яхшы туган тел һәм әдәбият укытучысы – 2025» бөтенроссия конкурсының йомгаклау этабында җиңүче булды;

- Казан шәһәре Вахитов районының «63 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең өлкән тәрбиячесе Т.М.Макарова «Россия тәрбиячеләре – 2025» XIII бөтенроссия конкурсының «Иң яхшы инклюзив мәктәпкәчә белем бирү практикасы» номинациясендә I дәрәҗә лауреат исеменә лаек булды;

- Казан шәһәре Вахитов районының «283 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе «XXI гасыр мәгариф оешмасы. Лидерлар лигасы – 2025» бөтенроссия конкурсы лауреаты булды;

- Казан шәһәре командасы (Казан шәһәре Яңа Савин районындагы 91 номерлы мәктәпнең тәрбия буенча киңәшчесе Т.Н.Борһанова, Казан шәһәре Яңа Савин районындагы 91 номерлы мәктәпнең уку эшләре буенча директор урынбасары О.А.Панфилова, Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе методисты Л.Н.Карпунина) Тамбов шәһәрендә «Профилактика остасы» төбәкара конкурсында җиңүче булды;

- Казан шәһәре Совет районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 162 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Татарстан Республикасының мәктәпкәчә учреждениеләре арасында «Милли мультFest» V Республика балалар кинофестивалендә «Татар телендә балалар өчен кыска метражлы фильмнар» юнәлешендә III урынны алды.

Казан учреждениеләре ел саен RAEX тикшеренү агентлыгы рейтингларына керә. 2025 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы мәктәпләре арасында чыгарылыш укучыларының конкурентлык сәләте буенча беренче дүрт урынны КФУның СУНЦ IT-лицее, 2 номерлы лицей-интернат, 131 номерлы лицей, КФУның Лобачевский исемендәге лицее били, ә Россиянең 300 мәктәбе арасында чыгарылыш укучыларының конкурентлык сәләте буенча 8 Казан мәгариф оешмасы билгеләнде: КФУның СУНЦ IT-лицее, 2 номерлы лицей-интернат, 131 номерлы лицей, КФУның Лобачевский исемендәге лицее, Россия Герое А.В.Козин исемендәге 7 номерлы гимназия, 7 номерлы лицей-интернат, 3 номерлы гимназия, 18 номерлы мәктәп.

Шулай ук 131 номерлы лицей мәктәпләр арасында Россиянең алдынгы вузларына укырга кергән чыгарылыш сыйныф укучылары саны буенча 59 нчы урынны алды.

Казан мәктәпләре республиканың иң яхшы мәктәпләре рейтингында ышанычлы рәвештә алда бара. Иң яхшы 20 мәктәп исемлегенә кергән 15 мәктәп Казанны тәкъдим итә, шул исәптән 131 номерлы лицей, КФУның Лобачевский исемендәге лицее һәм КФУның СУНЦ IT-лицее шундый ук тәртиптә I-III урыннарны били.

**Яшь талантлар**

Казан мәктәпләре – балаларны һәрьяклап үстерү мәйданчыгы. Безнең мәктәп укучылары Иванова Полина, Хәлилова София, Сулагаева Оксана, Мадышева Диана, Гулина Яна «Зур тәнәфес» бөтенроссия конкурсында җиңүчеләр һәм призерлар булдылар.

2 номерлы лицей-интернат укучысы Абдуллин Гыймран Россия җыелма командасы составында ике олимпиадада җиңү яулады: информатика буенча

IOI-2025 халыкара олимпиадасында һәм информатика буенча Азия-Тын океан олимпиадасында (APIO) көмеш медальләргә ия булды.

«Халыкара Казан мәктәбе» автоном коммерцияле булмаган гомуми белем бирү оешмасы укучысы Хуҗиәхмәтов Илдар киберкуркынычсызлык буенча халыкара олимпиадада (ICO) алтын медаль яулады.

Шәрәфиев Азамат (9 номерлы мәктәп) һәм Нургаянов Сәет (131 номерлы лицей) химия буенча Әбү Рәйхан Әл-Бируни исемендәге халыкара олимпиададан алтын медальләр алып кайттылар.

Фәсхетдинов Рәшит (19 номерлы гимназия) һәм Семенов Альберт (2 номерлы лицей-интернат) химия буенча 59 нчы халыкара Менделеев олимпиадасында алтын медальгә ия булдылар.

Математика буенча Кытай милли олимпиадасында (CNMO) Россия җыелма командасы составында ике медаль яуланды: Большаков Максим («2 номерлы лицей-интернат» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе) – алтын, Васильев Михаил (Н.И.Лобачевский исемендәге лицей) – көмеш медаль алдылар.

2025 елда беренче тапкыр БРИКС яшүсмерләр фестивале һәм олимпиадасы узды, анда 13 илдән 131 укучы катнашты. Командалар арасында Казан шәһәре командасы алтын медаль яулады.

Информатика буенча шәхси турда көмеш медаль Костылев Никитага (2 номерлы лицей-интернат), алтын медаль Насыйбуллин Ильяска (2 номерлы лицей-интернат) бирелде. Математикадан шәхси турда 14-15 яшьлекләр категориясендә алтын медальне Тимофеев Артем (КФУ каршындагы IT-лицей) яулады; 16-17 яшьлекләр категориясендә Назыров Сергей (2 номерлы лицей-интернат) һәм Котляров Тимур (131 номерлы лицей) алтын медальләргә лаек булдылар.

**Профильле укыту. Һөнәр алды сыйныфлары**

Казанның 163 мәктәбендә белем бирү стандарты белән каралган барлык профильләр гамәлгә ашырыла.

Профильле 10-11 сыйныфлардан тыш, Казан шәһәрендә төрле юнәлештәге һөнәр алды сыйныфлары челтәре үсеш ала.

Казан шәһәренең гомуми белем бирү оешмаларында психологик-педагогик, медицина, агротехнологик юнәлештәге сыйныфлар, «Инженерлык республикасы», «“Энергокласс” энергетика профилендәге инженерлык сыйныфы», «Цифрлы (IT) сыйныф», «Авиатөзелеш профилендәге инженерлык сыйныфлары», «СИБУР-сыйныф», «Архитектура сыйныфы», «Торак-коммуналь хуҗалык сыйныфы», «Казан милли тикшеренү техник университетының инженерлык сыйныфы», шулай ук гомуминженерлык юнәлешендәге сыйныфлар, шәһәр идарәсе сыйныфы, тимер юл сыйныфы, дипломатия сыйныфы, юстиция сыйныфы, эшмәкәрлек, метрология, космос сыйныфлары эшли. Барлыгы – 21 юнәлеш.

«Казанның яңа педагогика сыйныфы» шәһәр проекты кысаларында Казан шәһәренең 29 мәктәбендә 65 психологик-педагогик сыйныф эшләп килә, аларда 1 500 укучы, мәктәп предметларыннан тыш, педагогика, психология нигезләрен теориядә генә түгел, практикада, югары белем бирүче мәгариф оешмалары педагоглары җитәкчелегендә өйрәнә.

Шәһәр мәктәпләре укучылары өчен Россия Федерациясе халык артисты Денис Мацуевның «Яңа исемнәр» бөтенроссия проекты гамәлгә ашырыла. 2025 елда 4 укучы әлеге бәйгедә катнашты: Кайгородов Климентий, Баһавиев Камил, Шакирова Зәлинә һәм Чапаева Софья стипендиат статусын алды.

Моннан тыш, балалар музыка һәм рәсем сәнгате мәктәпләренең, шулай ук балалар сәнгать мәктәпләренең талантлы 53 укучысы Казан шәһәре Мэры стипендияләре бәйгесендә катнашты. 16 иң сәләтле бала Казан шәһәре Мэры стипендиясенә ия булды.

Шулай ук балалар сәнгать мәктәпләренең һәм Александр Сладковский җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы Дәүләт симфоник оркестрының «Оркестрның тылсымлы кыллары» һәм «Балалар – балаларга» дигән уртак проектлары уңышлы гамәлгә ашырылып килә.

«Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында «98 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, «64 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе һәм «174 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе базасында «Кванториумнар» ачылды, аларга бүген Казанның 1 500 дән артык укучысы йөри. Алар укучыларда заманча компетенцияләр һәм күнекмәләр, шул исәптән табигый-фәнни, математик, мәгълүмат ягыннан белемне үстерү, тәнкыйди һәм алдынгы фикерләүне формалаштыру максатыннан гомуми белем бирүнең эчтәлеген киңәйтүне тәэмин итәргә тиеш.

**Проектлар һәм программалар**

«Пилотсыз авиация системалары» илкүләм проектының «Илебезнең пилотсыз авиация системаларына ихтыяҗны үстерү» федераль проекты кысаларында Казанның алты мәктәбе базасында махсуслаштырылган сыйныфлар ачылды. Биналарга ремонт ясалды, җиһазлар урнаштырылды, милли проект нигезендә брендлау башкарылды.

Әлеге махсуслаштырылган сыйныфларның төп максаты – мәгариф оешмаларында укучыларны һәм белем алучыларны пилотсыз авиация системаларын эшләү, җитештерү һәм эксплуатацияләү буенча белем алу мөмкинлекләренә массакүләм җәлеп итү.

Казан шәһәре укучыларында экологик культура формалаштыру максатыннан, табигать белән сак эш итүнең гамәли күнекмәләрен үстерү, әйләнә-тирә мохитне системалы рәвештә өйрәнү һәм табигатьне саклау чараларында актив катнашу юлы аша 2025 елдан «Яшел эшләр шәһәре» проекты гамәлгә ашырыла, аның кысаларында шәһәрнең барлык белем бирү

оешмаларында экология һәм табигатьне саклау акцияләре, экология бәйрәмнәре, уеннар, лекцияләр һәм иҗади конкурслар үткәрелә.

Дүртенче ел рәттән шәһәребездә «Дуслык тәпие» грант конкурсы тормыш-ка ашырылып килә. Конкурс нәтиҗәләре буенча Казанның 24 белем бирү учреж-дениесе үз проектларын үстерү һәм популярлаштыру өчен грант ярдәме алачак.

2025 елда 178 төп һәм урта белем бирү оешмасы, шулай ук 107 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе базасында «Беренчеләр хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең 232 беренчел бүлекчәләре ачылды, аларда барлыгы 85 945 бала тәрбияләнә. Ел саен 50 меңнән артык бала чараларда һәм конкурсларда катнаша.

1-4 нче сыйныф укучылары өчен «Россия бөркетчекләре» программасы тормышка ашырыла, 3 500 дән артык беренче сыйныф укучысы хәрәкәткә керде һәм атрибутика алды.

2025 елда Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендә патриотик тәрбия үзәкләре ачылды, алар белем бирү оешмалары хезмәткәрләренә консультатив-методик ярдәм күрсәтәләр, шулай ук район һәм шәһәр дәрәҗәсендә патриотик чаралар үткәрәләр (139 номерлы гимназия, 67 номерлы мәктәп, 101 номерлы мәктәп, 60 номерлы мәктәп). 60 номерлы мәктәп территориясендә «Бердәмлек» хәрби-патриотик үзәген ачу планлаштырыла.

Өченче ел инде «Казан мәгарифе командасы» конкурсы уздырыла. 2025 ел нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Совет районының «332 номерлы катнаш төрдәге балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Киров районының «“Сәяхәт” балаларга өстәмә белем бирү үзәге» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе һәм Казан шәһәре Киров районының «182 номерлы политехник лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе абсолют җиңүче булдылар.

Номинацияләрдә түбәндәгеләр җиңүче булды:

- «Коммуникация лидеры» – Казан шәһәре Совет районының «185 номерлы күппрофильле лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Идел буе районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 130 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;
- «Инновацияләр лидеры» – Казан шәһәре Мәскәү районының «Л.М.Мурысин исемендәге 94 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Катнаш төрдәге 380 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Совет районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 112 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Ел инициативасы» – Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 54 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Идел буе районының «Катнаш төрдәге 71 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Катнаш төрдәге 26 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Ел ачышы» – Казан шәһәре Совет районының «108 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе», Казан шәһәре Совет районының «Катнаш төрдәге 114 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Идел буе районының «Баланы үстерү үзәге – 383 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Ел нәтиҗәләре» – Казан шәһәре Яңа Савин районының «Аерым фәннәр тирәнтен өйрәнелә торган 71 номерлы татар-рус урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Идел буе районының «Баланы үстерү үзәге – 106 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Корпоратив культура лидеры» – Казан шәһәре Яңа Савин районының «31 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Яңа Савин районының «Катнаш төрдәге 151 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Ел алга китеше» – Казан шәһәре Совет районының «126 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Идел буе районының «35 номерлы лицей – “Галактика” мәгариф үзәге» муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесенең мәктәпкәчә бүлеге;

- «Традицияләрне саклаучылар» – Казан шәһәре Киров районының «15 номерлы татар гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Киров районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 321 номерлы балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Һөнәргә тугрылык» – Казан шәһәре Киров районының «153 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «Катнаш төрдәге 404 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, Казан шәһәре Мәскәү районының «Татар телендә тәрбия һәм белем бирүче катнаш төрдәге 355 номерлы балалар бакчасы» муниципаль автоном мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе;

- «Ел эшлеклесе» – Казан шәһәре Вахитов районының «98 номерлы урта гомуми белем бирүче татар-рус мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

- «Прогресс драйверы» – Казан шәһәре Яңа Савин районының «360 номерлы прогимназия» мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен муниципаль автоном гомуми белем бирү учреждениесе.

**Террорчылыкка каршы торучанлык**

2025 елда Казан шәһәре белем бирү учреждениеләренең террорчылыктан сакланганлыгын тәэмин итү чаралары башкарылды, шул исәптән:

- 5 учреждение территориясенең коймаларын ремонтлау;

- 3 учреждение территориясенә керү/чыгу юлында контроль-үткәрү пункты урнаштыру;

**Белем бирү учреждениеләрен ремонтлау**

2025 елда «Гаилә» илкүләм проекты, «Гаиләгә ярдәм» федераль проекты буенча 2 балалар бакчасында 130,1 млн сумлык капиталь ремонт эшләре башкарылды: Казан шәһәренең Совет районында Каштан урамы, 6 йорт адресы буенча 415 номерлы балалар бакчасы һәм Казан шәһәренең Яңа Савин районында Я.Гашек урамы, 9а йорт адресы буенча 302 номерлы балалар бакчасы.

«Яшьләр һәм балалар» милли проекты, «Балаларга иң яхшысы» федераль проекты буенча Ю.Фучик урамы, 147 йорт адресы буенча урнашкан 125 номерлы гимназиядә ремонт эшләре башкарылды. Анда түбә ремонтланды, бөтен бинада тәрәзәләр алыштырылды, спорт залы һәм профиль кабинетлары яңартылды, уку йорты өчен яңа җиһазлар һәм мебель алынды. Россия Федерациясе Герое майор С.А.Ашихмин исемендәге 130 номерлы мәктәп бинасында ремонт эшләренең икенче этабы башкарылды. Инженерлык челтәрләрен алыштыру һәм кабинетлар белән ял зоналарында бизәү эшләре, фасадны ремонтлау эшләре тәмамланды.

Агымдагы ремонт кысаларында 120 учреждениедә (50 гомуми белем бирү учреждениесендә, 67 балалар бакчасында, 3 өстәмә белем бирү учреждениесендә) гомуми бәясе 450 млн сумлык эш башкарылды.

**2026 елга планнар:**

- «Станция Спортивная» торак комплексында мәктәп төзү;

- А.Алиш исемендәге шәһәр балалар иҗаты сараенда капиталь ремонт эшләрен башкару;

- «89 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен капиталь ремонтлау;

- «Россия Федерациясе Герое майор С.А.Ашихмин исемендәге 130 номерлы мәктәп» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясен төзекләндерү эшләрен башкару һәм җиһазлар сатып алу;

- «Олимп» балалар иҗаты үзәген төзү буенча проект документациясен әзерләү;

- Казан шәһәре мәгариф хезмәткәрләре йортының яңа бинасын төзеп бетерү.

Моннан тыш, 2026 ел Россия Федерациясендә Россия халыклары бердәмлеге елы, ә Татарстан Республикасында хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы дип игълан ителүгә бәйле рәвештә, тәрбия эшләре кысаларында балаларда һәм яшьләрдә илнең күпмиллләтле һәм күпконфессияле составына хөрмәт тәрбияләүгә, милләтара татулыкны һәм үзара аңлашуны ныгытуга, гражданлык җаваплылыгы, патриотизм, Россия Федерациясе халыкларының рухи мирасына һәм традицияләренә сакчыл мөнәсәбәт, шулай ук Ватанны саклаучыларның һәм тыл хезмәтчәннәренең батырлыкларына, хезмәт сөючәнлегенә һәм буыннарның дәвамчанлыгына хөрмәт тәрбияләүгә аерым игътибар биреләчәк.

Эшнең төрле юнәлешләре буенча, шулай ук Россия Мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы планнары нигезендә план буенча проектларны гамәлгә ашыру дәвам итәчәк.

## Мәдәният

Казан шәһәрендә 2025 ел мәдәни вакыйгаларга бай булды. Ел саен үткәрелә торган проектларны һәм программаларны гамәлгә ашырудан тыш, безнең шәһәр беренче тапкыр популяр музыка яшь башкаручыларының «Новая волна» халыкара конкурсын һәм ачык һавада VK Fest музыкаль-күңел ачу фестивален кабул итте. Шулай ук «Алтын мөнбәр» Казан халыкара кинофестивале, «Игелекле дулкын» бөтенроссия балалар иҗаты мәдәни-хәйрия фестивале һәм башкалар узды.

Мондый масштаблы чараларга әзерләнү мәдәният тармагы хезмәткәрләреннән дә зур тырышлык таләп итте.

Бүгенге көндә Казан шәһәрендә төрле оешмаларга караган 400 дән артык мәдәният учреждениесе һәм оешмасы эшләп килә, 107 объект исә Казан шәһәре Башкарма комитеты карамагында.

Казан шәһәрендә яшәүчеләргә Үзәкләштерелгән китапханә системасы тарафыннан китапханә хезмәте күрсәтелә. Ул Үзәк китапханәне, Үзәк балалар китапханәсен, 47 филиалны һәм 3 китапханә пунктын үз эченә ала.

Китап укучылар саны – 198 079 кеше. Халыкны китапханә хезмәте белән тәэмин итү 17 процентны тәшкил итә. Китап фондында 2 555 921 нөсхә басма исәпләнә. Бер шәһәр кешесенә – 3 китап, бер укучыга 13 китап туры килә. Бирелгән китаплар саны – 4 591 237 данә.

Китапханәләрнең китап фондларын туплау өчен шәһәр тарафыннан тотылган акчаның гомуми күләме – 7 485,96 мең сум. 49 китапханәнең барысы да компьютерлар белән җиһазландырылган һәм Интернеттан файдалану мөмкинлеге белән тәэмин ителгән, 40 китапханәдә Wi-Fi нокталары урнаштырылган.

«Гаилә кыйммәтләре һәм мәдәният инфраструктурасы» федераль проекты кысаларында Побежимов урамы, 47 йорт адресы буенча урнашкан китапханәдә 18,4 млн сумлык ремонт эшләренең беренче этабы тәмамланды.

Шәһәр халкына иҗади мөмкинлекләрен гамәлгә ашыруда **16 муниципаль мәдәният йорты, шулай ук 3 мәдәни-ял учреждениесе (Рок мәктәбе, «Оперение» иҗади үсеш студиясе, «Апуш» балалар татар театр студиясе)** ярдәмгә килә.

Мәдәният йортлары тарафыннан тәкъдим ителә торган мәдәни хезмәтләр һәм чаралар спектры күптөрле, үсештә һәм Казан халкы ихтыяҗларына җавап бирә.

2025 елда Казан шәһәрендә халыкның төрле төркемнәренең социаль-мәдәни инициативаларына һәм һәвәскәрләр иҗатына ярдәм итү максатыннан 808 клуб берләшмәсе үз эшчәнлеген башкарды, аларда 15 759 кеше катнашты. Әлеге берләшмәләрнең гомуми саныннан 549 ы үзешчән халык иҗаты берләшмәләре булып тора, шул исәптән 365 е – 14 яшькә кадәрге балалар өчен, аларга 6 633 кеше җәлеп ителгән.

2025 елда Казан шәһәренең мәдәни-ял итү тибындагы учреждениеләре көче белән 7 304 чара уздырылды, шуларның 2 922 се (41%) – 14 яшькә кадәрге балалар өчен.

**«Яшәү яме» социаль проекты** өлкән яшьтәге кешеләргә иҗади, физик эшчәнлек һәм танып-белү эшчәнлеге белән бушлай шөгыльләнергә мөмкинлек бирә. «Яшәү яме» чаралары шәһәрнең 106 мәйданчыгында – мәдәният йортларында, китапханәләрдә, спорт объектларында, ә җәйге чорда паркларда, скверларда һәм яр буйларында уза. Проект 20 дән артык юнәлеш буенча гамәлгә ашырыла, алар арасында бигрәк тә бию, вокал, сәламәт яшәү рәвеше һәм мобиль ликбез юнәлешләре актуаль. Мәдәният учреждениеләрендә уза торган чараларга йөрү өлешендә проектның еллык күрсәткече – 190 000 визит.

**Апуш» балалар татар театр студиясе** үз эшчәнлеген дәвам итә.

10 августтан 24 августка кадәр Татарстанның Әтнә районында беренче тапкыр Туфан Миңнуллин исемендәге лагерь форматындагы «Күзлек» балалар театр лабораториясе узды, ул драматургның 90 еллыгына багышланган һәм Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә «Апуш» студиясе тарафыннан оештырылган иде.

Лабораториядә «Апуш» балалар театр студиясендә һәм Әлмәт, Чаллы, Минзәлә, Әтнә, Саба, Балтач, Апас, Арча районнарының театр студияләрендә тәрбияләнүче 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге 117 бала катнашты. Лаборатория кысаларында алар төрле мастер-классларда, чакырылган кунаклар белән иҗат кичәләрендә катнаштылар. Шулай ук балалар белән берлектә Туфан Миңнуллин пьесалары буенча эскизлар әзерләнде. 25 августта Г.Камал

исемендәге Татар дәүләт академия театрының яңа бинасында узган «Күзлек» фестивале ике атналык лабораториянең йомгаклау чарасы булды.

**Музейлар һәм хәтерне мәңгеләштерү**

Казан шәһәренең музей мирасы фонды бик бай. Музей комплексы составына Константин Васильевның картиналар галереясы, Бакый Урманче музее, Әмир Мәҗитов музее, Илдар Зариповның галерея-студиясе, «Хәтер китабы» мемориалы һәм В.П.Аксеновның музей-йорты, шулай ук Казан шәһәренең Рус фольклоры үзәге керә.

Музей эшчәнлеге мәдәни мирас объектларын туплауны, исәпкә алуны, саклауны һәм өйрәнүне, шулай ук экспозиция һәм фонд эшен үз эченә ала.

Музей комплексы фондларында 54 801 предмет исәпләнә. Төп фондка 36 440 саклау берәмлеге һәм фәнни-ярдәмче фондка 18 361 саклау берәмлеге карый. Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт каталогына 36 440 предмет кертелде. 2025 елда 18 яңа экспонат сатып алынды. Экспозициянең гомуми мәйданы – 780 кв.м, ә фонд саклагычы 284 кв.м мәйданны били. 2025 елда музейларда 110 859 кеше булды.

Музейлар түбәндәге социаль проектларны гамәлгә ашыра: «Гаилә белән килү», һәр айның беренче сишәмбесендә бушлай керү, 18 яшькә кадәрге балалар өчен бушлай керү, «Батыр» картасы буенча керү, «Пушкин картасы» проекты.

Хәтерне мәңгеләштерү эшләре кысаларында мемориаль такталар һәм һәйкәлләр ачылды:

Казан шәһәренең Җиңү паркында Сухов Иван Степановичка (19.09.1907 – 11.10.1976), Тихонов Павел Ивановичка (12.07.1908 – 28.09.1946), Ульянов Иван Михайловичка (22.01.1914 – 15.02.1986) элегрәк куелмаган истәлек такталары урнаштырылды.

Шулай ук Т.А.Миңнуллинга, К.А.Абрамовка, Г.К.Мосоловка, Татарстан Республикасы эчке эшләр органнары ветераннары – 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында катнашкан Б.А.Ботовка, Ф.И.Горшковка, В.П.Шихобаловка мемориаль такталар куелды.

**Башлангыч музыка һәм сәнгать белеме бирү**

Бүген 6 яшьтән 15 яшькә кадәрге һәр өченче бала Казан шәһәренең музыка яки сәнгать мәктәбендә белем ала.

2024-2025 уку елында сәнгать мәктәпләрендә укучы балалар халыкара, бөтенроссия һәм төбәкара, республика һәм шәһәр конкурсларында катнаштылар. 750 бала лауреат һәм дипломант исеменә лаек булды.

2025 елда 6 номерлы балалар музыка мәктәбе укучысы Даниэль Дульнев һәм 18 номерлы балалар музыка мәктәбе укучысы Софья Сабирҗанова Иветта Воронова исемендәге «Яңа исемнәр» хәйрия фонды стипендиатлары булдылар.

16 бала Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясе белән бүләкләнде. 25 мәктәптән 51 укучы конкурс тыңлауларын һәм карауларын узды. Әлеге чараларда жюри әгъзалары сыйфатында Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт

консерваториясенең, И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллиятенең, Н.И.Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесының иң яхшы педагоглары, Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге һәм Россия Федерациясе Рәссамнар берлеге әгъзалары катнашты.

Ел саен сәнгать мәктәпләренең иң яхшы укытучыларына К.Васильев исемендәге премия тапшырыла. 2025 елда жюри тарафыннан ачык дәресләр каралды, аларның нәтиҗәләре буенча ике җиңүче ачыкланды: Ларионова Наталья Владимировна – 7 номерлы балалар сәнгать мәктәбе педагогы һәм Вәлиева Наилә Рафаил кызы – 4 номерлы балалар сәнгать мәктәбе педагогы.

Пак Вадим Павлович, 18 номерлы балалар музыка мәктәбенең фортепиано классы буенча яшь укытучысы, Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Балалар сәнгать мәктәбенең иң яхшы укытучысы» конкурсында 35 яшькә кадәрге «Иң яхшы яшь укытучы» номинациясендә катнашып, 1 нче урынны яулады.

Балалар җыелма коллективларын үстерү эше дәвам итә. Татарстан Республикасы яшьләр симфоник оркестры, җыелма шәһәр симфоджаз-оркестры, Казан шәһәренең балалар тынлы оркестры, Балалар халык уен кораллары оркестры, җыелма хор – шулар арасында. Коллективлар шәһәр күләмендә уздырыла торган эре чараларда катнашалар, шулай ук югары һөнәри казанышлары белән уртаклашалар.

Д.И.Железнов җитәкчелегендәге малайлар капелласы «Ну-ка, все вместе! Хором!» телевизион проектында җиңү яулады. Коллектив шулай ук төрле чараларда, концертларда, конкурсларда чыгыш ясап, шәһәрнең иҗади тормышында актив катнаша.

Россия Федерациясенең атказанган артисты Аида Гарифуллина патронажы астында уткәрелгән «Татарстанның яшь виртуозлары» республика конкурсы – Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәге ярдәме белән «Татарстан Республикасының иҗади музыка академиясе» кысаларында гамәлгә ашырылган уникаль проект. Конкурс түләүсез нигездә уза, керү взнослары юк, шуңа күрә анда һәркем катнаша ала. 2025 елда конкурста Казаннан һәм Татарстан Республикасы районнарыннан 500 гә якын талантлы бала катнашты.

2025 елның 6 июнендә С.Сәйдәшев исемендәге Дәүләт зур концертлар залында конкурс җиңүчеләренең гала-концерты узды. Өч сайлап алу турын узган яшь музыкантлар, София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәгенең профессиональ оркестры, Татарстан Республикасы Дәүләт камера хоры һәм Д.И.Железнов капелласы белән бергә солистлар сыйфатында чыгыш ясады. Шулай ук концертта Россиянең һәм Татарстанның атказанган артисты Аида Гарифуллина катнашты.

**«Пушкин картасы», «PRO.Культура.РФ» цифрлы платформасын үстерү**

2025 елда муниципаль мәдәният учреждениеләре тарафыннан «Пушкин картасы» федераль проекты кысаларында 29 908 010 сумлык 56 792 билет сатылды.

«PRO.Культура.РФ» порталында – мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрне һәм чараларны үстерү өчен цифрлы платформада – 2025 елның 1 гыйнварыннан 10 030 чара басылып чыкты, 1 083 трансляция уздырылды, сайтка керүләр саны – 1 152 286.

**Профессиональ сәнгатьне** Казан шәһәр филармониясенең, La Primavera Казан камера оркестрының һәм София Гобәйдуллинаның Заманча музыка үзәгенең уникаль коллективлары тәкъдим итә. 2025 ел дәвамында профессиональ коллективлар тарафыннан Казанда 187 концерт бирелде, аларны 1 145 149 кеше карады.

**Казан зооботаника бакчасы** уникаль учреждение булып санала. Хәзерге вакытта аның зоология коллекциясендә хайваннарның 143 төре, 4719 экземпляры теркәлде. Ботаника коллекциясендә исә үсемлекләрнең 1136 төре, 11 348 экземплярына исәпләнә. 2025 елда коллекция Хабаровскидан китерелгән һәм кызыл китапка кертелгән ике амур юлбарысы белән тулыланды, алар өчен «Замбези елгасы» комплексының яңа өлешендә вольер төзелде.

**Шәһәр чаралары**. Ел дәвамында Татарстан башкаласында күпсанлы музыкаль, әдәби проектлар һәм мәдәни-массакүләм чаралары тормышка ашырылды: Нәүрүз, Май чабу, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы, Россия көне, «Китап-фест» әдәби-музыкаль фестивале, «Мәдәни чәршәмбеләр» проекты, «Урын гение» проекты, Татарстан Республикасы көне һәм Казан шәһәре көне, сайлау кампанияләре кысаларында тавыш бирү көннәрендә бәйрәм программасы белән Гаилә фестивале, Яңа ел чаралары. «Йөрәк белән тыңлап», «Игелекле дулкын» хәйрия проектлары, «Нур» фестивале, «Кулга-кул тотыныйк, дуслар!» фестивале, Ватанны саклаучылар елы кысаларындагы проектлар тормышка ашырылды.

Моннан тыш, Казан беренче тапкыр популяр музыка яшь башкаручыларының «Новая волна» халыкара конкурсын кабул итте, аны үткәрү өчен шәһәрдә махсус корылма – «Ак Барс Арена» стадионы парковкасы территориясендә New Wave Hall залы төзелде. Шулай ук Казанда беренче мәртәбә ачык һавада VK Fest музыкаль-күңел ачу фестивале узды.

Мирный торак массивы Каенлыгында узган Казан Сабан туеның театральләштерелгән прологы гаиләдәге традицияләрне саклауны һәм аларны алдагы буынга тапшыруны гәүдәләндерде. Бәйрәмдә Карл Фукс тасвирлаган борынгы сәүдәгәр йорты атмосферасы милли орнамент һәм стиль элементлары белән яңадан торгызылды. Килгән һәр кунак милли ризыклар әзерләү, татар биюе элементларын өйрәнү буенча һәм башка шундый мастер-классларда катнаша алды.

Бишенче ел рәттән Шәһәр көне алдыннан Казан Мэриясе бинасы балконнарында «Голоса Казани» / «Казан тавышлары» театральләштерелгән перформансы уза. Юбилей елында тамашаның темасы «Летучая мышь» иде.

Җәйге чорда чәршәмбе көннәрендә шәһәрнең һәр районында иҗтимагый киңлекләр территорияләрендә «Мәдәни чәршәмбе» проекты гамәлгә ашырылды, аның кысаларында теләгән һәркем тематик мастер-классларда катнаша, шәһәрнең иҗат коллективлары концертларын тыңлый алды.

2025 елда 18 нче «Аксенов-фест» әдәби-музыкаль фестивале документалистикага багышланды: «ДокПроза. ДокКино. ДокТеатр». Быел фестиваль катнашучылары – Россия һәм чит ил язучылары белән иҗади очрашулар Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә, шәһәр китапханәләрендә, В.П.Аксеновның музей-йортында, Балыкчы бакчасында һәм Аксенов скверында, шулай ук «Елмай» паркында узды. Традиция буенча «Йолдызлы билет» премиясен тапшыру тантанасы булды.

2025 елда Казанның паркларында һәм скверларында 2 748 чара үткәрелде, аларда 2 313 500 дән артык кеше катнашты: кышкы һәм җәйге программалар, экскурсияләр, спорт һәм мәдәни программалар, фильмнар күрсәтелде.

«Елмай» балалар паркының беренче җәйге программасы 150 000 кеше катнашкан 160 тан артык чараны үз эченә алды, шул исәптән сентябрь аенда «Интервидение» халыкара җыр бәйгесенең турыдан-туры трансляциясе булды, аңа кадәр җирле артистлар катнашында концерт программасы тәкъдим ителде.

5 сентябрьдә Горький паркында татар җырчысы Илһам Шакиров истәлегенә зур концерт-трибьют булды. 50 дән артык музыкант легендар башкаручының композицияләрен заманча эшкәртүдә тәкъдим итте. Вакыйганы 12 000 нән артык тамашачы карады.

Кышкы сезонда тотрыклы үсешкә аерым игътибар бирелде: «Шәһәр кешесе-галим» шәһәр лабораториясе сигез экологик белем бирү дәресе үткәрде, Казансу яры буендагы экостанция иҗади мастер-класслар тәкъдим итте, «Урман һәм елга» глэмпингында кышкы эколагерь экскурсияләр, төрле мастер-класслар, чаңгы һәм тимераякта шуу оештырды.

Паркларда инклюзив программа рус ишарәләр теленә тәрҗемә итү һәм тифлокомментарийлар белән үрелеп барды, шулай ук «Ак Чәчәкләр» бульварында мастер-класслар үтте, «Казан» Гаилә үзәгендә сукырлар өчен экскурсияләр һәм фильмнар күрсәтелде, Серов урамындагы бульварда аерым программа һ.б. үткәрелде.

**2026 елга планнар**

2026 елга өстенлекле бурычларның берсе – тотрыклы үсеш принцибына нигезләнеп мәдәният тармагын үстерү, алынган «Ислам дөньясының мәдәни башкаласы» исеме кысаларында 2026 елда чаралар үткәрү.

Моннан тыш, халыкны Казанның мәдәни тормышына җәлеп итү, үсеп килүче буынга эстетик тәрбия бирү, шәһәр халкы өчен ял итү, китапханә

хезмәтләре һәм өстәмә белем бирү сыйфатын яхшырту эшләре тагын да дәвам итәчәк.

2026 елда, татар милли мәдәниятен саклау һәм популярлаштыруга басым ясап, Татарстан Республикасында хәрби һәм хезмәт батырлыгы елына һәм Россия Федерациясендә Россия халыкларының бердәмлеге елына багышланган, шулай ук татар шагыйре Габдулла Тукайның 140 еллыгына һәм шагыйрь-герой Муса Җәлилнең 120 еллыгына багышланган мәдәни башлангычларны актив үстерү планлаштырыла.

## Физик культура һәм спорт

Казан шәһәрендә физик культураны һәм спортны массакүләм үстерү, шәһәрлеләрне физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә тарту өчен шартлар тудыру 2025 елның төп бурычларыннан берсе булып торды.

2026 елның 1 гыйнварына башкалада физкультура һәм спорт белән даими рәвештә шөгыльләнүчеләр саны якынча 800 мең кешене тәшкил итте, бу 3 яшьтән 79 яшькә кадәрге казанлыларның гомуми санынннан 68,1% дигән сүз (2025 елның 1 гыйнварына – 66%).

**Спорт объектларын төзү һәм ремонтлау**

Яңа спорт корылмаларын төзү федераль, республика һәм башка программалар кысаларында гамәлгә ашырыла. 2026 елның 1 гыйнварына шәһәребездә 2 438 спорт объекты исәпләнә. 2025 ел дәвамында аларның саны 51 берәмлеккә (2025 елда – 2 387 берәмлек) артты.

Универсаль спорт мәйданчыклары һәм аз чыгымлы спорт корылмалары төзү буенча 2013 елдан гамәлдә булган республика программасы кысаларында Казанда 300 млн сумнан артык суммага 136 спорт мәйданчыгы төзелде һәм файдалануга тапшырылды.

Хисап елында Казанда гомуми бәясе 47,5 млн сум булган өч баскетбол-волейбол мәйданчыгы, мини-футбол өчен өч мәйданчык һәм бер тренажерлар мәйданчыгы төзелде.

2025 елда спорт учреждениеләрен капиталь ремонтлау буенча еллык программа кысаларында, гомуми бәясе 200 млн сумнан артык булган эшләр тәмамланды. «Хезмәт резервлары» (төп корпусны капиталь ремонтлауның икенче этабы: фасадны, түбә, инженерлык челтәрләрен ремонтлау, бокс залын яңарту), «Ракета» (җылылык системаларын алмаштыру, җылылык пунктын ремонтлау, өлешчә фасад һәм трибуналарны ремонтлау), «Тасма» (җиңел атлетика манежы бинасының фасад өлешен ремонтлау) стадионнарында ремонт эшләре башкарылды. Шулай ук «Смена» спорт мәктәбенең административ бинасында түбә һәм тәрәзәләрне алыштыру буенча ремонт эшләре үткәрелде.

2025 елда өч яңа спорт объекты төзелде: «Рубин» футбол клубы базасында Футболны үстерү үзәге, Короленко урамында Фехтование үзәге һәм

«Континент» паркында спорт мәйданчыгы. Төзелешнең гомуми бәясе 5,7 млрд сумнан артып китте.

2025 елның августында «Тасма» стадионында Уктан ату үзәге төзелешенә беренче таш салу тантанасы булды, шулай ук Порт һәм Девятаев урамнары арасындагы территориядә Фигуралы шуу үзәген төзүгә старт бирелде.

«Бизнес-спринт» федераль проекты кысаларында, концессия килешүе буенча «Салават Күпере» торак комплексында «Спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү комплексын төзү эшләре дәвам итә.

**Проектларны һәм программаларны финанслау**

2025 елда 27,17 млн сумлык спорт җиһазлары, инвентарь һәм экипировка сатып алынды.

2025 елда массакүләм спорт өлкәсендә физик культура һәм спорт чараларын оештыру һәм үткәрүдә финанслауның гомуми күләме 68,8 млн сум тәшкил итте.

**Спорт мәктәпләре эшчәнлеге**

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә 19 муниципаль спорт учреждениесе эшли, аларда 48 спорт төре буенча 18 765 кеше шөгыльләнә.

Казан шәһәренең спорт мәктәпләрендә 642 тренер (540 – штатта, 102 – икенче эш урыны буларак) эшли.

Казан шәһәренең муниципаль спорт мәктәпләрендә спортның иң массакүләм төрләре булып футбол, җиңел атлетика, нәфис гимнастика, хоккей, йөзү санала.

Муниципаль спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче 1 906 спортчы Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе җыелма командалары составына керә, шулардан:

- 1 781 кеше Татарстан Республикасы җыелма командаларында;
- 125 кеше – Россия Федерациясе җыелма командаларында вәкил булып тора.

Гадәттәгечә җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында яшь спортчылар балалар лагерьларында ял итте. Әйтик, «Тасма» балалар сәламәтләндерү лагеренда 2025 елда да, 2024 елдагы кебек үк, бер сменаның дәвамлылыгы 18 көнне тәшкил итте, 1 160 кешегә барлыгы 4 смена (сменага 290 бала) оештырылды.

«Яшь гвардия» спорт-сәламәтләндерү лагеренда бер сменаның дәвамлылыгы шулай ук 18 көнне тәшкил итте, барлыгы 4 смена оештырылды, аларда 1840 кеше ял итте. Шулай ук язгы, көзге һәм кышкы чорларда 300 кешене колачлаган 7 шәр көнлек берәр смена үткәрелде (һәр сменада 100 бала).

2025 елда муниципаль спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүче 18 яшькә кадәрге балалар Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясен алу буенча конкурста катнаштылар.

Конкурс нәтиҗәләре буенча стипендия шәхси спорт төрләрендә – муниципаль спорт мәктәпләрендә шөгыльләнүче 12 кешегә, спортның команда

төрләрендә олимпия резервының «Ак Барс» спорт мәктәбенең 2011 елда туган спортчылар командасына билгеләнде.

Спорт мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләр 2025 елда ирешкән иң яхшы күрсәткечләр:

- йөзү буенча Россия чемпионатында Россиядә яшүсмерләр арасында яңа рекорд (Софья Дьякова);

дөнья беренчелекләре:

- йөзү буенча Европа беренчелегендә 2 алтын медаль (Софья Дьякова);
- яшүсмерләр арасында йөзү буенча Европа беренчелегендә 1 бронза медаль (Софья Дьякова);
- спорт гимнастикасы буенча дөнья чемпионатында 1 бронза медаль (Даниел Маринов);
- 18 яшькә кадәрге яшүсмерләр арасында көрәш буенча дөнья беренчелегендә бронза медаль (Данил Әүхәдиев);
- билбау көрәше буенча дөнья чемпионатында көмеш медаль (Айнур Нургалиев);

халыкара ярышлар:

- самбо буенча «Татарстан Республикасы Рәисе Кубогы» халыкара Гран-при ярышларында 1 алтын медаль (Магомед Гасанов);
- самбо буенча «Татарстан Республикасы Рәисе Кубогы» халыкара Гран-при ярышларында бронза медальләр (Рамис Уразаев, Илья Алексеев);
- 2008-2009 елгы яшүсмерләр арасында Lida Open спорт көрәше (грек-рим көрәше) буенча халыкара турнирда 1 бронза медаль (Эрик Сөләйманов);
- 21 яшькә кадәрге яшүсмерләр арасында СССРның атказанган спорт мастеры, олимпия уеннары чемпионы Р.М.Дмитриев истәлегенә багышланган спорт көрәше (ирекле көрәш) буенча халыкара ярышларда 1 алтын медаль (Демьян Макаров).

Моннан тыш, Казанның яшь спортчылары спорт һәм нәфис гимнастика, йөзү, бокс, каратэ, самбо, өстәл теннисы, җилкәнле спорт, җиңел атлетикада күп төр ярышлар, триатлон һәм башкалар буенча Россия чемпионатларында һәм беренчелекләрендә алтын, көмеш һәм бронза медальләр яуладылар.

**Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар белән эшләү**

Халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп максатларыннан берсе – халыкның барлык категорияләренә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен комплекслы шартлар, шул исәптән сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен тигез шартлар тудыру.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрнең барлык категорияләре өчен уңайлы шартлар тәэмин итү максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан «Спорт – бердәм киңлек» проекты эшләнде, аның нигезендә һәр спорт объектында, бушлай дәресләрдән тыш, сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар һәм олылар өчен ташламалы нигездә шөгыльләнү каралган. Проект инвалид балаларның, 1 нче төркем инвалидларны

озатып йөрүче затларның, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган ятим балаларның, әти һәм әни кешенең икесе дә 1 нче яки 2 нче төркем инвалид булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларның мәнфәгатьләрен исәпкә ала һәм аларга хезмәтләрдән бушлай файдалану хокукы бирә. Әлеге затлар арасында йөзү һәм дәвалау физкультурасы кебек спорт төрләре популяр.

Хоккей, футбол һәм йөзү кебек массакүләм спорт төрләре дә зур кызыксыну уята.

«Стрела» спорт мәктәбе базасындагы «Баско» боз аренасында следж-хоккей буенча командага һәм менталь тайпылышлары булган балалар өчен махсус хоккей буенча бушлай күнекмәләр уздыруга вакыт бүлеп бирелә.

Бушлай күнекмәләр уздыру өчен вакыт бүлеп бирү буенча эш оештырылган һәм адаптив физик культура инструкторлары катнашында дәресләр үткәрелә торган муниципаль объектлар эшчәнлеге турында тулы мәгълүмат Казан шәһәре Башкарма комитеты Физик культура һәм спорт комитетының www.kzn.ru порталындагы сәхифәсендә урнаштырылган.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар өчен объектлардан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү эше дә дәвам итә. Пандуслар, күтәргеч җайланмалар, киңәйтелгән керү төркемнәре, санитар узеллар һәм душ бүлмәләре булган, шул исәптән коляскадагы инвалидлар өчен тулысынча җайлаштырылган объектлар арасында түбәндәгеләр бар:

- Идел буе районындагы «Акчарлак», Совет районындагы «Ракета», Авиатөзелеш районындагы «Триумф», Яңа Савин районындагы «Ватан» йөзү бассейннары;

- Казан шәһәренең Совет районындагы «Ак бүре», «Бокс һәм өстәл теннисы үзәге» универсаль спорт заллары.

Объектларның якынча 60 проценты начар күрүчеләр өчен җайлаштырылган: юнәлеш бирүче плиткалар урнаштырылган, баскычларда ачык төстәге тамгалар ябыштырылган, Брайль шрифты белән язылган элмә такталар, тактиль күрсәткечләр бар. Ә трибуналары булган 18 объектның 17 сендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә әлеге трибуналардан файдалану мөмкинлеге тудырылган.

Объектларның инфраструктура һәм кадрлар белән тәэмин ителешеннән тыш, инвалидларны һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләрне физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итүнең мөһим инструментларыннан берсе – алар актив катнаша торган массакүләм спорт чараларын оештыру һәм үткәрү.

2025 елда гражданнарның әлеге категориясе өчен 47 чара уздырылды, аларда 1 500 дән артык кеше катнашты.

2025 елның 6-10 июнь көннәрендә иң мөһим чараларның берсе – Даун синдромлы затлар өчен йөзү буенча «Бергә җиңәчәкбез» бөтенроссия турниры узды. Ярышларда Россия Федерациясенең 34 төбәгеннән, шулай ук 4 илдән (Казахстан, Үзбәкстан, Италия, Белоруссия) 200 дән артык спортчы катнашты.

Моннан тыш, «Ярдәм» мәчете территориясендә Казанда сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр һәм паралимпиячеләр өчен төзелгән беренче спорт комплексында да дәресләр уза.

8 декабрьдә «Дан» спорт комплексында Инвалидлар үнкөнлеге кысаларында бочча, джакколо, корнхол, новус, кульбуто, шаффлборд, эстафета һәм каршылыклар полосасы, флорбол, футбол буенча «Көчле рухлылар» дип аталган традицион спорт бәйрәме оештырылды. Ярышларга инвалидлыкның барлык категорияләренә караган сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле казанлылар кертелде. Аларда барлыгы 50 кеше катнашты.

**Чаралар**

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан спортның 63 төре буенча 532 массакүләм спорт чарасы, шул исәптән 234 чемпионат һәм беренчелек, 53 кубок, 104 турнир һәм 84 массакүләм спорт чарасы, спартакиадалар кысаларында 57 чара үткәрелде. Аларда барлыгы 150 меңнән артык кеше катнашты.

Иң эре чаралар:

- «Россия чаңгы юллары» бөтенроссия массакүләм чаңгы ярышы;
- «Милләт кроссы» бөтенроссия йөгерү көне;
- яшь футболчыларның «Күн туп» бөтенроссия ярышлары;
- А.В.Тарасов исемендәге «Алтын алка» яшь хоккейчылар клубы призларына бөтенроссия ярышлары;
- шахмат буенча Казан шәһәре Мэры кубогы;
- урам баскетболы буенча «Кызгылт сары туп» бөтенроссия ярышлары;
- Бөтенроссия физкультурачылар көне кысаларында үткәрелә торган Казан спорты көне;
- Казан чаңгы марафоны;
- Казан җиңел атлетика марафоны;
- Даун синдромлы кешеләр өчен йөзү буенча «Бергә җиңәчәкбез» бөтенроссия турниры;
- Россиянең атказанган тренеры Ю.М.Красильников истәлегенә җиңел атлетика буенча бөтенроссия ярышлары;
- торак комплекслар арасында «Безнең ишегалды чемпионнары» шәһәр спартакиадасы.
- TIMERMAN чаралар сериясе: Казан милли ярыммарафоны, «Төнге Казан» йөгерү ярышы һәм СберПрайм Казан марафоны, шулай ук аның кысаларында марафон буенча Россия чемпионаты да узды.

Моннан тыш, 2025 елда муниципаль хезмәткәрләрнең «Спорт белән шөгыльләнүче Казан» спартакиадасы узды, анда 400 дән артык кеше спортның 9 төрендә көч сынашты. Җиңүче булып социаль блок бүлекчәләре командасы танылды. «Спорт белән шөгыльләнүче Казан» спартакиадасы нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы муниципаль хезмәткәрләре спартакиадасында катнашу өчен башкаланың җыелма командасы формалаштырылды.

Шулай ук «Озын гомер уеннары. Яшәү яме» спартакиадасының икенче сезоны оештырылды һәм уздырылды. Ярышлар Казанның барлык районнарыннан 4 000 нән артык спортчыны һәм 2 000 җанатарны берләштерде. Сезон дәвамында өлкән яшьтәгеләр спортның 10 төре буенча, шул исәптән шашка, мини-волейбол һәм «иң тугры җанатарлар» кебек яңа дисциплиналарда иң көчле исеме өчен көрәштеләр . Спартакиада ике этапта (район, шәһәр) һәм өч категориядә (һәвәскәрләр 55+, һәвәскәрләр 70+, спортчылар) уза. Спартакиада җиңүчесе булып Вахитов районы командасы танылды. Барлыгы 1 000 нән артык шәхси бүләк һәм 270 кубок тапшырылды.

«Яшәү яме» проекты кысаларында өлкән яшьтәге кешеләр өчен 20 муниципаль спорт объектына, күнекмәләр процессын төзеп, бушлай йөрү мөмкинлеге булдырылды, шулай ук башкала районнарындагы паркларда һәм скверларда атна саен скандинавия йөреше, зумба, сулыш гимнастикасы һ.б. буенча бушлай дәресләр үткәрелә.

**«Хезмәткә һәм оборонага әзер» комплексы**

Казан шәһәрендә системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче кешеләр санын арттырырга ярдәм итә торган «Хезмәткә һәм оборонага әзер» бөтенроссия физкультура-спорт комплексы проекты (алга таба – «ГТО» проекты) да уңышлы гамәлгә ашырыла.

Шәһәрнең төп сынау үзәге – «Хезмәт резервлары» спорт-сәламәтләндерү комплексы. Үзәк заманча һәм универсаль спорт объекты булып санала, анда ГТО ның барлык нормативларын диярлек үтәргә мөмкин.

2025 елда ГТО сынауларын үтүдә һәм аның күрсәтмә чараларында 61 меңнән артык кеше катнашты.

**2026 елга планнар:**

- физик культура һәм спорт белән системалы рәвештә шөгыльләнүчеләр санын арттыру;
- «Уникс-Юниор» спорт мәктәбе өчен «Казан шәһәрендә баскетбол үзәге» спорт объекты төзелешен башлау;
- «“Ракета” физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең «Ракета» стадионында, Казан шәһәренең «“Хезмәт резервлары” физкультура-спорт берләшмәсе» олимпия резервы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә, «Триумф» универсаль спорт комплексында һәм «Ватан» универсаль спорт комплексында капиталь ремонт эшләрен дәвам итү;
- концессия килешүе кысаларында «Салават күпере» торак комплексында «Спорт үзәге» физкультура-сәламәтләндерү комплексы төзелешен тәмамлау;
- «Волна» спорт мәктәбе территориясендә спорт мәйданчыкларын төзүне тәмамлау;
- «Тасма» стадионы территориясендә Уктан ату үзәге төзелешен тәмамлау;

- Казан шәһәренең Яңа Савин районындагы «170 номерлы лицей» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе территориясендә акыллы спорт мәйданчыгы төзелешен башлау;

- төрле дәрәҗәдәге ярышлар үткәрү.

## Яшьләр сәясәте

Казан шәһәренең яшьләр сәясәте яшьләргә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыруга, аларның социаль активлыкларын арттыруга, җәмәгать инициативаларына булышлык итүгә, яшьләр һәм үсмерләрнең мәшгульлеген оештыруга, яшьләр арасында асоциаль күренешләр таралуны кисәтүгә һәм аларга каршы торуга, балаларга һәм яшьләргә гражданлык, патриотик тәрбия бирүгә, аларның ялын оештыруга юнәлдерелгән.

**Матди-техник база**

2025 елда Казан шәһәренең «“Яшүсмер” яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клублары берләшмәсе» яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең ике яшьләр (яшүсмерләр) клубы ремонтланды: Левченко торак массивында – гомуми суммасы 13,31 млн сумга, «Компас» – гомуми суммасы 14,28 млн сумга. «Лидер» клубында 179,96 млн сумлык ремонт эшләре дәвам итә.

**Эшчәнлек юнәлешләре**

«Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе 69 объектны үз эченә ала. 2025 елда «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесенең иҗат һәм спорт берләшмәләрендә, 560 түгәрәгендә һәм секцияләрендә шөгыльләнүче балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр саны 20 500 кешегә җитте, шул исәптән 60 лап түгәрәк һәм секциядә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 144 бала шөгыльләнә.

2025 елда 50 000 нән артык кеше катнашында 30 шәһәр чарасы оештырылды һәм уздырылды, шул исәптән:

- кышкы һәм җәйге каникуллар чорында «Хобби-бокс» мобиль яшүсмерләр клубы шәһәрнең ерак микрорайоннарында яшәүче 1430 дан артык баланың һәм яшүсмернең ялын оештырды;

- 542 бала «Притяжение» программасында катнашты;

- «Вместе» проекты үз эшен дәвам итте. «Ата-ана + бала» форматындагы бушлай мастер-классларда 1 351 кеше катнашты;

- 2025 елның 1 июнендә яңа «Елмай» паркында яшүсмерләр клубларының «Мы там, где ты» дип аталган иҗат фестивале узды, анда 17 000 кеше катнашты.

2025 елда «Яңа Юдино» балалар сәламәтләндерү үзәгендә, махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән булган 23 баланың да ялын кертеп, 623 кешегә исәпләнгән 8 профильле смена оештырылды. Беренче

мәртәбә «Вертолет» яшьләр үзәге базасында «На взлет» көндезге лагерь эше оештырылды. 4 смена үздырылды, анда 100 бала катнашты.

«Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесендә төрле төрдәге исәптә торучы балигъ булмаганнарны яшүсмерләр клубларына җәлеп итү системасы булдырылды. 295 тәрбияләнүчене колачлаган 147 махсус чара уздырылды. Хәзерге вакытта төрле төрдәге исәптә торучы 65 бала «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе түгәрәкләренә/секцияләренә даими рәвештә йөри.

2025 елда «Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе коллективы «Балаларның ялын һәм күңел ачуын оештыру өлкәсендә предприятие хезмәтләре» номинациясендә «Иң яхшысы – балаларга» сыйфат билгесенә ия булды.

2025 елда барлыгы 4 204 кеше катнашында 219 патриотик чара: иҗади һәм гамәли мастер-класслар, патриотик акцияләр, спорт-ял итү программалары, конкурслар һәм күргәзмәләр, шулай ук гражданлык позициясен формалаштыруга, ил тарихы белән горурлануга һәм Ватанны саклаучыларның батырлыгына хөрмәт тәрбияләүгә юнәлдерелгән очрашулар һәм тематик дәресләр үткәрелде.

**Казан шәһәрендә балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыру**

2025 елгы сәламәтләндерү кампаниясе йомгаклары буенча каникуллар чорында шәһәрнең балалар лагерьларында 50 500 яшь казанлы ял итте һәм вакытын файдалы итеп уздырды. Бу эшкә 170 мәктәп яны, 27 шәһәр яны һәм 1 палаткалы лагерь җәлеп ителде.

Ел саен Казан лагерьлары программаларын уртак концепция берләштерә. 2025 елда илебез 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үтте. Бөек Ватан сугышы тарихы тематикасы «“Ял” балаларны сәламәтләндерү, ял иттерү, эш белән тәэмин итү шәһәр үзәге” яшьләр сәясәте муниципаль бюджет учреждениесенең барлык лагерьларында җәйге сменалар нигезенә салынды. «Казан, мин хәтерлим, мин горурланам!» – бөтен җәйге кампаниянең мотивы. Һәр смена Бөек Ватан сугышы геройлары хөрмәтенә аталды, аларның исемнәре тарихка мәңгегә язылды һәм шәһәр урамнары исемнәрендә мәңгеләштерелде. Сменалар вакытында лагерьларда Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм Махсус хәрби операциядә катнашучылар белән очрашулар узды.

Лагерьларда эшләү өчен әйдаманнарны әзерләү Татарстан Республикасы студентлар хезмәт отрядлары белән берлектә алып барыла. Әйдаманнар мәктәбен 150 дән артык кеше узды, әлеге проектны тәмамлаучылар Казан лагерьларындагы сменаларда уңышлы эшләде. 2024 елдан башлап яңа проект – Әйдаман ярдәмчеләре мәктәбе эшли башлады. 2025 елның җәендә 43 яшүсмер «Ял» үзәге лагерьларына эшкә урнаштырылды.

2025 елның 20-23 ноябрендә «Восток» балалар сәламәтләндерү лагере базасында әйдаманнарның «Планерка» III ачык Казан слеты узды. Слетта

барлыгы 150 кеше катнашты, алар арасында Татарстан Республикасы балалар ялы оешмаларыннан 13 команда, Россия Федерациясе субъектларыннан (Мәскәү, Ульяновск шәһәре, Иваново өлкәсе) 3 команда катнашты.

2025 елдан башлап балалар лагерьларында инвалид һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен махсус урыннар бүленеп бирелә башлады. 2025 елның җәендә лагерьларда 170 инвалид һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле бала ял итте.

Гадәттәгечә, катлаулы тормыш хәлендә, социаль яктан куркыныч хәлдә калган, балигъ булмаганнарның күзәтчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнарында һәм учреждениеләрендә исәптә торучы гаиләләрдәге балалар өчен сменалар үткәрелде. 2025 елда лагерьларда катлаулы тормыш хәлендә калган 860 бала ял итте.

«Нармонка» балалар сәламәтләндерү лагерен масштаблы реконструкцияләү эше башланды. 2024 елдан башлап реконструкциягә 600 млн сум бүлеп бирелде.

**Яшьләр социаль хезмәтләре системасы**

2025 елда 8 186 кеше шәхси-психологик ярдәм алды, 10 583 консультация үткәрелде. Кискен кризис хәлендәге 12 830 абонентка ышаныч телефоны аша ашыгыч психологик ярдәм күрсәтелде. Төркемле профилактик чараларда 14 530 кеше катнашты, шулардан бәйлелекне профилактикалау чараларында – 2 046 кеше, экстремизмны профилактикалау чараларында – 1 435 кеше.

2025 елда Казанның сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балалар тәрбияләүче яшь гаиләләренә комплекслы психологик, мәгълүмати һәм социаль ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «Мөмкинлекләр юлы» проекты гамәлгә ашырылды.

Проект Татарстан Республикасының 1 млн сум күләмендә грантлар бирү конкурсында җиңүче булды. Проект чараларында 73 гаилә катнашты. Проект кысаларында шәхси һәм төркемле консультацияләр, укыту мастер-класслары, терапевтик очрашулар, гаиләләрне берләштерүгә һәм аларның ресурсларын үстерүгә юнәлдерелгән ял һәм йомгаклау чаралары уздырылды.

2025 елда куркыныч яный торган затлар төркемендәге балалар – мәктәптә исәптә торучы, социаль яктан куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар эшләре буенча органнарда исәптә торучы балалар һәм яшүсмерләр өчен остазлык программасы гамәлгә ашырылды. Дәресләр программасы балигъ булмаганнарда тәнкыйди фикерләүне, конфликтларны конструктив чишү күнекмәләрен, үз-үзеңнең эмоциональ халәтеңне көйләүне һәм кыйммәт-мәгънә өлкәсен формалаштыруны үстерүгә юнәлдерелгән. Әлеге программаны 2025 елда 30 яшүсмер узды.

**А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге**

Үзәк базасында бию, театр, музыка, рәсем сәнгате, оригами юнәлешләре буенча 20 иҗат студиясе һәм берләшмәсе эшли. 2025 елда тәрбияләнүчеләрнең саны 1 300 кеше тәшкил итте.

2025 елда 508 чара үткәрелде, аларда 353 120 кеше катнашты. А.Гайдар исемендәге Казан яшьләр үзәге чараларының төп максатчан аудиториясе – һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары, Казан предприятиеләре һәм оешмаларының эшләүче яшьләре, шулай ук югары уку йортлары студентлары.

**Яшьләр иҗтимагый берләшмәләре белән хезмәттәшлек**

Бүгенге көндә Казанда 27 югары һәм 38 һөнәри белем бирү оешмасында барлыгы 165 836 студент белем ала. Чит шәһәрләрдән һәм чит илләрдән килгән студентлар өлеше 66,5 процентны тәшкил итә (чит шәһәрләрдән килүчеләр – 93 205, чит илләрдән килүчеләр – 17 074).

Казан шәһәрендә балалар һәм яшьләрне волонтерлыкка җәлеп итү өлкәсендә эшләүче 200 дән артык иҗтимагый берләшмә һәм оешма исәпләнә:

- студентлар хезмәт отрядларының Казан штабы: югары уку йортларында – 13 штаб, һөнәри белем бирү оешмаларында – 4 штаб (4 000 нән артык активист);

- Казан шәһәре Думасы каршындагы Яшьләр парламенты, ул 25 актив егетне һәм кызны берләштерә (4 утырыш уздырылды, яшьләрнең 15 инициативасы гамәлгә ашырылды);

- «Җиңү волонтерлары» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең Татарстан төбәк бүлегенең Казан бүлекчәсе: 36 мәктәп отряды, югары уку йортлары каршында 6 иҗтимагый үзәк һәм һөнәри белем бирү оешмалары каршында 6 үзәк (барлыгы 3 000 активист). Бүлек тарафыннан патриотик юнәлештә 250 чара оештырылды;

- студентлар эзтабарлар отрядларының Казан берләшмәсе: 26 эзтабарлар отряды, югары уку йортлары базасында 8 эзтабарлар отряды (барлыгы 650 дән артык эзтабар). 2025 елда Казан эзтабарлары Ленинград, Волгоград, Сахалин, Псков, Калуга, Новгород өлкәләре территорияләрендә, Кырым Республикасында үткәрелгән экспедицияләрдә катнашты, алар барышында 800 дән артык Кызыл Армия сугышчысы, командирлары һәм тыныч халыкның җәсәдләре табылды, 20 дән артык исем ачыкланды;

- Казан шәһәренең чит ил студентлары һәм аспирантлары ассоциациясе (300 дән артык чит ил активисты). 9 югары уку йорты базасында ассоциация ячейкалары төзелде;

- коткаручыларның Бөтенроссия студентлар корпусының Казан бүлекчәсе. Оешма 2021 елның ноябрендә төзелде, анда 89 активист эшли, шуларның 6 сы коткаручы һөнәри аттестатына ия;

- «Бердәм Россия Яшь гвардиясе» бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Казан бүлекчәсе. Бүлекчә тарафыннан ел саен патриотик юнәлештәге 300 дән артык чара оештырыла, аларда 10 мең активист катнаша.

2025 елда Казан шәһәрендә ирекleләр саны – 61 000 кеше. Казан шәһәре Башкарма комитеты каршындагы Казан шәһәренең ирекleләр үзәге мобилизацияләнгән гаиләләр һәм шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное

шәһәрләре халкы өчен гуманитар ярдәм җыюда булышлык күрсәтә. Гуманитар ярдәм җыю штабларында 1 000 нән артык ирекле (волонтер) эшли.

**Патриотик тәрбия**

Ел дәвамында яшьләр, балалар оешмалары һәм битараф булмаган казанлылар тарафыннан патриотик характердагы 1 500 дән артык шәһәр чарасы уздырылды, анда 200 меңнән артык кеше катнашты. Аларның иң масштаблылары, гадәттәгечә, ил тормышындагы истәлекле көннәргә һәм вакыйгаларга багышлана: 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү Көне, Ватан Геройлары көне, Хәтер һәм кайгы көне, Чернобыль АЭСындагы фаҗига еллыгы, совет гаскәрләрен Әфганстаннан чыгару көне, Хәрби-Диңгез Флоты көне, сәяси репрессия корбаннарын искә алу көне, шулай ук «Георгий тасмасы», «Ветеранны котла», «Үлемсез полк», «Блокада икмәге» һ.б. бөтенроссия акцияләре.

2025 елның 19 февралендә, Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 көн кала, Казанда 3 меңнән артык битараф булмаган ирекleләрне (волонтерларны) берләштергән Җиңүнең 80 еллыгы волонтерлар корпусы эшли башлады. Корпус волонтерлары ветераннар белән бергә вакыт уздырдылар, компьютер белеменә өйрәттеләр, социаль-көнкүреш ярдәме күрсәттеләр, шулай ук Ватанны саклаучылар елына багышланган барлык чараларда озатып йөрделәр.

2025 елда 2 акция: «Студентларның хәтер уты», шулай ук «Геройлар» видеороликлар сериясе эшли башлады. Казанның «Студентларның хәтер уты» акциясе шәһәрнең барлык югары уку йортларын һәм көллиятләрен берләштерде: ике ай дәвамында һәлак булган геройлар истәлеген гәүдәләндерүче студентлар уты бер уку йортыннан икенчесенә тапшырылды. «Геройлар» – төрле юнәлешләргә сизелерлек өлеш кертүче һәм яшьләрне эшкә һәм казанышларга рухландыручы кешеләрнең тарихларын популярлаштыруга юнәлдерелгән инициатива. 2025 елда Казан геройлары турында 20 дән артык видеоролик төшерелде.

**Чаралар**

2025 елда 200 дән артык чара: белем бирү сменалары һәм шәһәр күләмендәге бәйрәмнәр, иҗади конкурслар һәм фестивальләр, спартакиадалар, спорт ярышлары һәм интеллектуаль бәйгеләр үткәрелде. Алар арасында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә мөмкин:

- Казанның югары уку йортлары арасында «Беренче курс студенты көне» XXXII студентлар иҗаты фестивале;
- «Созвездие – Йолдызлык» яшьләр эстрада сәнгате фестивале;
- студентларның «Ягымлы яз» милли иҗат фестивале;
- һөнәри белем бирү оешмалары студентлары арасында «Язгы тамчы» республика фестивале;
- Казанның югары уку йортлары арасында «Студентлар язы» фестивале;
- гомуми белем бирү учреждениеләренең «Озын тәнәфес» Казан фестивале;

- шәһәркүләм соңгы мәктәп кыңгыравы;
- «Зур гаилә пикнигы» фестивале;
- «Студентлар марафоны» I Казан шәһәр яшьләр фестивале;
- Казан брейн-клубының Казан шәһәре Мэры кубогына интеллектуаль уеннары.

2025 елда БРИКС илләренең Яшьләр фестивале узды, анда 35 муниципалитеттан һәм 13 илдән 150 кеше катнашты.

**2026 елга планнар:**

- яшьләр сәясәте учреждениеләре инфраструктурасын алга таба да ныгыту һәм үстерү;
- җәмәгатьчелек игътибарын иреклелек (волонтерлык) идеяләренә ярдәм итүгә һәм гаилә кыйммәтләрен таратуга җәлеп итү;
- яшьләр арасында наркотиклар куллануны профилактикалау һәм тискәре (җәмгыять өчен куркыныч тудыра торган) күренешләрне киметү буенча актив эшчәнлек алып бару;
- яшьләрнең социаль һәм иҗади активлыгын арттыру, балаларда һәм яшьләрдә гражданлык һәм патриотик караш тәрбияләү;
- яшьләр белән эшләүдә яңа инновация формаларын эзләү.

## Халыкны социаль яклау һәм аңа ярдәм күрсәтү

Хәзерге вакытта Казан шәһәрендә ташламалардан файдалана торган гражданнар категорияләре буенча күрсәткечләр түбәндәгечә:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм аларга тиңләштерелгән затлар – 125;
- тыл хезмәтчәннәре – 1 521;
- инвалидлар – 88 420, шул исәптән инвалид балалар – 6 832;
- күп балалы гаиләләр – 16 007.

2025 елда социаль ярдәм чараларын түләүгә 3 820,79 млн сум юнәлдерелде, шулардан 1 110,47 млн сум – федераль бюджеттан, 2 710,32 млн сум – республика бюджетыннан.

**Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына әзерләнү һәм бәйрәм итү кысаларында түбәндәге чаралар уздырылды:**

- 136 мемориаль комплекс реставрацияләнде һәм ремонтланды;
- Бөек Ватан сугышы ветераннарына адреслы ярдәм күрсәтелде;
- өлкән кешеләргә өйдә хезмәт күрсәтелде;
- ялгыз яшәүче ветераннарга ярдәм кысаларында 18 фатирга агымдагы ремонт ясалды;
- «Ветеран йорты янында парад» бәйрәм чарасы, Арча һәм Архангельск зиратларында, шулай ук Җиңү паркында чәчәк кую тантанасы, Казан гарнизоны гаскәрләре йөреше узды.

**Өлкәннәр декадасы кысаларында түбәндәге чаралар** оештырылды:

- «Игелекле эшләр кылырга ашыгыгыз», «Фатирны тәртипкә китер», «Игелек һәм хөрмәт көне», «Ветеран янәшәдә яши» хәйрия акцияләре;
- өлкәннәр өчен «Игелекле очрашулар» һөнәрчелек ярминкәләре;
- «Тән һәм җан яшь булсын өчен» су спорты бәйрәме, рус бильярды буенча шәһәр турниры һәм «55 яшьтән узганнар өчен» футбол турниры;
- 10 меңнән артык кешене колачлаган мәдәни-ял итү чаралары.

**Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләргә социаль ярдәм күрсәтү.**

Казан шәһәре бюджетыннан ел саен инвалид балалар тәрбияләүче аерым категория гаиләләргә 10 мең сум күләмендә матди ярдәм бүлеп бирелә (2025 елда бер мәртәбә бирелә торган матди ярдәмне 341 гаилә алды).

Тулысынча дәүләт тәэминатында булган балалардан тыш, инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналарга (уллыкка яки кызлыкка бала алучыларга, опекуннарга һәм попечительләргә), шулай ук күп балалы гаиләләргә физик затлар милкенә салым ташламалары алу хокукы бирелә.

Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен башкала территориясендә уңайлы яшәү тирәлеге булдыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыру максатыннан Казан шәһәрендә 2016 елдан Инвалидлар эшләре буенча совет эшләп килә.

**2026 елга планнар:**

- Казан шәһәрендә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгына багышланган бәйрәм чараларын әзерләүдә һәм уздыруда катнашу, шул исәптән иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек өлешендә;
- өлкән яшьтәге гражданнар арасында актив тормыш рәвешен популярлаштыру максатыннан «Яшәү яме» шәһәр социаль проектын гамәлгә ашыруны дәвам итү;
- Инвалидлар декадасы кысаларында инвалид балалар тәрбияләүче гаиләләрнең аерым категрияләренә матди ярдәм күрсәтү.

## «Игелекле Казан» проекты

2025 елда «Игелекле Казан» шәһәрдә хәйриячелек культурасын формалаштыру эшен дәвам итте.

**Хәйрия фондлары**

Хәзерге вакытта «Игелекле Казан» бердәм тәрәзә функциясен үти һәм үз эченә 134 фондны һәм инициативаны берләштерә. Ел дәвамында шәһәрнең коммерцияле булмаган оешмалары тарафыннан ресурс, грант ярдәме, чаралар үткәрүдә ярдәм, муниципаль һәм коммуналь хезмәтләр белән мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм күрсәтелде.

**Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр һәм авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен проектлар өстендә эшләү** «Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы эшчәнлегенең өстенлекле юнәлеше булып кала бирә, 2025 елда анда барлыгы 4 570 тән артык кешегә хезмәт күрсәтелде.

2025 елда «Игелекле Казан» коммерцияле булмаган автоном оешмасы катнашында түбәндәге проектлар гамәлгә ашырылды:

- авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен кайнар линия (50 меңнән артык шалтыратулар кабул ителде);
- инвалид балалар арасында спортны үстерүгә юнәлдерелгән «Игелекле спорт» проекты. Ел дәвамында чаңгы, җиңел атлетика, йөзү, йөгерү, велосипедта йөрү буенча ярышлар уздырылды, хәйрия шугалаклары һәм башка чаралар оештырылды;
- «Социаль такси» проекты – аның кысаларында 1 200 кешегә ярдәм күрсәтелде, һәм «Игелекле автобус» проекты – 72 җиргә сәяхәт, шул исәптән Татарстан Республикасының һәм якын төбәкләрнең тарихи урыннарына сәяхәт кылынды;
- инвалидларны социальләштерү һәм эшкә урнаштыру (инвалидлыгы булган һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле 100 дән артык яшь кеше эшкә урнаштырылды, 37 кеше социальләшү уза);
- инвалидлык статусын алмаган, әмма тернәкләндерү чараларына ихтыяҗы булган кешеләргә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән «Сәламәтлек» проекты (483 кешегә ярдәм күрсәтелде);
- инклюзив волонтерларны укыту (бүгенге көндә «Игелекле Казан» волонтерлык хәрәкәтендә 800 дән артык кеше исәпләнә, аларның иң кечесенә – 7 яшь, ә өлкәненә – 87 яшь).
- менталь тайпылышлары булган балалар өчен көндезге лагерь сменалары (600 бала өчен 30 дан артык смена оештырылды);
- сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен «Облачко» футбол командасы (финанс һәм оештыру ярдәме);
- шәһәрнең инклюзив остаханәләре продукциясен сату буенча «Игелекле сувенир» сәүдә нокталары (сатылган продукциянең гомуми суммасы – 2 млн сумнан артык);
- Калинин урамы, 3 йорт адресы буенча ачылган складта әйберләр җыю, аларны мохтаҗларга тапшыру;
- Серов инклюзив бульварында ДЦП белән авыручылар өчен велосипед прокаты һ.б.

**Казан шәһәрендә инклюзия үсеше**

«Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы эгидасы астында шәһәр районнарында мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен инклюзив ял итү үзәкләре һәм менталь тайпылышлары булган балалар өчен укыту-тренировка фатирлары оештырыла. Бүген Казанда шундый 3

учреждение бар: «Луч» укыту-тренировка фатиры, «Тылсым» күпфункцияле үзәге, «Крылья» мультиформатлы үзәге.

«Вместе» балалар инклюзив үзәген ачу 2025 елның мөһим казанышы булды. Үзәк 2025 елның августында ачылды һәм хәзер анда 300 дән артык сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле һәм инвалид балалар, шулай ук нормотиплы балалар йөри.

Барлыгы ачык мәйданнарга ел саен 4 000 нән артык үзенчәлекле бала килә.

Шулай ук 2025 елда менталь сәламәтлекләре бозылган кешеләр өчен «БлагоДарю» автоном коммерцияле булмаган оешмасы социаль адаптация үзәгенең икенче фатиры ачылды. Анда өч егет кеше яши, аларның һәрберсенең үз бүлмәсе бар, алар уртак көнкүреш алып баралар, эшлиләр. Проектның төп бурычы – менталь үсеш үзенчәлекләре булган кешеләргә интернатлардан читтә тулы канлы тормыш белән яшәргә мөмкинлек бирү.

**Чаралар**

«Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы тарафыннан үткәрелгән төрле хәйрия чаралары (концертлар, конкурслар, спектакльләр һәм фильмнар күрсәтү) нәтиҗәләре буенча 2025 елда мохтаҗлар өчен 18 миллион сумнан артык акча җыелды. Шулай ук, Луганск һәм Донецк халык республикалары территорияләреннән мәҗбүри күченүчеләрне дә кертеп, хәрби хезмәткәрләрнең гаиләләре өчен даими рәвештә төрле акцияләр үткәрелә һәм хәйрия ярдәме җыела.

Язгы һәм көзге игелек ярминкәләре үткәрелә. Акция кысаларында 2025 елда 15 млн сумнан артык акча җыелды. Акчалар хәйрия фондларына ярдәм, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм буларак җибәрелде.

**«Игелекле Казан» коворкингы** базасында Казан шәһәренең коммерцияле булмаган оешмалары тарафыннан 2025 елда 1000 нән артык төрле чара: очрашулар, киңәшмәләр, укулар, мастер-класслар һәм консультацияләр үткәрелде. Шулай ук психологик һәм юридик ярдәм күрсәтелә: авыр тормыш хәлендә калган кешеләр өчен консультацияләр үткәрелә, колл-үзәк эшләп килә.

Коворкинг базасында шулай ук инвалидлыгы булган 6 кеше эшкә урнаштырылды һәм тагын 24 кеше социальләшү үтә.

«Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы җитәкчелегендә хәрби хезмәткәрләргә, аларның гаиләләренә һәм шефлыкка алынган (кушылган) территорияләр халкына гуманитар ярдәм күрсәтү эше оештырылды. Зур күләмле яки эре габаритлы ярдәмне кабул итә торган склад эшләвен дәвам итә, ә битараф булмаган кешеләр өчен җыю пунктлары ачылды.

Шулай итеп, шефлыкка алынган Лисичанск һәм Рубежное өчен гуманитар ярдәм җыюда шәһәрнең 300 дән артык предприятиесе һәм оешмасы, меңләгән Казан кешесе катнашты.

Горький Шоссесы урамы, 53а адресы буенча урнашкан склад йөкләрне җыю һәм комплектлау өчен бердәм нокта булып тора. Махсус хәрби операция башланганнан бирле әлеге зонага 86 фурада 1600 тоннадан артык йөк илтеп тапшырылды.

«Игелекле Казан» проекты грант һәм иганә акчалары ярдәмендә тормышка ашырыла. 2025 елда җәлеп ителгән грантлар суммасы 27 миллионнан артык сумны, хәер-иганә акчалары 50 миллионнан артык сумны тәшкил итте.

Коммерцияле булмаган оешмаларның социаль яктан әһәмиятле эшчәнлеген тану һәм аларга булышу, кешеләргә ярдәм итүгә һәм тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән социаль яктан әһәмиятле проектларны популярлаштыру максатыннан 2025 елда Казанда иҗтимагый юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар арасында Казан шәһәре Мэрының «Игелекле эшләр шәһәре» премиясенә дәгъва кылу өчен конкурс уздырылды. Премиядә 50 дән артык коммерцияле булмаган оешма катнашты, 10 оешма призер булды.

Шулай ук 2025 елда «Игелекле Казан» автоном коммерцияле булмаган оешмасы «Без бергә» халыкара премиясенең «Мәрхәмәт коды» номинациясендә җиңүче булды.

**2026 елда** «Игелекле Казан» коммерцияле булмаган автоном оешмасы барлык юнәлешләр һәм проектлар буенча эшен дәвам итәчәк.

## Хәрби хезмәткәрләргә һәм аларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү

2022 елның 1 октябреннән махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча шәһәр хезмәтләре һәм оешмаларының барлык эшчәнлеген координацияли торган шәһәр штабы эшли.

Махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр гаиләләре өчен шәһәр ташламаларыннан файдалану тәртибе эшләнде.

Хәрби хезмәткәрләрнең 8 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларына шәһәр пассажир транспортында бушлай йөрү өчен ташламалы юл йөрү билетлары (транспорт карталары) бирү дәвам итә. Барлыгы 2025 елның 31 декабренә 6 258 карта бирелде, алар буенча 1 989 097 тапкыр йөрелде.

Хәрби хезмәткәрләрнең балалары мәктәптә бушлай ике тапкыр туклану белән тәэмин ителгән. 2025 елның 31 декабренә 5 140 укучы бушлай туклану алды.

Шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең балалары балалар бакчаларында абонент түләвеннән һәм туклану өчен түләүдән азат ителде. Барлыгы 2 116 бала абонент түләвеннән азат ителде.

Моннан тыш, Казан шәһәренең дәүләт һәм муниципаль мәдәният учреждениеләре хәрби хезмәткәрләрнең 18 яшькә кадәрге балаларына, «Батыр» махсус пластик картасын күрсәтеп, чараларга бушлай йөрү мөмкинлеген бирә. 2025 елның 31 декабренә 8876 карта бирелде. Шәһәрнең 45 мәдәният учреждениесе 107 703 билет таратты инде.

Шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең балаларына 30 спорт учреждениесендә 40 тан артык төрдәге хезмәт күрсәтелә, шул исәптән алар билгеләнгән вакытта җиңел атлетика манежларына, бассейннарга, тренажер залларына һ.б. йөри ала.

«Яшүсмер» муниципаль бюджет учреждениесе махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларын түгәрәкләргә һәм секцияләргә өстәмә җыюлар оештырды. Бүгенге көндә «Батыр» картасы буенча 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге 100 бала шөгыльләнә. Шөгыльләнүчеләр арасында иң киң таралган юнәлешләр – хореография, карате, гамәли иҗат, рәсем сәнгате. 18 бала берьюлы берничә юнәлеш буенча дәресләргә йөри.

2025 елгы сәламәтләндерү кампаниясе вакытында мәктәп яны һәм шәһәр яны лагерьларында махсус хәрби операциядә катнашучыларның 2 326 баласы ял итте.

Мобилизация башланганнан бирле «Ышаныч» үзәгенә психологик ярдәм сорап 927 кеше мөрәҗәгать итте, шуларның 378 е кискен кризислы кәеф вакытында ашыгыч психологик ярдәм алды.

Вахитов районындагы «Ышаныч» үзәгенең бер психологик хезмәте базасында, М.Сәлимҗанов урамы, 14 йорт адресы буенча ярдәм төркеме форматында мобилизацияләнгән хәрбиләрнең хатыннарына һәм аналарына психологик ярдәм күрсәтелә. Эшнең мондый формасы катнашучылар өчен үз фикерләрен һәм хисләрен әйтә ала, психологлардан һәм төркемдәге башка катнашучылардан ярдәм ала ала торган шартлар тудыруга юнәлдерелгән.

Казан шәһәрендә шулай ук 16 медик-психологик консультация кабинеты һәм 12 психотерапевт кабинеты эшләп килә.

«Игелекле Казан» кайнар линиясе – махсус хәрби операциядә катнашучыларның туганнарына, катлаулы тормыш хәлендә калган кешеләргә консультация һәм ярдәм күрсәтә торган гомумшәһәр телефоны үз эшен дәвам итә.

Кайнар элемтә телефонына 50 144 тапкыр шалтыратулар булды. Кайнар элемтәгә килгән сораулар буенча түбәндәге ярдәм күрсәтелде:

- 2 751 гаиләгә 3 306 702 сумлык азык-төлек һәм көнкүреш химиясе җыелмалары бирелде;
- 376 гаиләгә коммуналь хезмәтләргә түләүләр һәм торак арендасы, ремонт, көнкүреш техникасы сатып алу һ.б. өчен 6 963 128 сумлык ярдәм күрсәтелде;
- 803 гаиләгә памперслар һәм балалар ризыгы сатып алуда 4 239 840 сумлык ярдәм күрсәтелде;

- 484 гаиләгә дарулар алу һәм медицина хезмәтләре күрсәтү өчен 2 589 400 сумлык ярдәм күрсәтелде;

- гаилә әгъзасы «хәбәрсез югалган» статусында булган 77 гаиләгә 1 925 000 сумлык матди компенсация бирелде.

Шулай ук гаиләләргә волонтерлар тарафыннан даими рәвештә ярдәм күрсәтелә (азык-төлек, дарулар сатып алу, утын бушату, йорт янын тәртипкә китерү, үлән чабу, кар көрәү, техниканы төзәтү, вак ремонт һ.б.).

Хәрби хезмәткәрләрнең барлык гаиләләре Казан шәһәренең медицина хезмәте тарафыннан актив патронажга алына һәм бу гаиләләрнең әгъзаларын медицина хезмәте белән тәэмин итү турындагы мәсьәләләр өстенлекле тәртиптә хәл ителә.

2025 ел башыннан Гуманитар ярдәм күрсәтү буенча координация советы эшли башлады.

**2026 елга планнар:**

- хәрби хезмәткәрләрне һәм аларның гаиләләрен яклау, гуманитар ярдәм күрсәтү эшен дәвам итү.

## Иҗтимагый-сәяси һәм дини оешмалар белән хезмәттәшлек

Шәһәрдә конфессияара татулыкны һәм иҗтимагый-сәяси тотрыклылыкны саклау Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегенең мөһим юнәлешләреннән берсе булып тора.

**Дини оешмалар белән эшләү**

Бүген Казанда 156 гыйбадәт объекты: 81 мәчет, 51 православие чиркәве, 6 иске йолачылар гыйбадәт объекты, башка христиан юнәлеше буенча 15 чиркәү, 1 синагога, Бахаи һәм Кришна гыйбадәт йортлары бар.

Татарстан башкаласында барлыгы 203 дини оешма: 101 – ислам, 57 – православие, 4 – иске йолачылар, 1 – католиклар, 1 – әрмән апостоллыгы, 33 – протестантлар, 1 – мормоннар, 2 – яһүдләр, 1 – бахаилар, 1 – кришнаитлар һәм 1 буддистлар дини оешмасы эшли.

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты ярдәме белән түбәндәге бәйрәмнәр һәм чаралар үткәрелде:

- 7 гыйнвар – Раштуа;
- 19 гыйнвар – Хач ману;
- 19 март – 13 нче республика ифтары;
- 30 март – Ураза гаете;
- 20 апрель – Пасха;
- 6 июнь – Корбан гаете;
- 20-22 июль көннәрендә Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы Кирилл Татарстан митрополиясенә беренче тапкыр изге визитын ясады. Үзенең визиты

кысаларында Мәскәү һәм бөтен Русь Патриархы Кирилл Казанда Татарстан Республикасы Рәисе Р.Н.Миңнеханов йөкләмәсе буенча 2024 елдан бирле реставрацияләнә торган Кеше кулы белән иҗат ителмәгән Коткаручы Образы хөрмәтенә төзелгән храм-һәйкәлне изгеләндерү чинын башкарды;

- 21 июль – Казан Изге Ана иконасы табылган көндә традицион Хач йөреше;
- 27 сентябрь – «Сурб Григор Лусаворич» Әрмән Апостол чиркәвен төзүне изгеләндерүгә багышланган тантаналы чара;
- 22-25 октябрь – «Россиядә мөселманча укыту традицияләре һәм инновацияләре» мөселман мәгариф оешмалары укытучылары форумы;
- 4 ноябрь – Казан Изге Ана иконасын данлау хөрмәтенә традицион хач йөреше;
- 5 ноябрь – «Мәгърифәт һәм әхлак: шәхес формалаштыру һәм заман чакырулары» темасына ел саен үткәрелә торган Раштуа укулары;
- 12-13 ноябрь – ислам дисциплиналары һәм гарәп теле буенча халыкара олимпиада.

**Иҗтимагый-сәяси характердагы ачык чаралар**

Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан иҗтимагый-сәяси оешмалар һәм берләшмәләр белән хезмәттәшлек итү буенча шәһәр территориясендәге иҗтимагый-сәяси вәзгыятьне анализлауга һәм мониторинглауга юнәлдерелгән эш алып барыла.

2025 ел ахырына Татарстан Республикасында (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында теркәлгән 21 сәяси партиянең) 16 сәяси партиянең төбәк бүлекчәләре теркәлгән.

2025 елда Казанда 995 төрле ачык чара узды, аларда 18,3 мең кеше катнашты: сәяси таләпләр белән 65 чара, социаль мәсьәләләр буенча 11, 916 – агитация (ике сайлау кампаниясе – Татарстан Республикасы Рәисен һәм бишенче чакырылыш Казан шәһәре Думасы депутатларын сайлаулар кысаларында), гыйбадәт объектларыннан тыш узган 3 дини чара. Чараларда күтәрелә торган төп темалар – экологик проблемалар, йортсыз хайваннар мәсьәләләре, шәхси торак йортлар төзегәндә зыян күргән гражданнар, Россия Федерациясе Президентының ярдәме.

**2026 елга планнар:**

- Казанда конфессияара татулыкны саклап калу өчен уңай атмосфера булдыру;
- тотрыклы иҗтимагый-сәяси вәзгыятьне саклап калу;
- дини оешмаларга Казан шәһәрендә конфессияара килешүгә һәм татулыкка ирешергә ярдәм итүче социаль әһәмияткә ия программаларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү.

## Милли-мәдәни оешмалар белән хезмәттәшлек

Соңгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматларына караганда, башкалада 115 милләт вәкиле яши, 43 милли-мәдәни берләшмә эшли.

Казан шәһәре Башкарма комитеты Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе, Татарстан Халыклары ассамблеясе, Татарстан халыкларының Яшьләр Ассамблеясе, Татарстан Республикасының чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү үзәге кебек иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итә. Шәһәрдә балаларны туган телдә укыту һәм тәрбияләү өчен шартлар тудырылган. Гражданнарның өстәмә белем бирү системасы аша үз туган телен, тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүгә хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан күптәннән яшәүче яки шәһәргә яңа килгән төрле халыкларның балалары өчен төркемнәр бар. Россиядә бердәнбер «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге уңышлы эшләп килә, аның 25 бүлеге бар, анда 500 дән артык бала белем ала.

2024-2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаны үтәүгә, шулай ук милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгытуга, татар телен популярлаштыруга юнәлдерелгән яңа масштаблы чараларны һәм проектларны гамәлгә ашыруга, шул исәптән түбәндәге чараларга 2025 елда 26 451 000 сум күләмендә акча каралды:

- татар телен өйрәнү һәм татар мәдәниятен үстерү буенча «Үз телем» проектлар конкурсы;
- «Саумы, Казан!» / «Здравствуй, Казань!» шигырь конкурсы;
- Кабан күле яр буенда татар биюе буенча «Хәрәкәттә – бәрәкәт» мастер-класслары;
- «Апуш» балалар татар театр студиясенең матди-техник базасын ныгыту;
- «Кузьминки» бөтенроссия фольклор-этнография фестивале;
- «Алма спасы» бәйрәм программасы;
- ачык һавада үткәрелә торган «Голоса Казани – Казан тавышлары» музыкаль-театральләштерелгән тамашасы;
- Идел буе халыкларының «Итил» яңа этник мәдәни фестивале;
- өлкән сыйныф укучылары өчен «Татар кызы», «Татар егете», «Добрый молодец», «Красна девица» шәһәр конкурслары;
- «Духов день в Суконной слободе» («Сукно бистәсендә көн рухы») фестивале;
- мәктәп укучылары өчен Дуслык һәм татулык дәресләре үткәрү.

Шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәмендә түбәндәге проектлар гамәлгә ашырылды:

- Туган тел көнендә (26.04.2025) төрле милләттән булган 400 бала катнашында җыелма хор чыгышы;

- ике әзерлек дәрәҗәсе булган татар теле курслары (4 курс);

- «Алмаш» гаилә бәйрәме;

- Татарстан халыклары ассамблеясе белән берлектә гамәлгә ашырылган «Тормыш агачы» агарту проекты кысаларында «Рекрут йолалары һәм Идел буе халыклары традицияләре» һәм «Йолалы ата-баба йорты» тематик чаралары;

- Туфан Миңнуллин исемендәге «Күзлек» балалар театр лабораториясе;

- «Апуш. Нәниләр» мәктәп-студиясенең «Тыз-быз» спектакле;

- С.Сәетгалиев исемендәге мәдәният йортында «Апуш» балалар татар театр студиясенең спектаклен кую.

- Казан шәһәренең гомуми белем бирү һәм өстәмә белем бирү оешмаларындагы ир-ат укытучылар өчен «Тел сагында – ир-егетләр» конкурсы;

- Аяз Гыйләҗев исемендәге ачык шәһәр фестиваль-конкурсы;

- «Әйдә, шаярт!» Казан лигасы уеннары;

- «Калеб» иҗади берләшмәсенең әдәби-музыкаль кичәләре;

- «Кайтаваз. Хәйдәр Бигичев» концерты;

- «Гәүһәр» балалар фестивале һәм Казан шәһәре мәгариф учреждениеләрендә һәм балалар бакчаларында хореография, вокал, ораторлык сәнгате һәм музыка коралларында уйнау дәресләре;

- татар милли мәдәниятенең «Ягымлы яз» яшьләр фестивале;

- «Милли кием» милли киемнәр фестивале;

- «Җәйге бистә» проекты;

- татар поэмаларын сәхнәләштерү буенча «Җан авазы» конкурсы.

Милләтара һәм конфессияара конфликтларны кисәтү мәсьәләләре Татарстан халыклары Ассамблеясе белән берлектә Татарстан Республикасы территориясендә агымдагы миграция мәсьәләләре буенча фикер алышу буенча түгәрәк өстәлләрнең квартал утырышларында, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлегендә чит ил гражданнары тарафыннан хокук бозуларны профилактикалау буенча эшче төркемнең һәм хокук саклау органнары вәкилләре һәм Татарстан халыклары ассамблеясенең милли-мәдәни берләшмәләре җитәкчеләре катнашында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча координация советының ярты еллык утырышларында карала.

Отчет елында «Татарстан Республикасының чит ил гражданнарын социаль-мәдәни адаптацияләү үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешмасы белән хезмәттәшлек башланды. 2025 елның 26 ноябрендә Үзәк белән берлектә Татарстан Республикасында Кыргыз Республикасының Жогорку Кенеш депутатларын вакытыннан алда сайлау көне алдыннан Кыргыз Республикасы гражданнары белән адаптация очрашуы үткәрелде. Очрашуда катнашучыларга Россия законнарының төп моментлары, миграция исәбенә алу нигезләре һәм Россия Федерациясе территориясендә үз-үзеңне тоту нормалары аңлатылды.

**2026 елга планнар:**

- Казанда милләтара һәм конфессияара татулыкны саклап калу өчен уңай атмосфера тудыру;

- 2024 – 2030 елларга Казан шәһәрендә гражданлык килешүен ныгыту буенча муниципаль программаны үтәү;

- милли-мәдәни оешмаларга Казан шәһәрендә милләтара һәм конфессияара килешүгә һәм татулыкка ирешергә ярдәм итүче социаль әһәмияткә ия программаларны гамәлгә ашыруда булышлык күрсәтү.

## Хокук саклау эшчәнлеге

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тарафыннан гражданнарның конституцион хокукларын һәм ирекләрен, хокук тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга, җинаятьчелеккә каршы көрәштә булган көчләрне һәм чараларны файдалануның нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар комплексы тулы күләмдә үтәлде.

2025 елда Казан полициясе хезмәткәрләре тарафыннан катнашучыларның гомуми саны 7 миллионнан арткан шәһәр һәм республика дәрәҗәсендәге, федераль әһәмияттәге 2 051 мәдәни-тамаша һәм спорт чараларын уздырганда җәмәгать тәртибе тәэмин ителде. Җәмәгать тәртибен саклауга 27 меңнән артык полиция хезмәткәре чыкты. Җитди рәвештә хокук тәртибен бозуларга юл куелмады.

2025 ел нәтиҗәләре буенча 20 267 җинаять теркәлде, аларның саны, 2024 ел белән чагыштырганда, 19,1 процентка кимеде, шулай ук аеруча авыр һәм авыр җинаятьләр саны 6,1 процентка, ягъни 8 058 дән 7 563 очракка кадәр кимеде.




7 687 җинаять эше буенча тикшерү үткәрелде, аларны кылган 5 029 кеше җинаять җаваплылыгына тартылды.

2025 ел нәтиҗәләре буенча 46 үтерү һәм 81 сәламәтлеккә авыр зыян китерү очрагы теркәлде. Әлеге категориядәге җинаятьләрне ачу һәм тикшерү эшенең нәтиҗәлелеге 99,4% һәм 100,0% тәшкил итте.

Милек белән бәйле җинаятьләр саны 11,0 процентка кимеде. 2025 елда шундый 11 844 җинаять теркәлде, шуларның 3 236 сы тикшерелде, тикшерелгән җинаятьләрнең процент күрсәткече – 26,9%.

Узган елда талау нияте белән һөҗүм итүнең 28 очрагы, талау буенча 106 җинаять теркәлде. Талау нияте белән һөҗүм итүгә бәйле 38, талау очрагы белән бәйле 96 җинаять эше судка җибәрелде. Талау һөҗүмнәренең ачылу күрсәткече – 100,0%, талауларныкы – 97,0%.

Милеккә карата кылынган җинаятьләрнең күп өлешен, элеккечә, урлаулар тәшкил итә. Шул ук вакытта аларның саны, 2024 ел белән чагыштырганда,

4,8 процентка кимеде һәм 5 678 очракны тәшкил итте. 2 209 җинаять буенча җинаять эшләре судка җибәрелде.

Шәһәрдә теркәлгән фатир басулар саны 32 процентка, 31 дән 41 фактка кадәр артты. 22 җинаять буенча җинаять эшләре судка җибәрелде. Тикшерелгән җинаятьләр күрсәткече 68,8 процентны тәшкил итте.

Кибетләрдә һәм башка сәүдә нокталарында ачык шартларда башкарылган урлаулар саны 45,1 процентка – 1 859 дан 2 698 очракка кадәр артты. Мондый җинаятьләрнең күбесе Совет, Идел буе һәм Яңа Савин районнарында теркәлде, бу аларда эре сәүдә үзәкләре булуга бәйле.

Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре ярдәмендә кылынган җинаятьләр саны 27,0 процентка (15 514 тән 11 329 га кадәр) кимеде, шулай ук дистанцион рәвештә алдап урлашу очраклары 15,5 процентка (6 024 тән 5 123 кә кадәр) кимеде. Әлеге категориядәге теркәлгән урлашулар саны 30,8 процентка – 1 780 нән 1 231 гә кадәр кимеде.

Мәгълүмат-телекоммуникация технологияләре ярдәмендә кылынган, тикшерелгән җинаятьләр саны 3,7 процентка, ягъни 2 482 дән 2 389 очракка кадәр кимеде. 13 меңнән артык кеше алдап урлашучылар корбаны булды.

Дистанцион ысул белән кылынган җинаятьләрне профилактикалау максатыннан Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тарафыннан әлеге төр җинаятьләрне профилактикалау буенча мәгълүмат ведомство сайтының яңалыклар лентасында даими урнаштырыла. Торак секторларда полициянең участок вәкилләре халык белән профилактик әңгәмәләр үткәрә, алдауның мөмкин булган схемалары турында брошюралар тарата, җинаятьчеләр корбаны булудан ничек сакланырга кирәклеген аңлата. Метрополитен станцияләрендәге интерактив җайланмалар экраннарында алдап урлау юлы белән кылына торган җинаятьләрне профилактикалау буенча видеороликлар трансляцияләнә, халыкка чит кешеләрдән кергән теләсә нинди мәгълүматка игътибарлы һәм уяу булырга кирәклеге турында тавыш ярдәмендә мәгълүмат җиткерү оештырыла.

2025 елда авто-, мототранспорт урлауның 54 очрагы теркәлде. Әлеге категориядәге 64 җинаять буенча җинаять эшләре судка җибәрелде. Әлеге төр җинаятьләрне ачу күрсәткече 93,1% тәшкил итте.

Шәһәр буенча икътисад өлкәсендә 1 208 җинаять ачыкланды, шуларның 419 ы – коррупция юнәлешендә, шул исәптән 382 се – ришвәт алу/бирү, 8 е коммерцияле сатып алу белән бәйле. Бюджет акчаларын саклау өлкәсендә 75 җинаять ачыкланды. Икътисади җинаятьләрдән гомуми зыян 12,4 млрд сумнан артып китте. 15 млрд сумга якын акча кире кайтарылды.

2025 елда законсыз уен йортлары эшчәнлеге ачыкланмады.

2025 ел нәтиҗәләреннән күренгәнчә, наркотикларның законсыз әйләнеше белән бәйле 1 733 җинаять буенча эш тәгәлләнде. 770 кеше – җинаять җаваплылыгына, тагын 2 699 кеше административ җаваплылыкка тартылды. 47 килограммнан артык наркотик матдә һәм көчле тәэсир итүче матдәләр

законсыз әйләнештән алынды, аларның күпчелеген синтетик наркотиклар тәшкил итте. Казан шәһәре территориясендә наркотик һәм психотроп матдәләр белән тәэмин итүче 4 канал ябылды.

Экстремизмга һәм терроризмга каршы тору, әлеге категориядәге җинаятьләрне вакытында кисәтү, ачыклау һәм булдырмый калу, экстремистик һәм террористик оешмаларны финанслау каналларын ябу эшен нәтиҗәле оештыру – Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең төп бурычларыннан берсе. Әлеге юнәлеш буенча эш кызыксынган ведомстволар белән тыгыз хезмәттәшлектә алып барыла.

2025 ел нәтиҗәләре буенча экстремизм һәм террорчылык юнәлешендәге 40 җинаять буенча 20 җинаять эше кузгатылды. Әлеге категориягә караган 24 җинаять буенча 9 җинаять эше судка җибәрелде.

Нацистлар атрибутикасын яки символларын пропагандалау һәм ачык демонстрацияләү яисә экстремистик оешмалар атрибутикасын яки символларын ачык демонстрацияләүнең 36 очрагы ачыкланды, гаеплеләр административ җаваплылыкка тартылды.

Хәзерге вакытта Казанда милләтара һәм динара мөнәсәбәтләр тотрыклы, җәнҗаллы хәлләр теркәлмәде.

2025 ел нәтиҗәләре буенча Казанга килүче чит ил кешеләренең саны артты.

Миграция законнарын һәм чит ил гражданнарының Россия Федерациясе территориясендә законлы нигездә тору тәртибен бозу очракларын ачыклау һәм кисәтү максатыннан алар күпләп яши һәм хезмәт эшчәнлеген алып бара торган урыннар даими рәвештә тикшерелә.

Хисап чорында миграция законнары өлкәсендә 13 294 хокук бозу ачыкланды. 2025 ел нәтиҗәләре буенча чит ил гражданнарын Россия Федерациясеннән чыгару турында 1 133 карар кабул ителде.

Законсыз миграция һәм ялган исәпкә куюны оештырган затларны җинаять җаваплылыгына тарту эше башкарылды: 371 очрак ачыкланды, 372 очрак тикшерелде.

Чит ил гражданнары тарафыннан кылынган җинаятьләр дәрәҗәсе 4,2 процентны тәшкил итте. Барлыгы 505 җинаять кылынды, аларның күпчелеге наркотиклар белән бәйле җинаятьләр (244 очрак) һәм милеккә каршы җинаятьләр (136 очрак). 264 чит ил кешесе җинаять җаваплылыгына тартылды.

Оешкан җинаятьчел төркемнәрне таркату буенча максатчан эш дәвам иттерелде. Хисап елында полиция хезмәткәрләре тарафыннан төркемнәр составында кылынган 1 439 җинаять ачылды, шул исәптән 181 җинаять – оешкан төркемнәр һәм җинаятьчел төркемнәр составында.

Полиция хезмәткәрләре тарафыннан шәһәр территориясендә корал, сугыш кирәк-яраклары һәм шартлаткыч матдәләрнең законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне кисәтүгә, ачыклауга һәм ачуга юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрелде, нәтиҗәдә законсыз әйләнештән 25 берәмлек утлы корал,

2 567 патрон, 3 622 г дары алынды. Законсыз корал әйләнеше белән бәйле 73 җинаять ачылды.

Полиция эшчәнлегендә видеокүзәтү чаралары, көчләр һәм чаралар белән идарә итү буенча техник чаралар актив кулланыла. Тулаем шәһәр буенча 52 меңнән артык видеокүзәтү камерасы урнаштырылган, шул исәптән күпфатирлы йортларда – 20 048, Ір-домофоннарда – 7 120, җәмәгать урыннарында һәм шәһәр урамнарында – 5 058. Башкаланың 47 паркында һәм скверында шулай ук видеокүзәтү алып барыла.

Видеокүзәтү системалары ярдәмендә 909 җинаять ачылды. 940 административ хокук бозу ачыкланды.

Үткәрелгән чаралар җәмәгать урыннарында һәм шәһәр урамнарында кылынган җинаятьләр санының кимүенә китерде.

2025 елда Казан шәһәренең җәмәгать урыннарында 4 566 җинаять кылынды, җинаятьләрнең гомуми санында әлеге категория җинаятьләрнең чагыштырма зурлыгы – 22,5%, бу, 2024 ел белән чагыштырганда, 5,3 процентка артыграк (17,2%).

2025 елда яшүсмерләр тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 21,4 процентка, 401 дән 315 фактка кадәр кимеде. Яшүсмерләр җинаятьчелеге дәрәҗәсе кимеде һәм 4,1% тәшкил итте. Ел йомгаклары буенча 221 яшүсмер җинаять җаваплылыгына тартылды, шуларның 152 се – шәһәрнең гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары.




Рецидив җинаятьчелекне профилактикалауга зур игътибар бирелә.

Элек хөкем ителгән затлар тарафыннан кылынган җинаятьләр саны 2025 елда 3,8 процентка (2 610 нан 2 510 очракка кадәр) кимеде. Гомуми күрсәткечтә рецидив җинаятьчелек өлеше 1,3 процентка (34,0 проценттан 32,7 процентка кадәр) төште.

Әлеге категориягә караган гражданнарның эшкә урнашмаган булуы – алар тарафыннан кылынган күпсанлы җинаятьләрнең төп сәбәпләреннән берсе. Әйтик, элек хөкем ителгәннәрнең 80,4 проценты, яки 1 574 кешенең 1 266 сы рәсми рәвештә эшкә урнашмаган, ягъни аларның даими кереме юк.

Хисап чорында исерек хәлдә кылынган җинаятьләр саны 18,6 процентка, 1 327 дән 1 080 очракка кадәр кимеде. Исерек хәлдә кылынган җинаятьләр дәрәҗәсе 14,0 процентны тәшкил итте.

Алкоголь продукциясе әйләнеше өлкәсендәге законнарны үтәү максатыннан полиция хезмәткәрләре узган елда төрле объектларда 30 меңгә

якын тикшерү уздырды, шул исәптән 830 сәүдә объекты тикшерелде, аның нәтиҗәләре буенча 80 административ беркетмә төзелде. Алкоголь продукциясенең законсыз әйләнеше фактлары ачыкланмады, якынча 799 л алкоголь һәм спиртлы продукция сатудан алынды.

Исерек хәлдәге затларга беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү, әлеге затлар тарафыннан, шулай ук аларга карата җинаятьләр кылуны минимальләштерү максатыннан 2025 елда Голубятников урамы, 3 йорт адресы буенча урнашкан «“Яңарыш” ярдәм үзәге» муниципаль автоном учреждениесе (медицина айныткычы) мөмкинлекләре актив кулланылды.

2025 елда үзәккә барлыгы 2 577 кеше: ашыгыч медицина ярдәме станциясе хезмәткәрләре тарафыннан – 1 698 кеше, полиция һәм башка хезмәтләр хезмәткәрләре тарафыннан – 867 кеше китерелде. Учреждение эшчәнлеге исерек хәлдә кылынган җинаятьләр санының кимүенә ярдәм итә. 2025 елда мондый җинаятьләр 18,6 процентка, ә исерек автомобиль йөртүчеләр катнашындагы аварияләр саны 9,5 процентка кимеде.

Юл хәрәкәте иминлеген оештыру шәһәрлеләр тормышына тәэсир итүче мөһим фактор булып тора.

2025 ел нәтиҗәләре буенча юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозуның 200 меңнән артык очрагы ачыкланды, шул исәптән автомобиль транспорты йөртүчеләргә карата 172 468 беркетмә төзелде, шуларның 2 750 се – транспорт чарасы белән исерек хәлдә идарә иткән өчен. Җәяүлеләргә карата 24 850 административ беркетмә төзелде.

Транспорт чарасы белән кабат исерек хәлдә идарә иткән өчен 161 кеше тоткарланды, административ җәзага тартылган зат тарафыннан юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен 163 очрак буенча җинаять эшләре кузгатылды (РФ Җинаять кодексының 264.1 статьясы).

Дәүләт автоинспекциясе полиция бүлекләре белән берлектә транспорт чарасын идарә итү хокукыннан мәхрүм ителгән һәм машина йөртү таныклыгын тапшырмаган гражданнар белән адреслы эш алып бара. Бер ел эчендә әлеге категория гражданнардан 2 661 машина йөртү таныклыгы алынды.

Юл-транспорт һәлакәтләре саны 5,0 процентка (1 279 дан 1 215 кә кадәр) кимеде. Төрле дәрәҗәдәге тән җәрәхәтләре алучылар саны шулай ук кимеде (1 517 дән 1 450 гә кадәр). Һәлак булучылар – 32 кеше.



Полициягә җәмәгать тәртибен саклау эшендә Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты актив булышлык күрсәтә. Аларның ярдәме белән шәһәр территориясендә полициянең участок хезмәткәрләре өчен алты административ-торак комплекс эшләп килә, 88 тәртип саклау җәмәгать пункты эшли.

Бүгенге көндә 35 тәртип саклау җәмәгать пунктында ремонт таләп ителә.

Хокук тәртибен тәэмин итүдә полиция хезмәткәрләре белән бергә муниципаль хезмәткәрләр дә катнаша.

Казан шәһәре Башкарма комитетында җәмәгать тәртибен саклау буенча 87 эйдәп баручы белгеч, шул исәптән Россия Федерациясе Эчке Эшләр Министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең миграция мәсьәләләре бүлеге белән бергә эшләүче 14 белгеч вазифасы бар. Муниципаль хезмәткәрләр җәмәгать тәртибен саклауга патруль экипажлары, җәяүле постлар составында һәм полициянең стационар постларында җәлеп ителә. Муниципаль хезмәткәрләр катнашында 1 221 җинаять ачылды, 7 меңнән артык административ хокук бозу ачыкланды һәм булдырылмый калды, 65 787 гражданин, шул исәптән 7 мең якын һәм ерак чит ил кешеләре, 7 832 автомашина, 44 317 номерлы әйбер тикшерелде.

Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүдә 38 муниципаль хезмәткәр катнашты. 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр юл-патруль хезмәте нарядларына 2 123 юл-транспорт һәлакәтен рәсмиләштерүдә, техник чаралар кулланып, юл йөрү кагыйдәләрен бозуның 10 857 очрагын теркәүдә ярдәм күрсәтте. Алар шулай ук юл хәрәкәте иминлеген пропагандалау буенча 370 чарада катнашты.

Җәмәгать тәртибен саклауга һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүгә гражданнарны җәлеп итү эшен оештыру зур әһәмияткә ия.

Казан шәһәре территориясендә 1 550 кешедән торган 255 халык дружинасы булдырылды. 2025 ел нәтиҗәләре буенча халык дружинниклары 10 массакүләм чара үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауда катнашты.

Гадәттәгечә, террорчылык акты куркынычы янарга мөмкин булган потенциаль объектларның террорчылыктан сакланганлыгын тәэмин итү мәсьәләләренә аерым игътибар бирелә.

Хисап чорында Казанда террорчылыкка каршы комиссиянең массакүләм чаралар үткәрү вакытында иминлекне тәэмин итү, объектларны террорчылыктан саклау, экстремизмны профилактикалау, җаваплы затларның һөнәри осталык дәрәҗәсен күтәрү мәсьәләләре буенча 10 утырышы уздырылды.

2025 елда Казанның 29 мәктәбендә «цифрлы гигиена» дигән лекцияләр циклы уздырылды, аларда цифрлы куркынычсызлык, мошенниклык һәм кибербуллинг мәсьәләләре турында фикер алыштылар. Педагогик коллективлар арасында балигъ булмаганнарны деструктив берләшмәләргә җәлеп итүне профилактикалау буенча семинарлар уздырылды.

«Кибердружина» эш төркеме үз эшен дәвам итә, анның максаты – социаль челтәрләрдә деструктив төркемнәр һәм басмалар булу-булмауны күзәтү. 2025 ел эчендә «Кибердружина» «ВКонтакте» социаль челтәрендәге 110 деструктив берләшмә турында мәгълүматны ачыклады һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенә тапшырды. 73 веб-сылтама буенча шикаятьләр һәм Роскомнадзорга алга таба блоклау өчен үтенечләр җибәрелде.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе җинаятьләрне профилактикалау һәм кисәтү мәсьәләләрендә массакүләм мәгълүмат чаралары мөмкинлекләреннән актив файдалана. 2025 елда 2 181 чыганакта кисәтү һәм аңлату характерындагы 588 материал әзерләнде һәм бастырылды. Телевидениедә – 311 сюжет, басма чыганакларда – 8 мәкалә чыкты, радиода 21 тапкыр чыгыш ясалды.

Социаль киеренкелек югары булуга карамастан, шәһәрдә оператив хәл тотрыклы һәм ул контрольдә тотыла.

Хезмәт күрсәтелә торган территориядәге оператив хәлнең торышыннан чыгып, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе **2026 елга түбәндәге төп юнәлешләрне билгеләде**:

- җәмгыять белән партнерлык мөнәсәбәтләрен үстерү һәм ныгыту;
- җәмәгать урыннарында һәм шәһәр урамнарында, шул исәптән сәяси, спорт, мәдәни-массакүләм чаралар уздыру чорында хокук тәртибен һәм куркынычсызлыкны тәэмин итү;
- гадәттән тыш шартларга (гадәттән тыш хәлләргә) җавап бирүне оештыруны камилләштерү;
- мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен кулланып һәм компьютер мәгълүматы өлкәсендә кылына торган җинаятьләргә каршы тору, алдап урлашуларны профилактикалау;
- милли һәм дини нигездә барлыкка килгән экстремистик күренешләргә, җәмгыятьтә социаль киеренкелек формалаштыру өчен миграция процессларын куллануга каршы тору;
- наркотикларның законсыз таралу, шулай ук махсус хәрби операция уздырыла торган районнардан корал, сугыш кирәк-яраклары, шартлаткыч матдәләр һәм шартлаткыч җайланмалар кертү каналларын ачыклау һәм ябу;

Коррупциягә каршы көрәш.

- Россия Федерациясен үстерү буенча илкүләм проектларны (программаларны) гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән дәүләт акчаларын урлау һәм максатчан файдаланмау белән бәйле җинаятьләрне, оборона-сәнәгать комплексындагы җинаятьләрне кисәтү һәм булдырмау;
- яшүсмерләр арасында җинаять кылуларны профилактикалау һәм балигъ булмаганнарны хокуксыз гамәлләрдән саклау;
- юл хәрәкәте иминлеген арттыру.

## Яшүсмерләр арасында караучысызлыкны һәм хокук бозуларны, наркоманияне профилактикалау

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан гамәлдәге законнар нигезендә балалар һәм яшьләр арасында караучысыз калуны һәм хокук бозуларны, наркомания һәм токсикоманияне профилактикалау, балигъ булмаганнарның һәм үз хокукларыннан файдалануга сәләтсез гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау буенча эш алып барылды.

Балигъ булмаганнар тарафыннан кылына торган хокук бозуларны профилактикалау һәм катлаулы тормыш хәлендә калган балаларга ярдәм күрсәтү – аерым игътибар таләп итә торган мәсьәләләр. Төп басым имин булмаган гаиләләрне ачыклауга һәм девиант тәртипле балалар белән эшләүгә ясала.

2025 елда полиция бүлекләренең балигъ булмаганнар белән эшләү бүлекчәләре хезмәткәрләре тарафыннан 1 165 яшүсмер һәм 1 061 имин булмаган гаилә ачыкланды һәм профилактик исәпкә куелды. 1 118 яшүсмер һәм 1 247 гаилә, шул исәптән төзәлү сәбәпле 850 яшүсмер һәм 1 051 гаилә исәптән төшерелде. Казан шәһәре буенча эчке эшләр органнарында барлыгы 765 балигъ булмаган бала һәм 1 039 имин булмаган гаилә профилактик исәптә тора.

Бала тәрбияләү буенча бурычларын үтәмәгән өчен 1 994 ата-ана (законлы вәкил) административ җаваплылыкка тартылды. 23 кеше ата-ана хокукыннан мәхрүм ителде.

2010 елның 4 октябрендәге 71 номерлы «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында»гы Татарстан Республикасы законын үтәү йөзеннән Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тарафыннан профилактиканың башка субъектлары белән берлектә 365 рейд үткәрелде. Алар барышында балаларның сәламәтлегенә һәм үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итү буенча таләпләрне үтәмәгән өчен 1 269 ата-ана, шулай ук аларны алмаштыручы затлар һәм 7 вазифаи зат административ җаваплылыкка тартылды.

Балигъ булмаган затны җинаять кылуга җәлеп итү факты буенча – 123, бала тәрбияләү буенча бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен 5 җинаять эше кузгатылды.

Закон җәмәгать тәрбиячеләре институтын булдыруны күздә тота, аның төп бурычы – социаль яктан куркыныч хәлдә яки катлаулы тормыш хәлендә калган яшүсмерләргә ярдәм итү, балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау һәм торгызу чараларын гамәлгә ашыруда катнашу, аерым профилактик эш уздыру, балигъ булмаганнарның караучысыз калуын һәм алар тарафыннан хокук бозуларны профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре белән хезмәттәшлек итү.

Җәмәгать тәрбиячеләрен беркетү бурычы Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясенә йөкләнгән. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе утырышларында балигъ булмаганнар арасында җинаятьчелекнең торышы һәм аны профилактикалау буенча үткәрелә торган эш белән бәйле мәсьәләләр карап тикшерелде.

Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсенең полиция бүлекләрендә профилактик исәптә торучы 765 балигъ булмаган баланың 226 сы аерым игътибар таләп итә, шуларның 104 е – җинаять җаваплылыгына тарту яшенә җиткәнче җәмгыять өчен куркыныч гамәлләр кылган.

Ел дәвамында аерым игътибар таләп итә торган мәсьәләләр өйрәнелде: наркомания, суицидлар, алкоголь белән агуланулар, социаль яктан куркыныч хәлдә калган гаиләләр белән эшләү, шулай ук, боларга бәйле рәвештә, балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары белән аерым профилактик эшне оештыру мәсьәләләре һәм башкалар.

2025 елда үсмерләр тарафыннан 6 суицид кылынды (2024 елда – 8).

2025 ел ахырына балигъ булмаганнарның алкоголь белән агулану очраклары саны – 39 расланган очрак (2024 елда – 28).

Хәвеф яный торган төркемдәге балигъ булмаганнарга ярдәм күрсәтү һәм җәмәгать тәрбиячеләре институтын үстерү максатыннан ел дәвамында 2009 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы «Балигъ булмаганнарның җәмәгать тәрбиячеләре турында»гы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру эше дәвам итте. Ел дәвамында хәвеф яный торган төркемдәге балигъ булмаганнар белән 1 018 җәмәгать тәрбиячесе эшләде.

Социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән индивидуаль эш оештыру мәсьәләсе Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе эшендә һаман да төп мәсьәләләрнең берсе булып кала бирә. Мондый гаиләләрне иртә ачыклау буенча актив эш алып барыла. 2025 ел дәвамында Казан шәһәрендә ведомствоара социаль патронатта 1 226 гаилә, 2 240 балигъ булмаган бала исәптә торды.

Казанда наркотиклар куллануга каршы көрәш һәм ведомствоара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген күтәрү буенча комплекслы эш алып барыла. Казан шәһәренең наркотикларга каршы көрәш комиссиясе эшне координацияли.

Комиссия эшендә Казан шәһәренең «“Ышаныч” балаларга һәм яшьләргә психологик-педагогик ярдәм күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет яшьләр сәясәте учреждениесе белгечләре, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры табиб-наркологлары катнаша.

Наркотикларга каршы көрәш комиссиясе утырышлары кварталга бер тапкыр уздырыла.

2025 елда әлеге утырышларда түбәндәге мәсьәләләр карап тикшерелде:

- Казан шәһәрендә наркотикларга бәйле вәзгыять һәм наркологик ярдәм оештыру, наркотик матдәләр белән үлемгә китергән агулануларны мониторинглау нәтиҗәләре;

- Казан шәһәрендә ата-аналар һәм балигъ булмаганнар наркотик һәм психоактив матдәләр куллану сәбәпле социаль яктан куркыныч хәлдә булган гаиләләр белән аерым профилактик эш үткәрү турында;

- «Мак-2025» ведомствоара оператив профилактик операция нәтиҗәләре турында;

- Казан шәһәре районнарында наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш, халык арасында наркотик куллануны профилактикалау эшенең торышы турында;

- белем бирү һәм һөнәр оешмаларында укучылар арасында наркоманияне профилактикалауга һәм наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы торуга юнәлдерелгән эшне оештыру турында;

- наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы тору һәм халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау эшенең торышы турында;

Үз хокукларыннан файдалануга сәләтсез гражданнарга, балигъ булмаган затларга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү регламентларын федераль законнардагы үзгәрешләр нигезендә актуальләштерү эше даими рәвештә алып барыла.

Хокукларыннан файдалануга сәләтсез һәм хокукларыннан файдалану сәләте чикләнгән гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча вәкаләтләрне үтәү йөзеннән белгечләр 2025 елда 124 җинаять эше (2024 елда – 202) буенча производствода катнашты, судларга 745 бәяләмә (2024 елда – 672) әзерләнде.

Барлыгы Казан шәһәрендә хокукларыннан файдалануга сәләтсез дип танылган 3 395 гражданин (2024 елда – 3 178) яши: шуларның 374 е – социаль яклау учреждениеләрендә, 156 сы – сәламәтлек саклау учреждениеләрендә, 2 927 се – опекуннар белән, 467 се – опекуннардан аерым.

**2026 елда** эш түбәндәге юнәлешләр буенча дәвам итәчәк:

- балалар һәм яшьләр арасында караучысыз калуны, хокук бозуларны, наркоманияне, токсикомания һәм алкоголизмны профилактикалау;

- балигъ булмаганнарның һәм хокукларыннан файдалануга сәләтсез гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау;

- балигъ булмаганнарның үз-үзенә кул салуын профилактикалау;

- балигъ булмаганнарны җинаятьләр кылуга һәм җәмгыятькә каршы гамәлләр кылуга җәлеп итү очракларын ачыклау һәм кисәтү;

- катлаулы тормыш хәлендә калган балигъ булмаганнар һәм аларның ата-аналары белән аерым профилактик эш оештыру;

- катлаулы тормыш хәлендә калган яки җәмәгать тәртибен бозарга әзер балигъ булмаган балалар белән җәмәгать тәрбиячеләре эшен оештыру.

## Коррупциягә каршы сәясәт

Казан шәһәре Башкарма комитетында коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыру буенча планлы, системалы эш башкарыла.

Әлеге эш кысаларында коррупциягә каршы көрәшкә һәм коррупция куркынычларын киметүгә юнәлдерелгән алдынгы цифрлы механизмнар этаплап кертелә. 2025 елда түбәндәге автоматлаштырылган мәгълүмат системалары актив кулланылды һәм өзлексез яңартылды:

- кадрлар хезмәтләрендә коррупциягә каршы эшнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән «Мәнфәгатьләр каршылыгы контроле» системасы;

- юридик хезмәтләр эшенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән «Суд эшләрен һәм таләп-дәгъва эшләрен исәпкә алу» системасы;

- муниципаль контролерлар эшенең нәтиҗәлелеген һәм ачыклыгын арттыруга юнәлдерелгән «Административ хокук бозуларны исәпкә алу» системасы.

Тест режимында Казан шәһәренең җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы торуны цифрлаштыру процессы буенча яңа автоматлаштырылган мәгълүмат системасы кертелде. Программа керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрне анализлауны автоматлаштыруга, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгы өлешендә мөмкин булган куркынычларны ачыклауга юнәлдерелгән.

2025 ел дәвамында коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча 11 муниципаль хокукый акт эшләнде һәм кабул ителде.

Муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләре һәм җитәкчеләренең керемнәре һәм чыгымнары турында 1 600 дән артык белешмәгә анализ ясалды.

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль органының муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазифа биләүче затларның вазифаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе тарафыннан 2025 елда 17 беркетмә карары кабул ителде. Ел дәвамында 26 хезмәткәр коррупцион хокук бозулар кылган өчен дисциплинар җаваплылыкка тартылды.

Казан шәһәрендә коррупциягә каршы көрәш эшен координацияләү комиссиясе тарафыннан 4 утырыш үткәрелде, аларда 15 мәсьәлә карап тикшерелде, нәтиҗәдә, коррупциягә каршы көрәш өлкәсендә 22 тәкъдим һәм йөкләмә контрольгә куелды.

2025 елда Казан шәһәренең муниципаль хезмәткәрләре вазифаи бурычларын үтәгәндә барлыкка килә торган коррупция куркынычларын комплекслы бәяләү үткәрелде. Аның нәтиҗәләре буенча, гражданнар вазифага билгеләнгәндә һәм аны биләгәндә үзләренең керемнәре, милке һәм милек характерындагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм милек характерындагы

йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган вазифаларның гамәлдәге исемлеген актуальләштерү турында карар кабул ителде.

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарыннан эштән азат ителгән, яңа хезмәт килешүләре һәм (яисә) гражданлык-хокукый килешүләр төзегәндә, чикләүләрне үтәргә тиешле 145 элекке муниципаль хезмәткәр арасында эшкә урнашу буенча үткәрелгән контроль нәтиҗәләре нигезендә мөмкин булган мәнфәгатьләр каршылыгы очраклары ачыкланмады.

Казан шәһәренең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре һәм Казан шәһәренең муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре өчен коррупциягә каршы тематикага 22 дән артык укыту семинары һәм белем бирү лекциясе үткәрелде. Хезмәт урынында файдалану өчен 10 төрдән артык методик рекомендация, визуаль презентацияләр һәм белешмәлекләр әзерләнде.

Шәһәрдәге мәктәп укучылары арасында ел дәвамында коррупциягә каршы темага гомумшәһәр интеллектуаль уеннар сериясе үткәрелде. Алар белем бирү учреждениеләре һәм җәйге яшьләр лагерьлары базасында узды. Чараларда 35 тән артык мәктәп вәкилләре катнашты.

Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне (9 декабрь) алдыннан халыкның коррупция күренешләренә түземсезлеген формалаштыру максатыннан 7 шәһәр билборды һәм медиафасадында, шулай ук барлык үзгәрүчән мәгълүмат таблоларында коррупциягә каршы тематикага социаль реклама урнаштырылды. Балалар һәм яшьләр арасында коррупциягә каршы темага «Казань против коррупции! – Казан коррупциягә каршы!» дигән иҗади конкурслар үткәрелде. Конкурсларга барлыгы 300 дән артык эш – цифрлы плакатлар, видеороликлар һәм коррупциягә каршы проектлар тәкъдим ителде. Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга акчалата бүләкләр һәм кыйммәтле бүләкләр тапшырылды.

**2026 елга планнар:**

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарында коррупция күренешләрен кисәтүгә ярдәм итә торган чараларның нәтиҗәлелеген арттыру максатыннан 2026 елда «2019-2027 елларга Казан шәһәрендә коррупциягә каршы сәясәтне гамәлгә ашыру» муниципаль программасында каралган чараларны башкару дәвам итәчәк.

## Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү

2025 елда гражданнарны яклау өлкәсендә төп көч түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелде.

**Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын оештыру һәм аларда катнашу**

Муниципаль берәмлекнең мобилизацион әзерлеге торышы тикшерелде, киңәшмәләр үткәрелде, аларда актуаль мәсьәләләр каралды һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләренең эшчәнлеген җайга салу буенча өстәмә чаралар күрелде. Шулай ук, өлешчә мобилизацияне тәэмин итү барышында җирле үзидарә органнары вәкаләтләре кысаларында тиешле чаралар уздырылды. Казан шәһәренең икътисад объектларына беркетелгән җыелма эвакуация пунктлары исемлеге төгәлләштерелде, 27 сендә аларны гамәлдә эшләтеп карадылар.

Мобилизация биреме һәм гражданнар оборонасы буенча категориясе булган икътисад объектларының иң күп эшләүче сменасы яшеренер өчен гражданнар оборонасының 317 сак корылмасы (саклану урыны) санала. Хәзерге вакытта 95 сак корылмасын Казан шәһәре муниципаль милкенә тапшыру планлаштырыла. Аларны икътисад объектлары буларак куллануга әзерләү максатыннан 2025 елда 156 объектта гомуми суммасы 35 млн сумнан артыграк булган ремонт-торгызу эшләре башкарылды. Аларны федераль милектән муниципаль милеккә кабул итү өчен гражданнар оборонасының сак корылмаларын (алга таба – ГО сак корылмалары) дәүләт кадастр исәбенә кую эше алып барыла. 2025 елның 30 декабренә Росреестрда ГО сак корылмаларының 45 объектына документлар рәслауда тора.

Казан шәһәренең ГО сак корылмаларын иң яхшы хәлдә тоту буенча ел саен оештырыла торган смотр-конкурслар үткәрелде. Республика смотр-конкурсы нәтиҗәләре буенча саклану урыннары арасында сыйдырышлылыгы 150 гә кадәр булган убежищелар арасында 1 урынны «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте алды, ә 600 һәм аннан күбрәк кешегә исәпләнгән убежищелар арасында 1 урынны «КМПО» акционерлык җәмгыяте алды.

Гражданнар оборонасының сак корылмаларына, җир астында төзелгән корылмаларга һәм башка җир асты корылмаларына (торак йорт подваллары, җир асты кичүләре, метрополитен станцияләре) инвентаризация үткәрелде. 317 саклану урынында һәм күпфатирлы торак йортлардагы 6 мең подвалда, 35 паркинг һәм башка җир асты корылмаларында (балалар бакчаларындагы, мәктәпләрдәге, сәүдә үзәкләрендәге, дәвалау учреждениеләрендәге, икътисад объектларындагы һәм башка урыннардагы подваллар) инвентаризация үткәрелде. «Укрытие» төрендәге ГО сак корылмалары буларак җайлаштырылган күпфатирлы йорт подвалларының ишекләренә уклар (2 186 данә) һәм такталар (2 572 данә) урнаштырылды.

**Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын оештыру һәм аларда катнашу**

Халыкның һәм шәһәр территориясенең иминлеген тәэмин итү бурычларын хәл итүдә координацияләүче звено булып Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча шәһәр комиссиясе тора.

2025 елда әлеге комиссиянең 37 утырышы үткәрде, 28 боерык һәм 9 карар әзерләнде.

Казан шәһәренең «Буран», «Елга сулары ташу», «Туң салкын», «Казан шәһәре территориясендә табигый янгыннар чыккан чорда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү планы», «Казан шәһәренең су объектларында кешеләрнең һәлак булу ихтималын киметү планы» кебек оператив планнарына төзәтмәләр кертелде, «Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең мөмкин булган гадәттән тыш хәлләр шартларында халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итү чаралары планы» әзерләнде һәм расланды.

Ел дәвамында халыкны махсус чорда, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәл килеп чыкканда тиешле гамәлләргә өйрәтүгә зур игътибар бирелде. 2025 елда гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча виртуаль укыту-консультация пункты булдыру эше төгәлләнде. Әлеге проект KZN.RU мәгълүмат порталында урнаштырылды һәм Интернет челтәре ресурсларын актив кулланучы халыкның барлык категорияләре өчен дә куллану өчен ачылды. Шулай ук, ракета һәм пилотсыз очкыч һөҗүм итү куркынычы килеп чыккан очракта яшеренү урыннары турында халыкка мәгълүмат бирү максатыннан, сәхифәдә Казан шәһәренең җир асты корылмалары турында мәгълүматлар (адреслар) урнаштырылган. Моннан тыш, өйдә, урамда яки эштә булганда пилотсыз очкыч һөҗүме куркынычы барлыкка килгәндә гражданнар кылырга тиешле гамәлләр буенча 2 төр белешмәлек әзерләнде.

Халыкка гражданнар оборонасы сигналлары буенча эш итү тәртибе турында мәгълүмат бирү өчен 100 мең данә белешмәлек сатып алынды. Бүгенге көндә аларның 26 меңнән артык данәсе таратылды, шулардан: 10 мең данә – белем бирү учреждениеләренә, балалар бакчаларына; 2 600 данә – җир өсте җәмәгать транспортында һәм тукталыш платформаларында; 8 664 данә – күпфатирлы йорт подъездларында.

**Казан шәһәре территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итүне оештыру**

Статистика мәгълүматларына караганда, 2025 елда янгыннар саны, 2024 ел белән чагыштырганда, 10,3 процентка кимеде, шулай ук янгын вакытында зыян күрүчеләр саны 20,3 процентка кимеде. Шул ук вакытта янгыннарда һәлак булучылар саны 1,5 процентка артты.

**Казан шәһәре территориясендә янгыннар статистикасы**

| | Еллар буенча янгыннар саны | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | |
| | гадәттән тыш хәлләр | янгыннар | гадәттән тыш хәлләр | янгыннар | гадәттән тыш хәлләр | янгыннар | гадәттән тыш хәлләр | янгыннар | гадәттән тыш хәлләр | янгыннар |
| Барлыгы | - | 1293 | - | 1197 | - | 1063 | - | 1047 | - | 939 |
| Һәлак булучылар | - | 29 | - | 34 | - | 28 | - | 19 | - | 29 |
| Зыян күрүчеләр | - | 55 | - | 56 | - | 65 | - | 64 | - | 51 |

Янгын куркынычы дәрәҗәсен киметү максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан ел саен оештыру һәм гамәли чаралар комплексы уздырыла. Шулай итеп, 2025 елда, янгыннарда кешеләрнең үлемен кисәтү буенча нәтиҗәле чара буларак, 7 817 төтен чыгу турында автоном хәбәр итү җайланмалары һәм, янгын турында автоном хәбәр итү җайланмалары белән тәэмин итү рәвешендә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чара буларак, аерым категориядәге гражданнар, атап әйткәндә: күпбалалы гаиләләр, Бөек Ватан сугышы ветераннары, тыл хезмәтчәннәре, инвалид балалары булган гаиләләр, шулай ук 80 яшьтән өлкәнрәк ялгыз пенсионерлар яшәгән урыннарда урнаштыру өчен сөрем газы белән пычрануны билгели торган 200 сигнал бирү җайланмасы сатып алынды.

**Су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау чараларын тормышка ашыру**

2025 елның җәйге сезоны чорында пляжларда һәм су объектларында халыкның күпләп ял итү урыннарының куркынычсызлыгын тәэмин итү максатыннан түбәндәге чаралар комплексы башкарылды:

- су объектларында пляжларда һәм кешеләрнең ял итү урыннарында патрульләүне оештыруга, елга төпләрен водолазлар ярдәмендә чистартуга һәм суның сыйфатын анализлауга 12 700 300 сум акча бүлеп бирелде;
- шәһәрнең гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучылар белән янгын куркынычсызлыгы буенча, суда, юлларда, көнкүрештә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен үтәү буенча чаралар үткәрелде;
- су коену сезоны дәвамында ял итүче гражданнар белән әңгәмәләр үткәрелде, анда 2 739 кеше катнашты, суда куркынычсыз тәртип кагыйдәләре буенча 3 000 белешмәлек таратылды һәм батучыларны коткарганда ярдәм күрсәтү ысулларына өйрәтелде.

**Су коену сезонында суда бәхетсезлек очраклары статистикасы**

| Еллар | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
|---|---|---|---|---|---|
| Хәбәрләр | 59 | 29 | 39 | 42 | 37 |
| Батып үлүчеләр | 22 | 14 | 17 | 16 | 9 |
| Коткарылучылар | 25 | 15 | 22 | 30 | 45 |

**Казан шәһәрендә хәбәр итү һәм мәгълүмат бирү системасын оештыру**

Татарстан Республикасы Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының республика буенча хәбәр итүнең автоматлаштырылган төбәк системасын модернизацияләү проекты кысаларында Казан шәһәрендә хәбәр итү системасын үстерүгә юнәлдерелгән чаралар дәвам ителде. Хәбәр итү сигналларын һәм ашыгыч мәгълүмат тапшыру буенча 4 кәрәзле элемтә операторы һәм 4 радиотапшыру операторы белән үзара хезмәттәшлек турында килешүләр төзелде.

Халыкны пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме куркынычы турында өстәмә мәгълүмат белән тәэмин итү максатыннан Татарстан Республикасы Иминлек

Советы карары нигезендә Казан шәһәренең Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтендә халыкка ашыгыч мәгълүмат җиткерү һәм гражданнарга ышыклану урыннарына тоткарлыксыз керергә мөмкинлек бирә торган, ишекләрне дистанцион ачу мөмкинлеге булган автомат эш урыны җәелдерелде. 2025 ел ахырына халыкка электрон мәгълүмат бирү һәм бер үк вакытта подъезд ишекләрен автомат рәвештә ачу системасына 1 833 күпфатирлы торак йорт тоташтырылды.

**Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәте эше**

Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенең ашыгыч хәбәрләр кабул итә торган белгечләре тарафыннан Казан шәһәре халкыннан 294 380 хәбәр, шул исәптән торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча 289 521 хәбәр кабул ителде һәм эшкәртелде.

**2026 елга планнар:**

- укыту консультация пунктлары челтәрен үстерү, шул исәптән идарәче компанияләр базасында, һәм халыкны гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләр буенча укытуны дәвам итү;

- хәбәр итү системасын камилләштерү: «РСВО» универсаль аппарат-программа комплексын кулланып, хәбәр итүнең объектлы системасын камилләштерү буенча эшләр башкару;

- саклау корылмаларын нормативларга туры китерү, шулай ук пилотсыз очу аппаратлары һөҗүмнәре һәм ракета куркынычы очракларында халыкны яшерү өчен аларны әзерләү.

## «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексы. Мәгълүмат саклау

**Видеокүзәтү системасы**

Заманча шәһәр мохитенең мөһим өлеше – аның иминлеге, шунлыктан 2025 елда Казан шәһәренең җәмәгать киңлекләрен видеокүзәтү системалары белән тәэмин итү, парклардагы һәм скверлардагы видеокүзәтү системаларына техник хезмәт күрсәтү эше дәвам итте.

Хәзерге вакытта 49 парк һәм скверда, 1 тукталыш павильонында, 2 җир өсте һәм 4 җир асты җәяүлеләр кичүендә урнаштырылган 1 712 камера Казан шәһәре Башкарма комитеты балансында тора.

«Имин шәһәр» аппарат-программа комплексының хокук саклау сегменты кысаларында Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан 1 708 камерадан алына торган мәгълүматларны болытлы саклау, шулай ук видео агымнарын Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының ведомство программа тәэминатына тапшыру эше оештырылды.

10 шәһәр паркында һәм скверларында хәвеф сигнализациясе төймәләре аша Бердәм дежур-диспетчерлык хезмәтенә сигнал тапшыру каналларын оештыру эшләре тәмамланды.

Социаль инфраструктура объектлары 100% җиһазландырылды:

- керү мөмкинлеген контрольдә тоту һәм аның белән идарә итү системасы (СКУД) – 719 объект;
- видеокүзәтү системасы – 859 объект (16 841 камера).

**Куркынычсызлык системаларын тәэмин итү һәм үстерү**

2025 елда социаль объектларга куркынычсызлык системалары куелды, атап әйткәндә:

- автомат янгын сигнализациясе белән 6 гомуми белем бирү учреждениесе, 1 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 1 өстәмә белем бирү учреждениесе, 1 мәдәният учреждениесе һәм 2 яшьләр сәясәте учреждениесе җиһазландырылды;
- янгын вакытында хәбәр итү һәм кешеләрне эвакуацияләү белән идарә итү системасы 3 гомуми белем бирү учреждениесенә, 16 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә, 5 өстәмә белем бирү учреждениесенә, 1 мәдәният учреждениесенә һәм 5 яшьләр сәясәте учреждениесенә куелды;
- сак сигнализациясе белән 1 гомуми белем бирү учреждениесе, 31 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 2 өстәмә белем бирү учреждениесе һәм 1 яшьләр сәясәте учреждениесе җиһазландырылды;
- сөйләм ярдәмендә ашыгыч хәбәр итү системасы белән 3 гомуми белем бирү учреждениесе, 2 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 1 өстәмә белем бирү учреждениесе, 2 мәдәният учреждениесе һәм 2 яшьләр сәясәте учреждениесе җиһазландырылды;
- 4 мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе, 1 өстәмә белем бирү учреждениесе һәм 5 яшьләр сәясәте учреждениесе гадәттән тыш хәлләр министрлыгы пультына хәбәрнамәләр тапшыру буенча объектлар комплексы белән җиһазландырылды;
- 77 учреждениедә хәвеф сигнализациясе системасы (КТС) яңартылды.

**Мәгълүмат куркынычсызлыгы һәм мәгълүмат саклау.**

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетының телекоммуникация инфраструктурасын саклауны көчәйтүгә юнәлтелгән өстәмә чараларны гамәлгә ашыру эше дәвам итте.

Шәхси мәгълүматларны яклау чаралары кысаларында мәгълүмат куркынычсызлыгы таләпләре буенча 2 мәгълүмат системасы аттестацияләнде, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләрендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүне оештыру өчен җаваплы кешеләр өчен вебинар үткәрелде, Казан шәһәре Башкарма комитетына караган учреждение вәкилләре катнашында эшлекле очрашулар уздырылды.

Өстәмә челтәрара экранлаштыру программа-аппарат комплекслары (8 берәмлек) сатып алынды, бу Казан шәһәре Башкарма комитетының барлык

структур бүлекчәләрен әлеге класслы саклау чаралары белән тәэмин итәргә мөмкинлек бирде, Кремль урамы, 7 йорт адресы буенча урнашкан яңа административ бинага керү өчен мәгълүматны криптографик саклау программа-аппарат комплексы (1 берәмлек) сатып алынды.

Ел дәвамында Linux операцион системалары өчен вируска каршы саклану чарасының корпоратив версиясе урнаштырылды, аның Казан шәһәре Башкарма комитеты компьютерларында һәм серверларында урнаштырылган комплектлары саны 2 300 берәмлектән артып китте.

**2026 елга планнар:**

- Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләрендә компьютерларга рөхсәтсез керүләрне ачыклау һәм челтәрара экранлаштыру чараларын, мәгълүматны криптографик саклау чараларын кертү чараларын төгәлләү;
- вируска каршы саклану чаралары белән бердәм үзәкләштерелгән идарә итүне, Астра Линукс операцион системасы өчен бердәм авторизация доменын төзү;
- законнардагы үзгәрешләрне исәпкә алып, ведомство буйсынуындагы учреждениеләрдә критик мәгълүмат инфраструктурасының әһәмиятле объектларының иминлеген тәэмин итү эшләрен үткәрүгә контрольне көчәйтү;
- законнарның яңа таләпләрен исәпкә алып, мәгълүмат системаларында мәгълүматны яклау чараларын үткәрү (Россиянең техник һәм экспорт контроле буенча федераль хезмәтенең 117 номерлы боерыгы).

Казан шәһәре Башкарма комитеты, төрле өлкәләргә заманча технологияләр кертеп, шәһәр идарәсен цифрлы трансформацияләү эшен башкара.

**Электрон формадагы муниципаль хезмәтләр һәм ведомствоара хезмәттәшлек**

2025 елда муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын арттыру өчен ведомствоара мөрәҗәгатьләрне Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең гамәли платформасыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасына 13 төр белешмә буенча автомат рәвештә тутыру һәм автомат рәвештә җибәрү механизмнары гамәлгә ашырылды, бу хезмәтләр күрсәтүне тизләтү мөмкинлеген бирде.

7 муниципаль хезмәт өчен автомат рәвештә эшкәртелгән документларның шаблоннарын генерацияләү кертелде, шулай ук 3.0 версиясендәге Бердәм ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең гамәли платформасын тоташтыру тәэмин ителде. Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү программасында катнашу хезмәте электрон форматка күчерелде. 5 муниципаль хезмәт өчен, визуаль конструктор кулланып, Россия Федерациясе дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең бердәм порталына чыгару мөмкинлеге өчен гаризаларның экран формалары эшләнде.

**Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасын** үстерү эше дәвам иттерелде. Әлеге система эшчәнлеге кысаларында 1 800 дән артык кулланучы мөрәҗәгате эшкәртелде, автомат рәвештә эшкәртелгән документларның 147 шаблоны эшләнде һәм кертелде. Системага 42 яңа бүлекчә тоташтырылды, яңа объектлар өстәлү хисабына пространство мәгълүматлары базасы киңәйтелде. Комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасының Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең гамәли платформасы белән тоташтыру өлешендә гаризаны кире кагу статусын кабул итү буенча эшләр башкарылды. Хезмәт күрсәтү тизлеген арттыру өчен 3 хезмәт буенча Казан шәһәренең комплекслы муниципаль геомәгълүмат системасы белән Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләренең гамәли платформасын интеграцияләү алгоритмы тормышка ашырылды. «Яшелләндерелгән территорияләр, балалар һәм спорт мәйданчыклары электрон реестры» сервисының функционалы эшләнде. Бүгенге көндә реестрга 14 864 объект кертелгән. Бу шәһәрне төзекләндерү белән идарә итү өчен бердәм һәм актуаль база формалаштыра.

Шәһәрнең **3D моделен** үстерү кысаларында платформага 217 яңа проект йөкләнде. Цифрлы модельләштерү технологияләрен куллану, проект карарларын реалистик масштабта визуализацияләүне тәэмин итеп һәм булган шәһәр төзелешен исәпкә алып, шәһәр төзелеше процессларының ачыклыгын

сизелерлек арттырырга мөмкинлек бирде. Бердәм 3D-платформаны куллану нәтиҗәсендә килештерү процедураларының үтәлү вакыты кыскартылды.

Тест рәвешендә куллану өчен 4 юнәлешне, 15 мәгълүмат чыганагын һәм 71 төп күрсәткечне үз эченә алган **шәһәр дашборды** булдырылды һәм эшли башлады. Транспорт чараларын контрольдә тоту буенча «Шәһәр мониторы» системасы кертелде һәм камилләштерелә. Система ярдәмендә 850 махсус техника берәмлеге контрольдә тотыла, 3 856 маршрут биреме булдырылды, шулай ук 16 мең кв.км юллар һәм тротуарлар цифрлаштырылды.

Кадрлар һәм эчке системаларда **HR «Пульс»** системасындагы оештыру-штат структурасы яңартылды, яңа структур берәмлекләр өстәлде һәм 439 хезмәткәр өчен исәп язмалары булдырылды. Шулай ук Directus базасында кадрлар белән эшләү буенча идарә итү системасы кертелде, **MAX платформасында** яңа хезмәткәрләрне адаптацияләү буенча бот эшли башлады, искергән базадагы функционал күчерелде.

Казан шәһәре Башкарма комитетының бердәм колл-үзәге операторларына мәгълүмат эзләүне җиңеләйтү өчен ясалма интеллект нигезендә **«акыллы» мәгълүмат базасы** гамәлгә кертелде. Тавышлы ярдәмченең сораулар исемлеге киңәйтелде, Казан шәһәренең барлык муниципаль унитар предприятиеләре бердәм номерга тоташтырылды.

Электрон документлар әйләнешенең ясалма интеллект-ассистент гамәлгә кертелгән «ЭДО 3.0» яңа версиясенә күчү башкарылды. Ул документлар белән эшләүне гадиләштерергә мөмкинлек бирде.

Шулай ук халык белән хезмәттәшлек итүгә юнәлдерелгән сервислар эшләтеп җибәрелде.

**«Минем Казан» шәһәр сервислары экосистемасы** – системадан өзү/сүндерү урыны билгеле булган очраклардан алып үз йорты радиусында башкарылган чараларга кадәр шәһәр тормышы турында барлык кирәкле мәгълүматны алу өчен бердәм тәрәзә буларак эшләргә тиешле цифрлы платформа.

**Казанның белем бирү порталы** – укытучылар, методистлар һәм мәгариф өлкәсе хезмәткәрләре мәгълүмат, методик материаллар, яңалыклар белән уртаклаша һәм блоглар алып бара торган цифрлы мәйданчык.

**«Казан шәһәренең ачык мәгълүматлары» порталы** – шәһәр тормышының төп өлкәләре турында машина укый алырлык форматта тәкъдим ителгән актуаль структураланган мәгълүмат базасы.

**Планлаштыру, идарә итү һәм инцидентларны контрольдә тоту системасы** – мөрәҗәгатьләр һәм инцидентлар белән эшләү өчен омниканал система булдыру буенча эш алып барыла. Система мөрәҗәгатьләр һәм инцидентларның төрле чыганаклары белән «бер тәрәзә» режимында эшләргә, дубликатларны берләштерү нәтиҗәсендә кергән мөрәҗәгатьләр санын киметергә, шулай ук ясалма интеллект ярдәмендә җаваплар әзерләргә мөмкинлек бирәчәк.

**Техник ярдәм**

Мәгълүмат системаларына һәм кулланучыларга техник ярдәм күрсәтү күләме – 4 000 уникаль кулланучы һәм барлык мәгълүмат системаларының 12 меңнән артык кулланучысы булган 88 мәгълүмат системасыннан тора. 2025 елда техник ярдәмгә килгән 12 045 мөрәҗәгать буенча эш башкарылды. Мобиль кушымта аша – 672, клиент порталы аша 2458 мөрәҗәгать килеп иреште.

**Асылмалы элемтә линияләрен җир асты коммуникацияләренә күчерү**. Чараларны 2011 елда гамәлгә ашыра башлаганнан алып булган 2 527 км асылмалы линияләрдән операторлар тарафыннан – 2108 км линия, ә идарәче оешмалар тарафыннан 507 км хуҗасы булмаган һәм маркаланмаган челтәрләр сүтеп алынды.

**Мобиль элемтә.** 2025 ел ахырына база станцияләре саны 15 192 берәмлек тәшкил итә, кәрәзле челтәр сигналын тарату – 100%, кәрәзле элемтәдән файдалану (бер кешегә сим-карталар саны) 200 поценттан артып китә.

**Фиксацияләнгән (үткәргеч) элемтә.** Йорт хуҗалыкларының теркәлгән элемтә хезмәтләре белән тәэмин ителеше 77 процентка җитә. 82 иң тыгыз урнашкан торак массивы заманча GPON технологиясе буенча Интернет челтәренә керү мөмкинлеге белән тәэмин ителде.

**2026 елга планнар:**

- Казан шәһәре Башкарма комитеты процессларын оптимальләштерү һәм автоматлаштыру, хезмәткәрләр эше өчен эчке платформаларны үстерү;
- Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлегендә ясалма интеллектны гамәлгә кертү;
- муниципаль хезмәтләрне электрон рәвешкә күчерү;
- цифрлы трансформация һәм шәһәрләрнең IQ күрсәткечләрен арттыру эше кысаларында проектларны гамәлгә ашыру;
- «2026-2028 елларга Казан шәһәре муниципаль идарәсенең цифрлы трансформациясе» муниципаль программасы күрсәткечләрен гамәлгә ашыру;
- Казан шәһәренең цифрлы тәңгәл моделен үстерү;
- халык өчен Бердәм экосистеманы үстерү;
- Бердәм шәһәр дашбордын гамәлгә кертү.

2025 елда халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлекне үстерү, Казан шәһәренең уңай имиджын ныгыту һәм яхшырту, шулай ук кунаклар өчен уңайлы шартлар тудыру буенча максатчан эш дәвам иттерелде.

2025 елда Казан шәһәренә 5,1 млн турист килде, бу 2024 елдагыга (4,5 млн кеше) караганда, 13 процентка артык. Шәһәрнең кунакханә фондын төрле категориядәге 238 урнаштыру урыны тәшкил итә. Казан шәһәренең номерлар фондында 8412 номер, 17 750 урын санала.

Шәһәребездә туристларны җәлеп итә торган төп урыннар булып, гадәттәгечә, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, җәяүлеләр өчен Бауман урамы, Иске Татар бистәсе, Кремль яр буе, «Урам» экстрим-паркы, шулай ук шәһәрнең күпсанлы музейлары тора.

2025 елда Казан Кремлендә 4 471 706 кунак булды. Туристларның күпчелеге Мәскәүдән һәм Мәскәү өлкәсеннән, Башкортостан Республикасыннан һәм Марий-Эл Республикасыннан, Чуваш Республикасыннан һәм Удмуртия Республикасыннан, Самара, Ульяновск һәм Свердловск өлкәләреннән, Санкт-Петербургтан килгән.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе статистикасы буенча 2025 елда Казан шәһәренә 198 036 чит ил гражданины килде, бу, 2024 елга караганда, 25,2 процентка кимрәк.

2025 елгы навигация чорында Елга порты 496 371 кешегә хезмәт күрсәтте, бу, 2024 елга караганда, 7,3 процентка күбрәк. 2025 елда Казан шәһәренең Габдулла Тукай исемендәге халыкара аэропорты 5 384 816 пассажирга хезмәт күрсәтте, бу, 2024 елга караганда, 0,3 процентка артыграк.

2025 елда урнаштыру чараларының уртача йөкләнеше 60 процентны тәшкил итте. Гадәттәгечә, иң зур йөкләнеш җәйге чорга һәм бәйрәм көннәренә туры килә. Кайбер даталарда һәм бәйрәм көннәрендә кунакханәләрнең йөкләнеше 90 процентка җитте.

**Вакыйгага бәйле чаралар**

Татарстан Республикасы башкаласына кунакларны җәлеп итү һәм илебездәге перспективалы туристлык үзәге буларак аның имиджын ныгыту инструментлары арасында һәрвакыт вакыйгага бәйле чаралар аерым урынны биләп тора. 2025 елда түбәндәге традицион чаралар үткәрелде:

- туристлык, ресторан һәм кунакханә индустриясе предприятиеләре хезмәткәрләре арасында «Кунакчыллык йолдызлары» һөнәри осталык буенча III төбәкара фестивале. Ярышларда катнашуга Россиянең 23 шәһәреннән, шул исәптән Мәскәү, Санкт-Петербург, Түбән Новгород, Уфа, Омск шәһәрләреннән 239 кеше гариза бирде. Финалга 187 катнашучы чыкты, алар 12 төрле номинациядә җиңүче исемен яулау өчен көч сынашты. Катнашучыларны Мәскәү, Иркутск һәм Чабаксар шәһәрләре экспертлары бәяләде;
- «Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсы. Россиянең 43 шәһәреннән, шул исәптән Архангельск, Белгород, Мәскәү, Санкт-Петербург,

Ростов-на-Дону, Калининград шәһәрләреннән барлыгы 280 гариза кабул ителде. Конкурс дүрт номинациядә уздырылды: «Казан турында иң яхшы видеоролик», «Туристик Казан» дигән иң яхшы фотоэш», «Казанда туризм турында иң яхшы мәкалә» һәм яңа номинация – «Казан турында иң яхшы видеоролик. Команда белән эшләү»;

- 12-13 июль көннәрендә «Казан» гаилә үзәге территориясендә «Россия тәмнәре x Тәмле Казан» гастрономия фестивале узды. Проект Казан шәһәре Мэриясе һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы коллаборациясенә әверелде. Проектта илнең 40 төбәгеннән рекордлы санда 125 кафе, ресторан, эре җитештерүчеләр һәм кече фермерлар катнашты;

- Казанда велосезон Төнге велофест белән тәмамланды (27 сентябрьдән 28 сентябрьгә каршы төндә). Россиянең 20 шәһәреннән – Санкт-Петербургтан һәм Мәскәүдән алып Владивостокка кадәр 4 мең кеше, әлеге чарада катнашып, Казан урамнары буенча 18 км юл үтте. Фестиваль Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгына һәм Ватанны саклаучылар елына багышланган иде.

**Яңа проектлар**

Кунакчыллык өлкәсендә һөнәрләрнең абруен яңадан күтәрү һәм арттыру, сыйфатлы сервис булдыручыларның хезмәтенә хөрмәт культурасын формалаштыру максатыннан 2025 елда Казан шәһәрендә «Кунакчыллык йөзләре: илһам бирүче профессионаллар» проекты гамәлгә ашырылды. Казан шәһәре урамнарында сервис өлкәсендәге осталар фотосурәтләре төшерелгән билбордлар урнаштырудан гыйбарәт әлеге проект Казанның Россиядә детальләргә игътибар итүгә һәм кунаклар турында кайгыртуга югары таләпләр куелган иң кунакчыл шәһәрләрнең берсе статусын ныгытуга юнәлдерелгән.

2025 елның 24 декабреннән 2026 елның 8 гыйнварына кадәр «Әкият» курчак театры янындагы парк территориясендә «Бияләй» Яңа ел ярминкәсе уздырылды. Мәйданчыкта сувенирлар, бүләкләр һәм гастрономия сата торган 14 сәүдә павильоны эшләде. 16 көн эчендә ярминкәгә барлыгы 20 мең кеше килде.

Туристлык өлкәсен цифрлаштыру бурычларын гамәлгә ашыру кысаларында июль аенда Казан шәһәренең рәсми туристлык порталы (go.kzn.ru) – кунаклар һәм шәһәр халкы өчен туристлык инфраструктурасы, карталар, маршрутлар һәм юл күрсәткечләре турында җентекле мәгълүмат булган рәсми ресурс эшли башлады. Ел ахырына порталны уртача айлык караулар саны 12 мең тирәсе тәшкил итте.

**Туристлык потенциалын алга җибәрү**

2025 ел дәвамында Казанны халыкара һәм төбәкара туристлык базарларында алга җибәрү буенча актив эш алып барылды. Аерым алганда, Tourism Plus Shanghai 2025 (Кытай Халык Республикасы) күргәзмәсендә катнашу; «Бөек чәй юлы: Россия-Монголия-Кытай» (Хух-Хото, Эчке Монголия) эшлекле киңәшмәсендә чик буе туристлык маршрутларын үстерү перспективалары һәм Казанның бу юлдагы төп пунктларның берсе буларак

роле турында фикер алышу; CITIE-2025 Халыкара күргәзмәсендә (Гуанчжоу, Кытай Халык Республикасы) һәм Исфаханда туризм һәм гамәли сәнгать буенча 15 нче Халыкара күргәзмәдә (Иран Ислам республикасы) катнашу.

Ел дәвамында партнер шәһәрләр белән туристлык продуктларын бергәләп үстерүгә һәм тәҗрибә уртаклашуга юнәлдерелгән яңа килешүләр төзелде, Казанда Минск көннәре кысаларында Минск шәһәре башкарма комитетының (Беларусь Республикасы) Спорт һәм туризм буенча баш идарәсе белән үзара аңлашу һәм хезмәттәшлек турында меморандум имзаланды. Шулай ук «РОСТКИ: Россия һәм Кытай – үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек» бизнес-форумында Самара белән туризм өлкәсендә уртак эш турында килешү төзелде.

Самара, Калуга, Екатеринбург, Түбән Новгород һәм Минск шәһәрләре белән реклама баннерларын алмашып урнаштыру кампаниясе гамәлгә ашырылды, ә бу исә Казанның танылуын арттыруга ярдәм итте.

Чит ил кунакларын җәлеп итү максатыннан Казандагы генераль консуллыклар һәм сәүдә вәкиллекләре белән актив хезмәттәшлек алып барыла.

Ел дәвамында Казанны җәлеп итәрлек туристик юнәлеш буларак популярлаштыруга юнәлтелгән төрле телевизион проектлар төшерүгә ярдәм күрсәтелде.

Казан – Россиянең гастрономик башкаласы концепциясе кысаларында май аеннан ноябрь аена кадәр уңышлы рәвештә «Казанда иртәнге аш» яңа гастрономик проекты гамәлгә ашырылды. Аның төп максаты – туристларны һәм Казан халкын Татарстанның мәдәни-тарихи мирасы белән гастрономик милли традицияләр аша таныштыру: аш-су кабул итү истә калырлык вакыйгага һәм туристлар өчен шәһәрнең яңа истәлекле урынына әверелә.

Милли сувенир брендын популярлаштыру кысаларында «Мәскәү» һәм «Прага» тортлары үрнәгендә ясалган «Казан» тортын әзерләү буенча осталык дәресе үткәрелде. Аны Казан шәһәрендәге учреждениеләрдә эшли башлау планлаштырыла.

**Уңышлар һәм җиңүләр**

2025 елда Казан Халыкара Russian Event Awards премиясенең «2025 елның вакыйгага бәйле туризмы өчен иң яхшы шәһәр» номинациясендә җиңү яулады.

Масштаблы «Төнге велофест» фестивале XII Бөтенроссия «Ел маршруты» премиясендә «Патриотик туризм өлкәсендә иң яхшы вакыйга» номинациясендә өченче урынны алды, шулай ук «Иң яхшы велосипед маршруты» номинациясендә «Киң күләмле велопроект өчен» махсус дипломы белән бүләкләнде.

XVIII Халыкара «Яшисе килә торган шәһәр» Бәйсез Дәүләтләр Берлеге һәм Евразия икътисади союзы шәһәрләренең шәһәр практикалары смотр-конкурсы нәтиҗәләре буенча Казан «Кунакчыллык йолдызлары» һөнәри осталык фестивален үткәрү өчен, шулай ук шәһәрнең туристлык ресурсларын («go.kzn.ru» порталы) комплекслы алга җибәрү өчен бүләккә лаек булды.

**2026 елга планнар:**

- төрле чаралар уздырып һәм туристлык күргәзмәләрендә катнашып, эчке һәм халыкара мәйданда Казан шәһәре брендын алга таба үстерү;
- кабат килүче туристлар процентын арттыру;
- вакыйгалар белән бәйле чаралар үткәрү.

## Юридик эшчәнлек

Казан шәһәре Башкарма комитеты һәм аның структур бүлекчәләре эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итү өлкәсендә түбәндәге юнәлешләр буенча эш алып барылды:

а) Казан шәһәре Башкарма комитеты эшчәнлеген хокукый яктан тәэмин итү, шул исәптән киңәшмәләрдә, комиссияләрдә катнашу, контроль-күзәтчелек органнары үткәрә торган тикшерүләрдә катнашу, шулай ук гражданнарны кабул итү;

б) гомуми юрисдикция судларында, арбитраж судларында, прокуратура органнарында, Федераль монополиягә каршы хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә, дәүләт хакимияте органнарында Казан шәһәре Башкарма комитеты мәнфәгатьләрен яклау;

в) Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә торган хокукый актларга, хокукый акт, килешү, шартнамә проектлары һәм башка документлар проектларына хокукый һәм коррупциягә каршы экспертиза ясау;

г) Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына һәм аның карамагындагы предприятиеләргә һәм учреждениеләргә консультация ярдәме күрсәтү.

Хокукый экспертизага Казан шәһәре Башкарма комитетының карарлары һәм боерыклары һәм капиталь төзелеш объектларын файдалануга кертүгә рөхсәт бирүнең 11 500 дән артык проекты тапшырылды.

12 меңнән артык проектка (кимчелекләрне кабат күрсәтүне исәпкә алып) хокукый характердагы бәяләмәләр әзерләнде (2024 ел белән чагыштырганда, 50 процентка күбрәк).

Шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан төзелә торган килешү һәм шартнамәләргә, җир кишәрлекләрен сату-алу, арендалау һәм җирдән бушлай файдалану килешүләре проектларына, ведомство карамагындагы учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан төзелә торган башка килешүләр һәм шартнамәләргә 5 меңнән артык хокукый экспертиза уздырылды.

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 13 октябрендәге 6374 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының норматив хокукый актларына һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру турында»гы карары нигезендә Казан шәһәре Башкарма комитетының 601 карары проектына коррупциягә каршы экспертиза ясалды.

2025 елда 12 193 тән артык суд утырышында катнашырга туры килде һәм (яки) катнашу оештырылды (2024 елда – 11 мең).

«1С: Суд эшләрен һәм таләп-дәгъва эшләрен исәпкә алу» системасы аша кергән 18 608 документ эшкәртелде (2024 елда – 15 486 документ).

Юридик хезмәтләр эшчәнлеген цифрлы трансформацияләү кысаларында 2025 елда эш барышын оптимальләштерү максатыннан «Суд эшләрен һәм

таләп-дәгъва эшләрен исәпкә алу» мәгълүмат системасының функционалы модернизацияләнде.

2025 ел дәвамында Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан шәһәре прокуратурасы, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасы белән норматив хокукый актлар проектларын тикшерү, аларга коррупциягә каршы экспертиза үткәрү буенча хезмәттәшлек алып барылды, 110 нан артык прокурор чарасы акты карап тикшерелде.

Даими нигездә Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына, шулай ук ведомство карамагындагы муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә гамәлдәге законнар нормаларын аңлату, суд һәм контроль-күзәтчелек органнарында мәнфәгатьләрне яклау барышында хокукый позиция формалаштыру буенча консультатив ярдәм күрсәтелә.

2026 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлары проектларына хокукый экспертиза уздыру, дәүләт хакимияте органнары, суд һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек итү, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнарына, аның карамагындагы предприятиеләргә һәм учреждениеләргә хокукый ярдәм күрсәтү, муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оптимальләштерү эше дәвам иттереләчәк.

**Оештыру-боеру документларын әзерләү**

Хисап чорында Казан шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан 11 252 хокукый акт (2024 елда – 11 924) кабул ителде, шуларның 4 841 е – карар (2024 елда – 5492) һәм 6 412 е – боерык (2024 елда – 6432).

2025 елда «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» (www.docskzn.ru) челтәр басмасында 3063 документ рус һәм татар телләрендә басылып чыкты. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) ике телдә 1582 норматив хокукый акт басылды.

## Кадрлар сәясәте

Казан шәһәрне үстерүче, аны уңайлы, имин һәм кызыклы итүче, аның тормышында актив катнашучы кешеләр ярдәмендә динамик рәвештә үсә һәм үзгәрә тора. Команда формалаштыру, яңа хезмәткәрләрне җәлеп итү һәм кадрлар потенциалын үстерү Казан шәһәре Башкарма комитеты өчен өстенлекле юнәлеш булып тора.

Илнең иң яхшы эш бирүчеләренең берсе статусы иң яхшы кадрларны җәлеп итәргә, алга барырга һәм шәһәрдәге процессларны камилләштерергә, традицияләрне һәм мирасны сакларга, үзгәрешләргә җайлашырга, эшнең яңа форматларын үзләштерергә һәм шәһәрнең сыйфатлы үсеше өчен кирәк булганның барысын да эшләргә мөмкинлек бирә.

**Кадрлар потенциалын үстерү**

Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләрендә 2014 кеше эшли. Хезмәткәрләр арасында күпчелеге хатын-кызлар – 1368 (67,9%), ирләр – 646 (32,1%). Хезмәткәрләрнең уртача яше – 42 яшь.




Казан шәһәре Башкарма комитетында 1829 кеше югары белемле, шуларның 261 е – ике һәм аннан күбрәк югары белемгә ия, 162 хезмәткәр – урта-махсус белемле.

Ел саен хезмәткәрләр арасында биләгән вазифага туры килүне билгеләү өчен аттестация үткәрелә. 2025 елда 404 хезмәткәр аттестация узды (2024 елда – 443). Класс чиннары 557 хезмәткәргә бирелде (2024 елда – 504).

Шулай ук хезмәткәрләрнең карьерасын үстерүгә аерым игътибар бирелә. 2025 елда 302 ротация (2024 елда – 356) башкарылды, шулардан Казан шәһәре Башкарма комитетының 110 хезмәткәре югарырак урынга күчерелде.

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты хезмәткәрләре һәм бүлекчәләре җитәкчеләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү буенча системалы эш дәвам итте, аерым алганда:

- муниципаль хезмәттәге һәм карамакта булган учреждениеләрдәге 2014 хезмәткәр Казан (Идел буе) федераль университетының Югары дәүләт һәм муниципаль идарә мәктәбе базасында Һөнәри үсеш программаларының календарь планы нигезендә квалификацияләрен күтәрү программалары узды, 134 хезмәткәр уку үзәкләрендә төрле курсларда өстәмә һөнәри белем алды;

- 22 хезмәткәр «Җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре өчен коммуникатив стратегик сессияләр үткәрү (операцион нәтиҗәлелекне арттыру проектларын гамәлгә ашыру)» программасы буенча квалификация күтәрү курсларын узды;

- 58 хезмәткәр озак вакытка планлаштыру һәм экологик җаваплылык өлкәсендә компетенцияләр формалаштыру максатыннан «Тотрыклы үсеш» квалификация күтәрү курсын узды;

- төзекләндерү өлкәсеннән 36 белгеч хезмәтне оештыруның нәтиҗәле ысулларын кертү аша шәһәр мохите сыйфатын яхшырту программасы буенча укулар узды.

Структур бүлекчәләр арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек һәм өзлексез эшләү өчен атна саен кадрлар сәясәте идарәсендә электрон документлар әйләнешендә эшләү буенча укыту курслары уздырыла. 2025 елда 26 дәрес оештырылды.

**Талантларны сайлап алу, бәяләү һәм алар белән идарә итү**

«Пульс» персонал белән идарә итүнең цифрлы платформасын кертү кысаларында Казан шәһәре Башкарма комитетының вакантлы позицияләренә кандидатлар сайлау буенча актив эш алып барыла. Ул үз эченә вакансияләр булдыру һәм урнаштыру, кандидатлар эзләү, әңгәмәгә чакыру, компетенцияләрне бәяләү һәм хезмәткәрне эшкә кабул итүне ала.

Барлык вакансияләр һәрвакыт «Работа в России» һәм HeadHunter цифрлы платформаларында ачык кулланылышта урнаштырыла. Ачык булу кандидатларның географиясен шактый киңәйтергә мөмкинлек бирде. 2025 елда 33 меңнән артык җавап алынды.

Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләренә персонал (машина йөртүче-механизаторлар, механиклар, юл эшчеләре, диспетчерлар, смена мастерлары һ.б.) сайлап алу эше актив алып барылды. Бердәм рекрутинг үзәге эшләп килә, барлык актуаль вакансияләр персонал һәм эш эзләү буенча HeadHunter цифрлы платформасында һәм «Авито» белдерүләр урнаштыру сервисында шәһәр хуҗалыгы профильләрендә урнаштырылды.

Казан шәһәре Башкарма комитетында һәм аның карамагындагы учреждениеләрдә хезмәт юлларын башлаучыларга аерым игътибар бирелә. 2025 елда яңа кабул ителгән 494 хезмәткәр өчен Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе белән 10 сәламләү очрашуы һәм шәһәрнең төп истәлекле урыннары буенча 8 экскурсия үткәрелде, яңа хезмәткәрләр «Адаптация» чат-ботына (MAX цифрлы системасы базасында) – яңа һөнәри тирәлектә уңайлы җайлашуга ярдәм итүче электрон ярдәмчегә тоташтырыла. Чат-бот хезмәткәргә диалог, биремнәр һәм өйрәнү материаллары булган коммуникация инструменты буларак төзелгән.

2025 елның яңалыгы – «Мин Казан командасында» CRM-системасын булдыру. Ул яңа кабул ителгән хезмәткәрләр, шулай ук аларның остазлары һәм бүлекчә җитәкчеләре белән хезмәттәшлек итү мәйданчыгы булып тора. Аның ярдәмендә тиз аралашу һәм коллективта яңа хезмәткәрне эшкә урнаштыру турында мәгълүмат бирү мөмкинлеге ачыла.

Казан шәһәре Мэриясенең линия җитәкчеләрен үстерү өчен «йомшак» күнекмәләрне камилләштерүгә һәм аларның һөнәри осталыгын күтәрүгә юнәлтелгән 8 укыту программасыннан торган трек эшләнде.

Актив эшчәнлек алып бара торган «Остазлар бердәмлеге» яңа хезмәткәрләрне адаптацияләү эшендә мөһим роль уйный. Бүгенге көндә «Остазлар бердәмлеге» – эшкә яңа урнашкан хезмәткәрләр өчен юл күрсәтүче һәм ярдәм итүче команда ул. Берләшмәгә 84 хезмәткәр керә, алар «үз кешеләр

арасында үз булу» программасы буенча эшлиләр. Хисап чорында остазларның календарь планы нигезендә тренинглар һәм лекцияләр үткәрелде.

2025 елда «Казан шәһәре Мэриясендә адаптацияләү һәм остазлык» практикасы «Pro-наставничество» федераль конкурсында бүләккә лаек булды. Моннан тыш, Казан шәһәре Мэриясе Мәскәү Хөкүмәтенең яңа «В кадре» конкурсында абсолют җиңүче булды. Казан «Уңышлы кадр сере: җәлеп итү» номинациясендә үзенең эшләнмәләрен тәкъдим итте. «Мин Казан командасында» проекты мэрияне җәлеп итүчән һәм ачык эш бирүче сыйфатында алга этәрүче эчараларны үз эченә ала.

**Корпоратив культура**

Корпоратив культура аерым бүлекчәнең генә түгел, гомумән, Казан шәһәре Башкарма комитетының уңышлы эшләве нигезе булып тора. Алга киткән эчке культура һәм корпоратив коммуникацияләр нәтиҗәсендә «Казан командасы» миссиясе һәм кыйммәтләре алга таба үсеш ала.

Ел саен без хезмәткәрләребезнең эштә актив катнашулары дәрәҗәсен үлчибез. Гомумән, эшкә тартылганлык чагыштырмача югары булуга карамастан, кире элемтә нәтиҗәле булганлыктан, без тиз арада тиешле чаралар күрәбез, кирәкле карарлар кабул итәбез.

Шулай итеп, 2025 елда эчке коммуникацияләрне ныгыту һәм бердәм кыйммәтләр юнәлешләрен формалаштыру өчен Казан шәһәре Башкарма комитетының төрле бүлекләреннән 47 хезмәткәрне үз эченә алган «Корпоратив культура» программасы гамәлгә ашырылды. Әлеге инициативалар персоналның җәлеп ителүен арттырырга һәм һөнәри үсешнең яңа стандартларын билгеләргә мөмкинлек бирде.

«Казан командасы» корпоратив культурасы үзенчәлекле мохит тудыра. Спартакиада һәм Казан марафоны кебек традицион вакыйгаларга соңгы елда хезмәткәрләрнең гамәлгә ашырылган инициативалары да өстәлде: Казансу елгасы буйлап экологик йөзү, шәһәрнең 4 күленә сәяхәт һәм орнитологик экскурсияләр, атна саен «Йөгерү пәнҗешәмбесе» чарасында иртәнге йөгерүләр. Җирле үзидарә көнендә «Казан командасы» инициатива белән чыкты һәм «Черек күл» паркындагы балалар мәйданчыгын үзгәртү өстендә эшләде, ә «Тылсым» балалар инклюзив үзәгенең яңа аллеясында агачлар утыртты.

«Казан командасы» телеграм-каналында (хезмәткәрләр белән оператив аралашу өчен канал) 7 243 язылучы бар. Моннан тыш, MAX милли мессенджерында шундый ук канал булдырылды һәм эшләп килә.

2025 елда Казан шәһәре Мэриясе хезмәткәрләре өчен спорт, интеллектуаль һәм команда булдыруга юнәлтелгән чаралар оештырылды, «Казан командасы» эчендә бергәлекләр формалаштыру дәвам иттерелде.

Йомгаклау буенча төп корпоратив вакыйга булып 2 юнәлеш – коллектив һәм шәхси юнәлеш буенча уздырыла торган «Казан Мэриясенең ел командасы» конкурсы финалы торды.

**Яшьләрнең карьера проектлары**

«Казан командасы»нда яшьләрнең карьера проектлары яшьләрне һөнәри яктан камилләштерү һәм үстерү өчен шартлар тудыруга, шулай ук Казан шәһәре Мэриясе амбассадорлары бергәлеген формалаштыруга юнәлтелгән. Алар яшьләргә эш буенча практик тәҗрибә алырга, үз өлкәсендә әйдәп баручы белгечләр белән элемтәләр урнаштырырга һәм карьерасында беренче адымнар ясарга мөмкинлек бирә.

2025 ел нәтиҗәләре буенча Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләрендә 597 студент гамәли әзерлек узды.

Шулай ук «Казан Мэриясендә стажировка» проектының 4 нче сезоны гамәлгә ашырылды, анда 35 студент катнашты. Стажировка нәтиҗәләре буенча 6 кеше Казан шәһәре Мэриясе бүлекчәләренә эшкә урнашты, ә калганнары, стратегик сессияләрдә актив катнашып һәм үз югары уку йортлары базасында Казан шәһәре Мэриясе белән ачык очрашулар оештыручы булып, шәһәр тормышында катнашуларын дәвам итте.

Хезмәттәшлек кысаларында Казан шәһәре Яңа Савин районының «107 номерлы “Открытие” гимназиясе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесендә «Шәһәр идарәсе. Казан командасы» дип аталган беренче профильле класс ачылды. Унынчы сыйныфта укучы 30 яшь кеше кадрлар резервын формалаштыру стратегиясенең бер өлеше буларак Казан шәһәре Мэриясе гамәлгә ашыра торган уникаль белем бирү проектында катнашты.

Яшьләр көнендә Казан шәһәре Мэриясе HeadHunter белән бергә «УРАМ» экстрим-паркында «Казанда карьера» мәйданчыгын оештырды. Яшүсмерләр һәм студентлар шәһәрдәге эш бирүчеләр белән таныштылар, экспресс-әңгәмәдә катнаштылар һәм карьера буенча консультантлар белән һөнәри яктан үсеш алдылар. Әлеге мәйданчыкка барлыгы 20 мең кеше килгән иде.

**Тәҗрибә уртаклашу**

Дәүләт һәм муниципаль оешмаларның Казан командасындагы кадрлар практикасына ихтыяҗы зур.

2025 елда Россия Федерациясенең башка субъектларыннан килгән коллегалар өчен 19 стажировка оештырылды. Аларда 300 кеше катнашты. Программаларны Мәскәү, Кырым Республикасы, Төмән, Лисичанск, Луганск, Сургут, Уфа, Иске Оскол, Архангельск, Элиста шәһәрләре, шулай ук Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр институты (университеты), Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе (РАНХиГС) студентлары, Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләре өчен Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе югары дәүләт хезмәте мәктәбенең белем бирү модулендә катнашучылар һәм «Алдынгылар хәрәкәте» вәкилләре тыңлады.

Татарстан Республикасы муниципаль районнарыннан 25 коллега өчен «Шәһәр командасын формалаштыру һәм аның белән идарә итү. Хезмәткәрләр эзләү, аларны адаптацияләү, үстерү һәм кадрлар эшен оештыруның нәтиҗәле системасы» һәм «Шәһәр процесслары белән идарә итү. Яшәү һәм үсеш өчен уңайлы киңлек булдыру» дип аталган стажировкалар оештырылды.

Казан шәһәре Башкарма комитетында кадрлар сәясәте шәһәр белән идарә итүнең барлык өлкәләрендә талантлар белән нәтиҗәле идарә итү буенча бербөтен система булып тора. Урыннарда хезмәткәрләр эшен оештыруга, тышкы партнерлар белән аралашуга бәйле барлык процесслар уңайлы, үз вакытында һәм продуктив эшчәнлеккә, шулай ук белгечләрнең кадрлар потенциалын үстерүгә ярдәм итә.

**2026 елга планнар:**

- кадрлар күрсәткечләрен оператив мониторинглап, персонал белән идарә итүнең нәтиҗәлелеге панелен эшләү һәм гамәлгә кертү;
- цифрлы инструментлар кулланып, кадрлар процессларын оптимальләштерү;
- кадрлар сервисларын үзәкләштерү;
- «Казан – иң яхшы эш бирүчеләр шәһәре» концепциясе кысаларында Казан шәһәренең үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру һәм хезмәт эшчәнлеге өчен мөмкинлекләре булган шәһәр образын алга таба үстерү;
- мәгариф, мәдәният, спорт һәм яшьләр сәясәте өлкәләрендә җитәкчеләрнең кадрлар резервын формалаштыру.

## Оешмалардан һәм гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләр белән эшләү. Башкару дисциплинасын контрольдә тоту

Казан шәһәре Башкарма комитетында эш башкаруны алып бару һәм башкару дисциплинасын контрольдә тоту Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнары, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**Юридик затларның мөрәҗәгатьләре**

2025 елда предприятие һәм оешмалардан кергән 53 278 документ теркәлде (2024 елда – 48 363), шуларның 28 146 сы – кәгазь чыганакта (2024 елда – 24 990), 107 077 бит сканерланды һәм электрон документлар әйләнеше системасына йөкләнде (2024 елда – 106 828 бит).

Контрольгә куелды:

- эчке документлар һәм югарыдагы органнар документлары, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, суд органнарыннан килгән хатлар буенча Казан шәһәре Мэрының, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең 38 890 йөкләмәсе (2024 елда – 38 974);

- Казан шәһәре Башкарма комитетының, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасарының, урынбасарларының һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесенең 3205 карары һәм боерыгы буенча 27 187 контроль пункт (2024 елда – 23 459).

**Гражданнар мөрәҗәгатьләре**

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетында гражданнарның 25 399 мөрәҗәгате теркәлде (2024 елда – 30 661).

25 065 мөрәҗәгать контрольгә куелды (2024 елда – 30 116).

555 мөрәҗәгать коллектив исеменнән килде.




Казан шәһәре Мэры исеменә һәм Казан шәһәре Башкарма комитетына гражданнардан килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрнең тематикасы түбәндәге мәсьәләләрне үз эченә ала:



Оешмалар, предприятиеләр, гражданнар белән язмача аралашу мөрәҗәгать итү телендә алып барыла. 2025 елда русчадан татар теленә һәм татарчадан рус теленә барлыгы 12 959 бит документ тәрҗемә ителде (2024 елда – 12 365).

**Халыкны кабул итү**

Халыкны шәхси кабул итүне оештыруга аерым игътибар бирелә. 2025 елда Казан шәһәре Мэры, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе, аның беренче урынбасары, урынбасарлары, Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе, район администрацияләре башлыклары, Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре җитәкчеләре тарафыннан даими рәвештә гражданнарны кабул итүләр, шул исәптән шәһәр районнарында халыкның яшәү урыннары буенча урынга чыгып кабул итүләр уздырылды. Моннан тыш, Казан шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм функциональ бүлекчәләре тарафыннан атна саен Казан шәһәре халкына бушлай юридик ярдәм күрсәтелә.

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарында барлыгы 5 933 гражданин шәхсән кабул ителде (2024 елда – 5 931).

**«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы**

2025 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы аша Казан шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак бүлекчәләренә гражданнардан 42 197 хәбәрнамә керде, бу, 2024 ел белән чагыштырганда, 6 220 хәбәрнамәгә кимрәк.




2026 елның 1 гыйнварына «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасында гаризаларны үтәүнең торышы түбәндәгечә:

- эш алып барыла – 244 (0,6%);
- хәл ителде – 30 387 (72,0%);
- кире кагылды – 3 569 (8,5%);
- планлаштырылды – 7997 (18,9%).

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгәнчә, хәл ителгән хәбәрнамәләр индикаторы 65 процент булса, Казан шәһәре Башкарма комитетында хәбәрнамәләрнең 72,0 проценты хәл ителде.




2025 елда Казан шәһәре буенча «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасына иң популяр гаризалар категорияләре төзекләндерү, муниципаль юлларны карап тоту, юл хәрәкәтен оештыру, торак-коммуналь хуҗалык һәм яктырту мәсьәләләре булды:

| Сорау темасы | Килгән гаризалар саны |
|---|---|
| Территорияне комплекслы төзекләндерү | 14 688 |
| Муниципаль юлларны карап тоту һәм ремонтлау | 8 816 |
| Юл хәрәкәтен оештыру | 3 874 |
| Торак-коммуналь хуҗалык | 3 263 |
| Тышкы яктыртуны оештыру | 2 792 |
| Транспорт | 2 102 |

**«Дәүләт хезмәтләре. Бергә хәл итәбез» кире элемтә платформасы**

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитетына «Дәүләт хезмәтләре. Бергә хәл итәбез» кире элемтә платформасы (алга таба – кире элемтә платформасы) аша 14 505 гражданнар мөрәҗәгате (2024 елда – 14 485) килеп иреште. Кире элемтә платформасына түбәндәге категорияләр буенча иң күп гражданнар мөрәҗәгате кабул ителде:

| Мөрәҗәгать категориясе | Саны |
|---|---|
| Белем бирү (электрон көндәлек, Дәүләт хезмәтләре системасында мәктәп портфолиосы, мәгариф оешмаларын төзекләндерү һ.б.) | 6 123 |
| Автомобиль юллары (җәяүлеләр өчен кичүләр, юлларны төзекләндерү, юл билгеләре, җәмәгать транспорты тукталышлары һ.б.) | 2 263 |
| Төзекләндерү (ишегалды эчендәге юл түшәмәләре, җәмәгать территорияләре һәм җәяүлеләр зоналары, яшел үсентеләр һ.б.) | 1 865 |
| Ишегаллары һәм гомуми файдалану территорияләре (урамны яктырту, ташланган автомобиль, балалар мәйданчыклары һ.б.) | 1 044 |
| Күпфатирлы йортлар (идарә итүче оешмалар, диварлар һәм фасадлар, җыештыру, су белән тәэмин итү һ.б.) | 678 |

**Эш башкаруны контрольдә тоту һәм координацияләү**

Документларны әзерләүнең сыйфатына, аларны дөрес итеп рәсмиләштерүгә даими игътибар бирелде. 2025 елда 36 197 биттә 11 399 проект тикшерелде (2024 елда – 34 284 биттә 10 920 проект).

Ел дәвамында Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләрендә эш башкаруны контрольдә тоту һәм координацияләү башкарылды.

Структур бүлекчәләрдә предприятиеләр, оешмалар документлары, хатлары, гражданнарның мөрәҗәгатьләре белән, чикле рәвештә таратылырга тиешле мәгълүматны үз эченә алган документлар белән эшләү торышын план буенча тикшерүләр үткәрелде, алар нәтиҗәсендә Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе боерыклары кабул ителде, рекомендацияләр бирелде.

Тикшерү барышында ачыкланган кимчелекләр билгеләнгән срокларда бетерелде.

Шулай ук ел дәвамында Казан шәһәре Башкарма комитеты бүлекчәләрендә халыкны кабул итүне оештыру буенча планнан тыш тикшерүләр үткәрелде. Тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эш формаларын һәм ысулларын камилләштерү, гражданнарны кабул итү көннәрендә урыннарда шәхси кабул итүне алып бару эшен көчәйтү, гражданнарны кабул итүне урыннарга чыгып алып баруны планлы эш итеп башкару буенча рекомендацияләр бирелде.

Урынга барып тикшерүләр, Казан шәһәре Башкарма комитетының территориаль һәм тармак бүлекчәләре, муниципаль предприятиеләр, оешмалар, урыннардагы учреждениеләр тарафыннан үткәрелә торган эшнең сыйфатын объектив бәяләргә мөмкинлек бирә.

2025 елда «Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасыннан турыдан-туры һәм югарырак органнар аша Казан шәһәре Башкарма комитетына кергән 99 гражданнар мөрәҗәгатенең үтәлеше тикшерелде. Халык белән эшләү Казан шәһәре Башкарма комитеты җитәкчелегенең даими контролендә тора. Шәһәр кешеләренең проблемаларын хәл итүнең, мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итүнең оперативлык һәм тулылык ягыннан дәрәҗәсен, башкаручыларның җаваплылыгын арттыруның яңа комплекслы ысулларын эзләү дәвам итә.

**2026 елга планнар:**

2026 елда эш башкару, документларны вакытында һәм сыйфатлы әзерләү өлкәсендә, шулай ук контроль системасын алга таба камилләштерүне һәм Казан шәһәре Мэры һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе йөкләмәләрен тулы, сыйфатлы һәм нәтиҗәле үтәүгә юнәлдерелгән башкару дисциплинасын яхшыртуны тәэмин итү буенча эш дәвам иттереләчәк.

## Җәмәгатьчелек фикерен һәм массакүләм мәгълүмат чараларын мониторинглау

Халык һәм журналистлар өчен төп рәсми мәгълүмат чыганагы булып kzn.ru – Казан Мэриясе порталы тора. Көн саен сайтта төрле темага кагылышлы 20 гә якын уникаль яңалык бастырыла, алар төбәк һәм федераль массакүләм мәгълүмат чаралары буенча тарала.

2025 елда Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында 4 465 материал урнаштырылды (2024 елда – 4 106). Порталның яңалыклар лентасы татар теленә 100 процент тәрҗемә ителә. Төп яңалыкларны инглиз теленә тәрҗемә итү югары сыйфатта башкарыла.

2025 елда порталга керүчеләр саны – 1,5 млн кеше. Сәхифәләрне кереп караулар саны 6,6 млн булды. Массакүләм мәгълүмат чараларында порталдан алынган 3,2 мең тапкырдан артык цитата кулланылды.

Медиакиңлектә проактив режимда эшләү нигезе булып массакүләм мәгълүмат чараларын һәм социаль челтәрләрне мониторинглау тора. Хисап чорында 202 меңнән артык материал эшкәртелде һәм анализланды, шуларның 110 755 е – массакүләм мәгълүмат чаралары басмалары, 91 787 се – социаль челтәрләрдәге хәбәрләр.

Массакүләм мәгълүмат чараларында һәм социаль челтәрләрдә актив яктыртыла торган төп 5 популяр тема: пилотсыз очу аппаратлары һөҗүме һәм аның нәтиҗәсендә куркыныч янаулар, җәмәгать транспорты, хокук тәртибе, юл хәрәкәтен оештыру һәм шәһәр мәгарифе. Массакүләм мәгълүмат чараларында шәһәр хуҗалыгы темалары еш телгә алына: республика һәм шәһәр массакүләм мәгълүмат чараларында – мәкаләләрнең гомуми саныннан 64%, федераль массакүләм мәгълүмат чараларында – 36%.

2025 елда шәһәр халкы өчен «Минем Казан» порталы эшли башлады.

Бер ел эчендә сәхифәләрне 132 меңнән артык карау теркәлде, сайтка 50 меңнән артык кулланучы керде, 2 меңнән артыгы – шәхси кабинетлар ачты һәм тарату рәвешендә шәхсән үзенә җибәрелгән хәбәрләрне ала.

Порталда 1643 яңалык бастырылды, шул исәптән лонгридлар да (экспертлар белән әңгәмәләр, мәдәни күзәтүләр, чаралар дайджестлары, ял итү өчен локацияләр сайлау). Шулай ук кулланучыларга 3,3 меңнән артык төрле чара (концертлар, осталык дәресләре, спортка бәйле очрашулар һ.б.) турында хәбәр ителде.

Бәйрәм көннәрендә кулланучылар электрон почталарына котлау открыткалары алалар (Халыклар бердәмлеге көне, Яңа ел һ.б. уңаеннан).

Әниләр көне алдыннан шәһәр билбордлары өчен котлаулар җыю буенча акция уздырылды. Кулланучылардан ике йөзгә якын гариза килде, иң җылы һәм күңелгә үтеп керә торган 50 котлау шәһәрнең төрле нокталарына урнаштырылды.

**2026 елга планнар:**

Казан шәһәре җирле үзидарә органнарын мәгълүмати-аналитик яктан тәэмин итү эшчәнлеген һәм төрле коммуникация каналлары аша шәһәр халкы белән үзара хезмәттәшлекне дәвам итү: kzn.ru порталына керүчеләр санын арттыру, материаллар санын арттыру һәм аларның сыйфатын күтәрү; шәһәр халкы өчен «Минем Казан» порталын үстерү.

## Муниципаль архив

Казан шәһәренең архив фонды 1725 фондны үз эченә ала, бу 148 786 саклау берәмлеген тәшкил итә. 2025 елда фондлар саны 2 процентка артты.

**Фондлар саны**




2025 елда 20 011 хезмәт күрсәтелде, бу, 2024 ел белән чагыштырганда, 4 процентка күбрәк. Күрсәтелгән хезмәтләрдән 9868 е – социаль-хокукый юнәлештә.

**Хезмәтләр күрсәтү**




Заманча уку залы актив эшләп килә. 2025 елда барлыгы 4710 кулланучы уку залы хезмәтләреннән файдаланды, килүчеләр саны – 6825. Файдаланучылар саны, 2024 ел белән чагыштырганда, 19 процентка артты.

Эшчәнлеге туктатылган 14 оешманың шәхси составы буенча социаль әһәмияткә ия документлар саклау өчен кабул ителде, бу 403 саклау берәмлеген тәшкил итә.

Цифрлы трансформацияләү кысаларында ел башыннан 281 684 биттән торган 1721 эш электрон форматка күчерелде. Барлыгы 1 377 674 битлек 7722 эш цифрлаштырылды.

2025 елның ахырына Казан шәһәренең муниципаль архивында 1 номерлы исемлектә барлыгы 652 оешма – комплектлау чыганагы исәпләнә. 2024 ел белән чагыштырганда, комплектлау чыганаклары оешмалары саны 79 процентка артты.

Хисап чорында 288 яңа оешма – комплектлау чыганагы өстәлде, шуларның 285 е белем бирү учреждениеләре булып тора.

**Комплектлау чыганаклары саны**




2025 елда 41 комплектлау чыганагы булган оешмадан 3359 саклау берәмлеге күләмендә даими саклау өчен идарә документлары кабул ителде.

2025 елда «Ведомство архивы» проекты кысаларында 18 оешма 4006 саклау берәмлеген урнаштыру өчен тапшырды. 2022 елдан башлап, 24 оешмадан барлыгы 67 776 саклау берәмлеге кабул ителде.

Муниципаль архивта 1593 саклау берәмлеген үз эченә алган 32 шәхси чыганак фонды саклана. Шулардан 2025 елда 615 саклау берәмлеге булган 8 шәхси чыганак фонды, шул исәптән махсус хәрби операциядә катнашучыларның 2 фонды булдырылды.

Түбәндәге аудиовизуаль документлар кабул ителде:

- БРИКС халыкара берләшмәсенә багышланган архив коллекциясе, 44 исәп берәмлегеннән торган электрон фотодокументлар;
- махсус хәрби операциядә катнашучы хәрбиләргә гуманитар ярдәм күрсәтү буенча архив коллекциясе, 191 исәп берәмлеге булган электрон фотодокументлар;
- 2011 елгы «Казан шәһәре аэропанорамасы: кош очкан югарылыктан тарихи фотосурәт» оптик язмасы видеодокументы;
- 2025 елгы «Поисковик» тарихи-архив клубы утырышының оптик язма фонодокументы.

Архив эшен популярлаштыру һәм үсеп килүче буынга патриотик тәрбия бирү эшенә зур игътибар юнәлтелде. «Яшь архивчы мәктәбе» программасы буенча 11 дәрес, 722 кешегә 27 экскурсия һәм 13 офлайн-күргәзмә уздырылды, җирле үзидарә органнарының рәсми порталында 4 интернет-күргәзмә

урнаштырылды. «Поисковик» тарихи-архив клубының 8 утырышы үткәрелде, анда 300 дән артык казанлы катнашты.

«Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» республика фестивалендә Казан шәһәреннән Әхәтовлар-Вахитовлар гаиләсе җиңеп чыкты.

**2026 елга план:**

- архив документларын саклау һәм аларны исәпкә алу эшен дәвам итү;
- дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне сыйфатлы күрсәтү;
- иң күп кулланыла торган даими саклау документларының электрон күчермәләрен булдыру эшен дәвам итү;
- комплектлау чыганагы булган оешмаларының архив документларын тәртипкә салу һәм аларны саклауга вакытында алу;
- аудиовизуаль документлар кабул итү эшен алып бару;
- ведомство архивларын муниципаль архив идарәсе базасында урнаштыру эшен дәвам итү;
- архив эшен популярлаштыру һәм үсеп килүче буынны патриотик яктан тәрбияләү эшен дәвам итү.

## Бүләкләү сәясәте

2025 елда барлыгы **5290** (шул исәптән 2236 «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» юбилей медале) бүләкләү документлары карап тикшерелде, килештерелде һәм муниципаль бүләкләр әзерләнде.

**2022-2025 еллар өчен бүләкләр буенча статистик мәгълүматлар**

| Бүләкләү төре | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе бүләкләре | 110 | 148 | 2427 |
| Татарстан Республикасы бүләкләре | 1316 | 1586 | 1554 |
| Казан шәһәренең муниципаль бүләкләре | 1229 | 1106 | 1309 |
| **Барлыгы** | **2655** | **2840** | **5290** |

**Казан шәһәренең муниципаль бүләкләре**

| Бүләкләү төре | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел |
|---|---|---|---|
| Казанның Мактаулы гражданины | 1 | 2 | 60 |
| Казанның Мактау китабы | 3 | 5 | 4 |
| «Казанның иминлеге хакына башкарган хезмәте һәм эштәге батырлыгы өчен» аерым хөрмәт билгесе | 17 | 19 | 28 |
| «Казан хакына мактауга лаеклы хезмәте өчен» аерым хөрмәт билгесе | 45 | 45 | 75 |
| «Казанның Горурлыгы һәм Даны» аерым хөрмәт билгесе | - | - | 5 |
| Казанның Мактау грамотасы | 218 | 206 | 271 |
| Казан Мэрының рәхмәте | 534 | 450 | 492 |
| «Казан волонтеры» мактау билгесе | - | - | 6 |
| Казан шәһәре Башкарма комитетының Мактау грамотасы | 411 | 379 | 368 |
| **Барлыгы** | **1229** | **1106** | **1309** |

Ветераннарны «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел» юбилей медале белән бүләкләүне оештыру буенча зур эш башкарылды. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге буенча бүләкләүгә 2236 кеше тәкъдим

ителде, 2216 медаль тапшырылды.

Шәһәр каршындагы казанышлары өчен гражданнарны бүләкләү системасын камилләштерү һәм социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне стимуллаштыру максатыннан 2 яңа муниципаль бүләк булдырылды: «Казанның Горурлыгы һәм Даны» аерым хөрмәт билгесе, «Казан волонтеры» мактау билгесе.

«Казанның Горурлыгы һәм Даны» аерым хөрмәт билгесе хәрби, гражданлык яки хезмәт бурычын үтәгәндә кыюлык, фидакарьлек һәм батырлык күрсәткән гражданнарны бүләкләү өчен билгеләнгән. Бүләк башкаларның иминлеге хакына гомерләрен куркыныч астына куйган гражданнарның батырлыгын тану, шәһәр казанышларын популярлаштыруга һәм аның имиджын ныгытуга ярдәм итә.

«Казан волонтеры» мактау билгесе белән социаль әһәмияткә ия бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән ирекле (волонтерлык) эшчәнлек алып баручы, шулай ук шәһәрдә хәйриячелек һәм иреклелек үсешенә зур өлеш керткән гражданнар бүләкләнә.

Хисап елында Казан бүләкләре белән бүләкләгәндә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты акчаларыннан бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе, шулай ук бүләкләнгән зат вафат булган очракта, бүләкләрне тапшыру һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата бүләкләүне түләү тәртибе эшләнде һәм расланды.

**«Казанның Мактаулы гражданины»** дигән шәһәрнең иң югары бүләгенә «Ростех» дәүләт корпорациясе генераль директоры Сергей Викторович Чемезов лаек булды.

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итү елында шәһәрнең югары бүләге – «Казанның Мактаулы гражданины» исеме 59 ветеранга бирелде. Бу мәсьәләне Казан шәһәре Думасы сессиясендә карап тикшерү, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы ветераннары – Казанның мактаулы гражданнары китабының аерым томын булдыру, бу китапка кертелә торган язмаларны әзерләү, ветераннарга бүләкләрне рәсмиләштерү һәм тапшыру буенча зур эш башкарылды.

**Казанның Мактау китабына** түбәндәгеләр кертелде:

- Богуславский Ирек Борисович, Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты;

- Кудерметова Вероника Эдуардовна, Россия теннисчысы, Россиянең атказанган спорт мастеры, Зур шлемның парлы разрядта бер турниры (Уимблдон-2025) җиңүчесе;

- «ТАТЭЛЕКТРОМОНТАЖ» акционерлык җәмгыяте;

- «Россия ветераннар берлеге» бөтенроссия ветераннар иҗтимагый оешмасының «Татарстан Республикасы ветераннар берлеге» республика ветераннар (инвалидлар) иҗтимагый оешмасы.

2005 елдан алып 2025 елга кадәр «Казанның Мактаулы гражданины»

дигән югары исемгә барлыгы **122** кеше лаек булды, Казанның Мактау китабына **126** гражданин, коллектив, предприятие, учреждение кертелде.

2025 елда «Казан шәһәренең мактаулы гражданнары» китабы һәм Казан шәһәре Мактау китабының яңа томнары әзерләнде, китапларның бизәлешенә үзгәрешләр кертелде.

2025 елда **якынча 50** тантаналы чара үткәрелде, якынча **1400** кешегә республика һәм муниципаль бүләкләр тапшырылды.

2026 елда шәһәр халкына Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Казан шәһәре бүләкләрен тапшыру эше дәвам итәчәк. Шулай ук Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре һәм ведомство карамагындагы учреждениеләр, шәһәр предприятиеләре белгечләре өчен бүләкләү документларын рәсмиләштерү мәсьәләләре буенча укыту семинарлары үткәрү планлаштырыла.

## 2025 ел чаралары. Эшлекле дүшәмбеләр

2025 ел илебездә 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгы билгеләп үтелде. Бәйрәм алдыннан берничә чара үткәрелде, шәһәрнең 59 ветераны Казанның мактаулы гражданнары китабына кертелде, сугышта катнашучыларга истәлекле медальләр тапшырылды, ветераннарның фатирларында ремонт эшләре башкарылды, шулай ук илебезне һәм дөньяны фашизмнан азат иткән кешеләрнең үлемсез батырлыгына тирән хөрмәт йөзеннән башка чаралар үткәрелде.

2025 елда Казан шәһәрендә Татарстан Республикасының һәм Казан шәһәренең беренче затлары катнашында 450 дән артык массакүләм чара уздырылды: дәүләт бәйрәмнәренә, истәлекле даталарга һәм вакыйгаларга, Россия Федерациясеннән һәм чит илләрдән килгән делегацияләр визитларына багышланган чаралар, шулай ук шәһәр тормышының әһәмиятле вакыйгалары.

2025 елның иң төп вакыйгаларыннан «Сабантуй» татар халык бәйрәмен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен бәйрәм итү булды.

2025 елда безнең шәһәр беренче тапкыр «Новая волна» халыкара башкару сәнгате конкурсын, I БРИКС яшүсмерләр фестивален кабул итте. Моннан тыш, халыкара статуста юридик һәм архитектура-төзелеш форумнары («Казаныш») үткәрелде. Алар үз мәйданчыкларына дөньякүләм дәрәҗәдәге һәм һөнәри мохиттә ихтыяҗ зур булган экспертларны җыйды.

2025 елда Казан шәһәре территориясендә Татарстан Республикасы Рәисен сайлау һәм бишенче чакырылыш Казан шәһәре Думасына депутатлар сайлау буенча **2 сайлау кампаниясе** уздырылды. Казан шәһәре буенча сайлауларга килүчеләр саны: Татарстан Республикасы Рәисен сайлауда – 56,05%, Казан шәһәре Думасына депутатлар сайлауда – 54,87%.

Бердәм тавыш бирү көнендә гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча, гадәттәгечә, тиешле чаралар башкарылды – һәр участок стационар металл детектор белән җиһазланды, полиция хезмәткәрләре тарафыннан саклау тәэмин ителде.

Шулай ук Казан шәһәре Думасына депутатлар сайлауга әзерлек кысаларында бер мандатлы округларның яңа схемасын әзерләү буенча зур эш башкарылды һәм Казан шәһәре Думасының 2025 елның 26 мартындагы 7-37 но-мерлы карары белән расланды.

2026 елда Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасына 2026 елның сентябрендә бердәм тавыш бирү көнендә узачак депутатларны сайлауларга әзерлек кысаларында сайлаулар турындагы гамәлдәге законнар нигезендә тиешле эш башкарылачак.

2025 елда Казан шәһәренең тормышы эшчәнлегенә кагылышлы актуаль мәсьәләләрне карап тикшерү һәм аларны оператив хәл итү өчен атна саен, кагыйдә буларак, дүшәмбе көнне, киңәшмәләр залында **аппарат киңәшмәләре** үткәрелде.



2025 елда Казан шәһәре муниципаль берәмлеге органнары һәм Башкарма комитет бүлекчәләре җитәкчеләренең 47 аппарат киңәшмәсе уздырылды (2024 елда – 45), анда шәһәр тормышына кагылышлы 182 мәсьәлә карап тикшерелде (2024 елда – 178).

Атналык киңәшмәләрдә шәһәр инфраструктурасын үстерү, республика һәм муниципаль программаларны гамәлгә ашыру, халыкка хезмәт күрсәтү сыйфаты, төзекләндерү һәм уңайлы шәһәр мохите формалаштыру, халыкка социаль ярдәм күрсәтү һәм җирле үзидарә органнарының эш нәтиҗәлелеген арттыру кебек шәһәр тормышының төп мәсьәләләре системалы рәвештә карап тикшерелә, бу исә килеп чыккан проблемалар буенча оператив рәвештә чаралар күрергә һәм, шәһәр халкы мәнфәгатьләрен күз алдында тотып, идарә итү карарлары кабул итәргә мөмкинлек бирә.

**Аппарат киңәшмәләрендә карап тикшерелгән мәсьәләләр тематикасы**




**2026 елга планнар:**

- чаралар һәм киңәшмәләрне әзерләү һәм уздыру, аларны оештыру һәм беркетмәләрен теркәү;
- тугызынчы чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны әзерләүне һәм уздыруны оештыруда сайлау комиссияләренә ярдәм итү (2026 елның сентябре).

## Казан шәһәре Думасы белән үзара бәйләнешләр

2025 елда Казан шәһәре Башкарма комитеты үз эшчәнлеген Казан шәһәре Думасының эш планына нигезләнеп алып барды.

Казан шәһәре Башкарма комитеты ел дәвамында Казан шәһәре Думасы уздыра торган чараларны оештыруда һәм уздыруда актив катнашты: Казан шәһәре Думасының тугыз сессиясендә, Президиум утырышларында, даими комиссияләр утырышларында һәм башкаларда.

Казан шәһәре Думасы белән үзара хезмәттәшлек итү буенча төп юнәлешләрнең берсе – Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренә караган җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча материаллар әзерләү һәм аны тикшерүгә кертү. Материалларны вакытында әзерләү максатыннан Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 6394р номерлы «2025 елга Казан шәһәре Думасының эш планын үтәү чаралары турында»гы боерыгы кабул ителде. Аның нигезендә Казан шәһәре Думасының 2025 елга эш планы белән расланган мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы затлар билгеләнде.

Казан шәһәре Башкарма комитетының структур бүлекчәләре тарафыннан Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтләренә караган җирле әһәмияттәге

110 нан артык мәсьәлә әзерләнде һәм карап тикшерүгә кертелде. Алар арасында: «Татарстан Республикасында Ватанны саклаучылар елы һәм 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 80 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек турында», «2030 елга кадәр (перспективада 2040 елга кадәр) Казанның тотрыклы үсеш стратегиясе турында», «Шәһәрне стратегик яктан планлаштыру һәм уңайлы шәһәр мохите формалаштыру турында» һ.б.

Казан шәһәре Думасының барлыгы 155 карары кабул ителде: 106 мәсьәлә – Казан шәһәре Башкарма комитеты, 49 мәсьәлә Казан шәһәре Думасы тарафыннан кертелде.

Казан шәһәре Башкарма комитеты белән Казан шәһәре Думасы хезмәттәшлегенең мөһим формасы булып узган елгы эшчәнлек нәтиҗәләре турында халык алдында ел саен уртак хисап бирү тора.

2025 елның гыйнвар-февраль айларында 29 хисап очрашуы узды. Алдагы еллар тәҗрибәсе очрашуларга, шул исәптән онлайн-трансляцияләргә ихтыяҗ булуын һәм аларның популярлыгын күрсәтте. Мондый алым аралашуда күбрәк кеше катнаша алу мөмкинлеген бирде. Очрашуларда барлыгы 65 781 кеше катнашты (2024 елда – 59 630, 2023 елда – 57 483, 2022 елда – 47 905 кеше), шул исәптән 5135 кеше очрашуларга килде һәм 60 646 кеше онлайн катнашты.

Очрашуларда 441 сорау бирелде, аларның төп өлеше төзекләндерү (144), торак-коммуналь хуҗалык (139), объектлар төзү (34), транспорт хезмәте күрсәтү (31), мәгариф (14) һәм башка өлкәләргә карый.

**2023 – 2025 еллар чорына мәсьәләләрнең динамикасы һәм тематикасы**




Халык белән үзара хезмәттәшлекнең әлеге формасы перспективалы тәҗрибә булып тора, ул шәһәр халкының конкрет мәсьәләләрен һәм проблемаларын хәл итү өчен конструктив эш оештырырга ярдәм итә.

Территориаль иҗтимагый үзидарәләр эшчәнлеген гамәлгә ашыру – җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча тагын бер мөһим юнәлеш булып тора.

Бүгенге көндә Казан шәһәрендә 79 территориаль иҗтимагый үзидарә теркәлгән, шуларның 60 ы эшләп килә.

2025 елда Казан шәһәре территориаль иҗтимагый үзидарәләре «Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсында актив катнашты.

Республика конкурсында Казан шәһәренең 20 территориаль иҗтимагый үзидарәсе җиңү яулады һәм бүләккә лаек булды. Грантлар суммасы 12 166,55 мең сум тәшкил итте. Конкурста җиңүчеләргә һәм призерларга бирелгән грантлар территориаль иҗтимагый үзидарәнең устав эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм социаль әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.

**«Татарстан Республикасында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсының Казан шәһәре буенча нәтиҗәләре**




Казан шәһәре Башкарма комитеты һәм Казан шәһәре Думасы арасында нәтиҗәле хезмәттәшлек 2026 елда барлык эш юнәлешләре буенча дәвам итәчәк.

2026 ел Россия Федерациясендә Россия халыкларының бердәмлеге елы һәм Татарстан Республикасында хәрби һәм хезмәт батырлыгы елы дип игълан ителде.

Казан шәһәре Башкарма комитеты әһәмиятле мәдәни-массакүләм вакыйгаларга бай программа планлаштырды.

Казан традициягә әверелгән эре бөтенроссия һәм халыкара чараларны, шулай ук Казан – Ислам дөньясының мәдәни башкаласы статусы кысаларындагы чараларны кабул итәчәк.

1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын билге-ләп үтү елында ветераннарны хөрмәтләү, яшьләргә патриотик тәрбия бирү, Ватан Геройлары истәлеген саклауга юнәлдерелгән чаралар үткәреләчәк. Шулай ук бөек татар шагыйре һәм язучысы Габдулла Тукайның 140 еллыгына һәм герой-шагыйрь Муса Җәлилнең 120 еллыгына багышланган чаралар да планлаш-тырыла. Гадәттәгечә, Россия көненә, татар халкының «Сабантуй» бәйрәменә, Татарстан Республикасы көненә һәм Казан шәһәре көненә багышланган чаралар узачак. Бу һәм башка чаралар республикабызда һәм илебездә яшәүче, үз илебезгә мәхәббәт һәм аның тарихына хөрмәт белән берләшкән халыклар мәдәниятләренең төрлелеген һәм байлыгын күрсәтүгә юнәлдерелгән.

Моннан тыш цифрлы трансформация эше дәвам иттереләчәк. Ул күп каналлы мәгълүмат җыюны һәм, ясалма интеллект кулланып, гражданнар мөрәҗәгатьләренә һәм шәһәр хезмәтләре эшенә анализ ясауны тәэмин итү өчен күпсанлы эчке сервисларны бер-берсе белән бәйләргә, шулай ук мөрәҗәгать буенча эшләү вакытын киметергә һәм шәһәрдә хезмәт күрсәтү сыйфатын яхшыртырга мөмкинлек бирәчәк.

Тышкы сәясәттә Казан шәһәре Башкарма комитетының максаты булып Казанның партнерларыбыз белән сәүдә-икътисади, фәнни-техник, социаль һәм мәдәни элемтәләрен ныгыту тора.

2026 елда Казан шәһәре Башкарма комитетына, алдагы еллардагы кебек үк, шәһәр халкы тормышының сыйфатын һәм югары дәрәҗәсен саклауга ярдәм итә торган төп икътисади күрсәткечләрне тәэмин итүгә; кече һәм урта бизнесны алга таба үстерүгә һәм Казан шәһәренең инвестицияләрне һәм туристларны җәлеп итүчәнлеген арттыруга; муниципаль программаларны тулы күләмдә үтәүгә һәм аларны финанслау белән тәэмин итүгә; шәһәр тормышының барлык өлкәләренә дә тотрыклы үсеш принципларын кертүгә; коррупция күренешләрен кисәтүгә һәм террорчылыктан саклауга ярдәм итүче чараларның нәтиҗәлелеген арттыруга, гражданнар арасындагы татулыкны ныгытуга, шәһәрлеләрнең иминлеге дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлтелгән җаваплы мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк булачак.

Башкарыла торган эшләр Татарстан башкаласының социаль-икътисади үсеше өчен яңа импульс бирер һәм Казан шәһәренә җәлеп итү, талантлы һәм

алдынгы карашлы кешеләрне биредә калдыру, аларны үстерү өчен мөһим аргумент булыр дип ышанабыз.

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**